# Казан утлары



6

июнь

1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

6
июнь
1968

## Бу санда:

Г. Тукай исемендәге премияләр Комитетында . . 3

ПОВЕСТЬ, ПОЭМА ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР

Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Агымсу. Повесть . . . . . . 5

Ә. МАЛИКОВ. Салкын-Алан. Поэма . . . . . . 60

Ә. БАЯНОВ. Синең вөҗданың; Мин — диңгез; Кеше кайгысы; Ышан елларга; Уйладым да кабат...; Уянсалар; Сөйгән җирем... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

Р. ГАТАУЛЛИН. Гомер бакый...; О, күңелнең көче...; Кайларда йөрмәдем...; Нинди яз бу...; Бер як читтән торып...; Ерак Марс авылы...; Әллә бик тугры түгелбез...; Ул чакта мин...; Зур рәхмәт... Шигырьләр . . . . . . . . 71

Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Мин ялгызым...; Кара төндә...; Мин Себердә. Шигырьләр . . . . . . . . . 76

ЯЗУЧЫНЫҢ КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕННӘН

К. МӘРГӘН. Парчалар . . . . . . . . . . . . 77

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. ХӘМИТОВ. Геология докторы. Очерк . . . . 83

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ

Ш. РӨКЫЙПОВ. Упкыннар кочагында. Очерк . . 96

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

А. ФАЙНБЕРГ. Чишмәләр ерактан башлана . . . 102

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. ХАРИСОВ. Җәйләр, көзләр нинди булыр? . . 106

ЗАРИФ БӘШИРИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

З. БӘШИРИ. Замандашларым белән очрашулар . 114

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ш. АБИЛОВ, З. МАКСУДОВА. Лутфи Идел буйларында . . . . . . . . . . . . . . . . 133

ТӨРЛЕСЕННӘН

Г. ТАҺИРОВА. «Гөлҗамал» . . . . . . . . . . 143

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Төрек халык мәзәкләре . . . . . . . . . . . 145

Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . . 153

Съезд көндәлеге . . . . . . . . . . . . . . 155

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 158

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Редактор урынбасары: **Ләбибә Ихсанова**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Производствога бирелде 15/IV-1968 ел. Басарга кул куелды 23/V-1968 ел. ПФ 09022.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 65746 экз.
Заказ М-710. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге
матбугат комбинатында басылды. Казан. Бауман урамы, Йорт 19. 1968 ел.

# Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘР КОМИТЕТЫНДА

*Шушы елның 22 апрелендә Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре Комитетының йомгаклау утырышы булды. Комитет Г. Тукай исемендәге 1968 елгы премияләрне:*
*өч томлык „Татар халык мәкальләре“ җыентыгы өчен* ***Нәкый Исәнбәткә*** *һәм*
*„Казакъ кызы сөйгәнем“, „Солдат җыры“, „Гөлләрем“, „Безнең кардәшлек“, „Мактанчык егет“, „Бормалы су“ исемле җырлар циклы өчен* ***Заһид Хәбибуллинга*** *бирү турында карар чыгарды.*

## Котлыйбыз!

Шагыйрь, драматург, галим һәм тәрҗемәче Нәкый ага Исәнбәтнең исемен татар халкы гына түгел, бәлки тугандаш халыклар да хөрмәт белән телгә ала. Ул — күп санлы балладалар, шигырьләр, җырлар авторы һәм күренекле драматург. Аның «Хуҗа Насретдин» исемле атаклы комедиясе, «Мулланур Вахитов» исемле драмасы, герой-шагыйребез Муса Җәлилнең үлемсез батырлыгына багышланган «Муса» трагедиясе, «Зифа», «Рәйхан», «Һиҗрәт», «Гөлҗамал» пьесалары, «Миркәй белән Айсылу» исемле халык драмасы һәм башка әсәрләре Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә дә, башка республика һәм өлкәләр театрларында да зур уңыш белән куелып килә.

Өлкән әдибебез Нәкый ага Исәнбәт бик күп еллардан бирле татар халык иҗатын җыю һәм туплау, аны гыйльми эшкәртү буенча да армый-талмый эшли. Г. Тукай премиясе аңа әнә шул зур хезмәте — өч томнан торган «Татар халык мәкальләре» җыентыгы өчен бирелде.



*Нәкый Исәнбәт.*



*Заһид Хәбибуллин.*

Матур-матур җырлар авторы Заһид Хәбибуллин — татар музыкасын үстерүгә зур өлеш керткән күренекле композитор. Аның күтәренке рух, якты өмет белән сугарылган җырларын профессиональ башкаручылар да, үзешчән сәнгать коллективлары да яратып җырлыйлар. З. Хәбибуллин үзе дә һәрвакыт халык белән тыгыз элемтәдә яши: концертларда катнаша, музыка сөючеләр белән очрашулар үткәрә. Халыкның уй-хисләрен, тормыш-көнкүрешен яхшы белгәнгә күрә, ул иҗат иткән җырлар да халык күңеленә тиз кереп урнаша.

### *ХӨРМӘТЛЕ НӘКЫЙ АГА ИСӘНБӘТ һӘМ ЗАҺИД АГА ХӘБИБУЛЛИН!*

Сезне халкыбызның сөекле шагыйре Г. Тукай исемендәге бүләккә лаек булуыгыз белән меңнәрчә укучыларыбыз исеменнән чын күңелдән котлыйбыз һәм иҗатыгызда тагын да зуррак уңышларга ирешүегезне телибез!

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ.**
**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ.**

**Рафаил Төхфәтуллин**

# АГЫМСУ

ПОВЕСТЬ[1]

> Әй, көчле соң, көчле бу агым,
> Беләм аның кайда туганын.
>
> *С. Хәким.*

БЕРЕНЧЕ ДӘФТӘР

## Хикмәтле таш

### 1

Без Тегәрҗеп урамында алты малай үстек. Бишебез белән биредә, Агымсуда ук танышырбыз. Тик алтынчыбыз — Мирзаһит белән генә күрешү икеле булыр. Хәрби кеше булып китте ул Мирзаһит. Майормы, әллә полковниктамы шунда. Каядыр чит илдә үк хезмәт итә, Агымсуга әллә ничә елга бер генә кайтып күренә. Анда да туйганчы бер сөйләшеп булмый үзе белән. Ник дигәндә, йөзенә күтәрелеп карап булмастай бик чибәр хатыны белән кайта Мирзаһит. Латыш кызы диделәр хатынын. Марите исемле. Менә шул Маритесен җитәклэп кайтып төшә дә Мирзаһитыбыз, Маритесен җитәкләп, инеш буенда йөри, җитәкләшеп, Чагыл тавына менеп төшәләр, җитәкләшеп, озак-озак безнең скважиналарга, буровой вышкаларына карап торалар. Очрашып сөйләшә башласаң, әлбәттә, Марите дә, иренең әллә нинди алтын тасмалар тегелгән китель җиңеннән тотып, шунда басып тора. Ире елмайса, Марите дә елмая, иренең йөзе уйчанланса, Маритенең дә яз күгедәй зәңгәр күзләрендә төпсез бер моң чагыла.

Минем әйтеп тә караганым бар. «Әйдә, булмаса, уртак телдә — русча сөйләшик», — дим. Мирзаһит кулын гына селти. «Тегендә дә үзебезчә бер авыз сүз ишетергә зарыгып бетәм», — ди. Аннары, җиңендәге алсу бармак очларын сыйпап куеп, әйтә: «У нас насчет языка полная демократия», — ди. Марите моңар каршы көлемсерәп кенә үзләренчә — латышча берәр сүз әйтеп куя. Янәсе, демократияне раслый...

---

[1] Кыскартып басыла.

Ләкин, ни генә булмасын, сиңа шулай бер нәрсә дә аңламый да һәм артыгы белән аңлый да кебек төпсез күзләр карап торганда, сөйләшү сөйләшү түгел инде ул. Аннары, шунысын да әйтмичә ярамастыр. Минем ул әле моңсу, әле нурлы-көлемсерәүле күз карашы астында каушабрак калуымның тагын бер сәбәбе бар. Бик җитди сәбәбе бар. Минем хәзер инде бик тирән яшерелгән, ләкин онытуы һич мөмкин булмаган сызлаулы хатирәләремне уятып җибәрә бу караш.

Әйтсәм әйтим, Надяны хәтерләтә миңа Маритенең күзләре. Кем ул Надя? Монысы алда аңлашылыр. Тик хәзергә шунысын гына әйтә алам: минем язмышымда, минем ничек нефтьче булып китүемдә бик зур катнашы бар аның, Надяның. Надя... Надягөл!..

Менә шушы турыда сөйләп бирмәкче булам мин.

## 2

Безнең сабый чаклар сугыш елларына туры килде. «Әти» дигән кешеләрне без карточкаларда гына күреп белдек, күмәч-кабартма, шикәр-конфет ишеләрнең дөньяда бары-югы турында хәбәребез дә булмады. Аңа карамадык, Тегәрҗепнең яшел чирәмендә алты малай тәгәрәшеп үстек.

Алты малай дигәч тә, бөтен шул зур урамның бала-чага халкы бары алты бөртектән генә тора иде дигән сүз түгел. Олырак малайларның инде ябык җилкәләренә ул елларның котсыз нужасы менеп кунакларга өлгергән. Еш кына алар атка атланып, безнең яннан егетләрчә чыбыркы шартлатып үтеп китәләр дә басуга тырмага, сукага китеп баралар. Яисә үзләре «уф, алла» арбасына җигелеп, бу юлы инде башларын түбән үк игән хәлдә, безне бөтенләй дә күрмәмешкә салышып, каядыр юл тоталар... Әйе. Ә бездән кечерәкләрнең исә өй, ишек алды тирәсендә тагын үз дөньялары. Аннары, кызлар да шактый. Ләкин алар да үзләренең урак очыдай чәч толымнарын безнең чебиле куллардан араграк тоту ягын карыйлар. Шулай итеп, урам чирәменә тулысынча без хуҗа идек.

Хәер, безнең сабый чаклар да гел яшел чирәмдә генә үтмәде. Әлеге котсыз нужа бабай безнең нәни җилкәләрдән дә атлап узарга өлгерде. Ачыклабрак әйтсәң, урам чирәменә генә түгел, әниләр һәм абый-апалар гел эштә булганлыктан, өйләргә дә без хуҗа идек. Хуҗа булгач, әлбәттә, эшенә дә син хуҗа инде. Суын китерәсең, идәнен юасың, чыбык-чабык чабасың. Карга күкәе кадәр булуга, бәрәңге казый башлыйсың. Ул бәрәңге бакчасының эше дә яртысыннан артыгы, һич арттырусыз, безнең кулда иде. Иртә яздан, көрәк сабының төбеннән үк тотып көчкә каера-каера, җир казый башлыйсың. Аннары чүп утау, бәрәңге төбенә өю, алу... Чишмә булып акты безнең тирләр ул бакчага. Әйе. Ләкин, ни генә булмасын, сабый чакларым искә төштеме, иң беренче — әнә шул яшел чирәм килә дә баса минем күз алдыма. Их, хәзер генә ул тракторлары, машиналары бихисап күбәеп китте дә, бөтен урамны чокыр-чакырлап, кара балчыкка калдырып бетерделәр. Ә ул вакытта соң... Ат юлы да сизелер-сизелмәс кенә уелып торган ямь-яшел, тип-тигез иде безнең урам. Ят та ауна — бер бөртек тузан кунмаган йомшак яшел хәтфә...

Әлеге бәрәңге бакчасы һәм өйдәге бетмәс эшләр чабудан тартып торгангамы, мәктәптә укый башлаганчы мин алай Чагыл тавына, Әйшә болынына чыгып йөргәннәрне әллә ни хәтерләмим дә — гел шул яшел чирәм истә.

Ләкин ул елларның да Чагыл тавына бәйле бер вакыйгасы булды.

Болай булды ул. Яшел чирәмдә гел бергә уйнасак та, безнең бу чикерткәле һәм каз бәбиле дөньядан аерылышыр сәгатьләребез бергә сукмады. Мирзаһит белән Исламгәрәй, сыбызгы борыннар, бу дөньяга ничәдер айга барыбыздан да алданрак килергә өлгергәннәр икән — бездән нәкъ бер ел алданрак мәктәпкә дә йөри башладылар. Ә без, ягъни Әбүзәр, Сәхип, Илгиз һәм мин, киләсе көзгә кадәр аларны мәктәп рәшәткәсе арасыннан борыннарыбызны тыгып кына карап йөрергә тиеш булып калдык.

Мирзаһитны әйтмим, ул вакытта ук безгә караганда гәүдәлерәк малай иде ул, шуңа күрә аның алай алга чыгуы безне әллә ни шаккатырмады. Ә менә Исламгәрәйнең, ягъни безнеңчә әйткәндә Ислайның, көрәшә башласак гел минем аста мыш-мыш чирәм тырнап ятучы кубык борынлы шул малайның бездән алдарак мәйданга ыргылуы белән һич тә килешәсе килми иде. Әйтсәм әйтим, өченче класста ике ел утырды да, без барыбер аның артыннан куып җиттек җитүен. Ләкин беренче елны, бигрәк тә беренче көннәрдә... Көрпә сипкәндәй кубыклы борыны белән, мин сиңа әйтим, тәмам зәңгәр һаваны йөзеп йөрде шул. Абыйсыннан калган кыршылган сумкасын асып барганда каршысына без юлыксак, безгә йодрык сыешлы йөнтәс ялганчы чокырын гына күрсәтеп узып китәр иде.

Шулай бер атнамы, артыгракмы мәктәптә бик хәтәр белем эчеп алгач, Ислаебыз бер көнне кесәсеннән ап-ак таш чыгарды да мактанырга тотынды:

— Менә миндә нәрсә бар! Күрдең, ничек язып була. Коймага да язып була, җиргә дә, менә учка да... Акбур бу, беләсең килсә. Укытучы апа да безгә кара тактага шушының белән генә язып күрсәтә.

Белмим, хәзерге малайларны алай гап-гади акбур белән таң калдырып була микән? Ләкин теге вакытта шул мескен акбур кисәге тәмам бер могҗиза булды бит миңа, әй! Дөрес, Чагыл тавының безнең Агымсу инеше белән Зәй елгасы кушылган текә бер ярында кызыл, сары, яшькелт ташлар арасында ап-ак ташлар да күргәнем бар иде минем. Әнинең дә шул яклардан чиләк-көянтә белән ак балчык алып кайтып, өйнең тишек-тошыкларын сылаганын да күргәнем бар иде. Ләкин алар болай әйбәт итеп язмый, ташы тырный гына, балчыгы, сыза башладыңмы, ualырга тора иде... Кара син, кыршылган сумка асып, безгә йөнтәс җилкә чокырын гына күрсәтеп йөрүе җитмәгән, инде менә хикмәтле акбуры да Ислай кулында гына булсын, имеш!

Минем гарьлек савытым тулып ашты.

Юк, бардыр ул, бик тырышып эзләсәң, болай әйбәт яза торган ташы да бардыр анда, Чагыл тавында.

Һәм мин ялт итеп борылдым да, кая барганымны малайларга күрсәтмәс өчен, үзебезнең ишек алды, бәрәңге бакчасы аша үтеп, Чагыл тауга таба элдерттем.

## 3

Пыяла ярган, шырпы кергән, авыртулары бер вакытта да бетеп тормый торган минем кара үкчәләрем болай да алтыбызныкыннан да житезрәк ялтырый иде. Бу юлы ул кара үкчәләрем җиргә тидеме-юкмы, ләкин арт якка шактый җилле тиде — мин Чагыл тауга килеп җиткәнемне сизми дә калдым.

Әнә, арырак әйләнеп, Зәй күпере аша чыгарга да кызыл, сары, яшькелт катлы текә яр буйлап әлеге хикмәтле акбурны эзли башларга да була. Менә бер ак таш. Учыма сызып карыйм. Юк, монысы әйбәт язмый. Менә икенчесе. Монысы бераз яза, ләкин бармак тиюгә эзе бетәргә дә тора.

Күрәсең, минем хикмәтле акбур биектәрәктер. Очлы-кытыршы ташларга, ниндидер тамырларга тотынып, өскәрәк үрмәлим. Биеккәрәк күтәрелгән саен, йөрәгем дә катырак дөпелди бара. Ул арада аяк астымнан ук дөбердәшеп вак ташлар коелып кала, шулар белән бергә, минем эчтә дә, бугаз турысыннан алып аска ук, нәрсәдер бик авырттырып төшеп китә... Мин һаман да үрмәлим, өскәрәк күтәреләм.

Менеп җитәргә дә күп калмады. Инде ярты гәүдәм тау башында. Кулларым шундагы куакка чытырдатып ябышкан, тик аякларым гына яр читенә асылынган килеш. Ләкин минем инде тагын да тырмашырлык артык хәлем юк. Битемне салкынча чирәмгә куям да, аякларым әле һаман да яр читенә асылынган хәлдә, хәл җыярга ятам.

Шушы хәлемдә күпме ятканмындыр, бераздан якында гына ниндидер ят сүзләр сөйләшкәнен ишетеп, башымны күтәрәм. Башымны күтәрәм һәм... сихерләнгәндәй катып калам.

Кайда мин? Өнме бу, әллә төшме?

Минем алдымда гаять зур җәймәләрдән эшләнгән бер өй тора. Бераз шалашка да охшаган бу өй, ләкин безнең яшелчә каравылчысы Көби абзый шалашыннан шактый зуррак һәм чагыштырып та тормастай матуррак. Җәймә стеналары акрын гына җилферди. Шулай җилферди-җилферди очып та китмәсен дипмедер, үзен бау белән җирдәге казыкларга бәйләп куйганнар.

Ләкин кайда соң моның хуҗалары? Нидер сөйләшкән тавышлар һаман да ишетелеп тора, ә кешеләр үзләре күренми.

Менә кинәт өйнең бер як җәймә стенасы капылт кына өскәрәк күтәрелде дә, берәү килеп чыкты. Әйе, берәү чыкты... Ләкин кем дип уйлыйсыз чыгучыны? Минем чаклы, хәтта миннән дә кечерәк бер кызчык!

Мин инде тау башына яртылаш кына түгел, бөтенләй менеп җитәргә дә шундагы куак артына посарга уйлап бетергән идем. Инде шуңа талпынган да идем. Бу кызчыкны күрүгә, баягыдан да битәр хәйран калып, җиргә сеңдем.

...Һич онытасым юк, өстендә кызыл һәм зәңгәр чәчәкләр төшерелгән күлмәк иде кызчыкның, башында бераз давыл чәчәгенә дә, бераз гөмбәгә дә ошаганрак бик матур башлык иде. Менә ул бире табарак йөгереп килде дә, иелеп, тузгакбаш өзеп алды. Тагын берне, әнә тагын берне өзде. Аннары, туктап, кулындагы шушы ап-ак күперенке йомгакка карап торды. Өф итеп өреп куйды. Тузгакбашның җилдәй җиңел мамык җепселләре бөтерелеп очып китте. Кыз елмайды. Тагын өрде. Бу юлы мамык җепселләр үзенә күрә нәни бер буран уйнатып очындылар. Кыз рәхәтләнеп чырык-чырык көлеп җибәрде.

Бу көлүне дә, ихтимал, мәңге оныта алмамдыр. Шундый да нурлы итеп, шул кадәр дә саф чыңлы итеп көлә иде ул. Керфекләренең һәр бөртегеннән, бит алмаларының нәни чокырларыннан шат нурлар сирпелә бу вакытта, давыл чәчәгедәй башлыгы, кулындагы тузгакбашлары да аңа кушылып көләләрдер кебек иде. Шунда мин үземнең дә, яр читендә яткан җиремдә, тын гына көлеп җибәрүемне сиздем...

Әнә ул йөгерә-йөгерә чикерткәме, күбәләкме куарга тотынды. Йөгереп бара-бара да ике учы белән дә шап итеп җиргә таяна, бик сак кына, акрын гына учларын ача. Гаҗәпләнүдән кашлары өскә үк күтәрелә — чикерткә тоттырмый иде, ахры.

Ах, әнә шулай нурлы итеп, йогышлы итеп көлә белсәң дә, чикерткә-күбәләк тотуда миннән бөтенләй калышасың икән ич әле! Кая соң, чикерткәсен дә, күбәләген дә тотып күрсәтәсе иде үзенә.

Шушы ният белән мин тагын өскәрәк талпындым. Ләкин янадан урыныма сеңдем.

Мәсьәлә шунда, бу вакыт җәймә өй эченнән тагын бер кеше килеп чыкты. Озын гына буйлы иде бу кеше, хәтта безнең авылның Хөсәен абзыйдан да озынрак иде бугай. Аннан да бигрәк, өстендәге киемнәре

моңарчы мин күргән абыйларның берсенекенә дә охшамаган иде. Бик киң кырлы яшькелт эшләпәдән, ялтырап торган кыска күн пиджактан, гаять калын табанлы ботинкадан иде бу кеше.

Кызчыгым, бу кешене күрүгә, аңа каршы йөгерде. Йөгереп тә килде — күз иярми дә калды — теге абыйның иңбашына менеп тә утырды. Үзләре көлешәләр, кызу-кызу нидер сөйләшәләр иде. Ләкин никадәр генә колакларымны торгызып тыңласам да, мин аларның бер генә сүзләрен дә аңламадым. Шунда минем аннан башка да дөп-дөп килгән йөрәгем тагын бик авырттырып-авырттырып кысылып куйды. Әллә инде... Әллә инде болар сугыш ягыннан килгән явыз кешеләр микән? Бу шигемә үземнең үк ышанасым килмәсә дә, эчтә шөриләр тыпырчына башларга бик җитә калды бу. Ник дигәндә, тагы берничә минуттан менә нәрсә булды.

Кинәт бу озын буйлы кеше дә, аның иңбашына менеп кунаклаган кызчык та нәкъ миңа таба карап тора башладылар. Озын буйлының күзлек пыялалары бик куркыныч булып ялтырап китте.

Ул арада кызчык озын буйлының иңбашыннан төште һәм алар, икәүләшеп, туп-туры миңа таба килә башладылар. Үзләре һаман нидер сөйләшәләр, миңа дәшәләр иде бугай.

Тагы да икенче бер мизгелдә...

Кинәт бөтен тирә-юнь асты-өскә килеп әйләнеп китте, озын буйлының тагын күзлек пыялалары ялтырап калды, кызчыкның нидер кычкырганы ишетелде... Мин бая гына ни азаплар белән үрмәләп менгән текә яр буйлап аска тәгәрәдем...



## 4

Менә шулай. Бу дөньяда аягыңны ныклап торып катыга терәмәс борын, авызыңны ачып кызлар күзли башласаң, мәтәлеп-кадалып упкынга тәгәрәгәнеңне сизми дә каласың икән аны. Бу хакыйкатьне тормыш миңа шулай бик иртә дә өйрәтеп куймакчы булган иде дә бит... Юк шул, өйрәтеп җиткермәгән икән. Хәер, акылга үткән дә иде бугай инде, ә менә йөрәкне кая куясың, йөрәкне...

Их, бу Мирзаһитны да әйтер идем! Нигә шул Маритесен ияртеп кайтып йөри, ичмасам. Юкса, чыбык очы кардәшләрен искә алмаганда, Агымсуда беркеме дә юк аның хәзер. Әтисе белән абыйсы сугышта үлеп калдылар. Әнисен җирләгәнгә дә биш былтыр. Ләкин туган җир барыбер үзенә тарта шул ул. Көтмәгәндә генә, әлеге Маритесен житәкләп, кайта да төшә Мирзаһитыбыз. Хәзер инде ул кадәр үк түгел, хәзер инде йөрәк урынына утырып килә бугай. Әмма беренче кайтуларында... Шул яз күгедәй зәңгәр күзле Маритене беренче күрүдә... Чак кына яңадан упкынга мәтәлеп төшмәдем. Монысы инде сан ягыннан өченче мәтәлүем булыр иде һәм өченче мәтәлүдә — ай-һай...

Фу! Мин тәмам бутала башладым, ахры. Биредә Марите бөтенләй вакытсыз килеп керде. Хикмәтле акбур турында, давыл чәчәгедәй башлык кигән житез кызчык турында сөйли башлаган идем ич... Житмәсә, ташлы текә ярдан тәгәрәп төшеп киткән килеш калдым. Маритенең ни катнашы бар монда?

Кая, булмаса, бер көйрәтеп җибәрик тә, тәртибе белән генә сөйлим әле.

Тәртибе белән дигәннән, китапларда да алай бик тәртип саклап тормыйлар бит. Еш кына геройны әнә шулай иң хәвефле хәлдә калдыралар да шуннан соң нәрсә булганын бик озакка кадәр билгесезлек томанында тотарга яраталар. Минем дә шуңа охшашрак килеп чыкты.

Хәер, биредә әллә ни билгесезлек тә юк. Күргәнегезчә, минем исән-сау калу-калмавым турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Шулай ук яшькелт эшләпәле, озын буйлы абыйның һич тә алай шикле бер кеше түгел, ә бик изге ниятле геологик разведка кешесе икәнен, бу сихри җәймә өйнең алар куйган палатка икәнлеген сизенергә бер дә әллә ни зирәклек кирәкмидер. Хәзерге бала-чаганы мескен бер акбур кисәге белән шаккатырып булмаган кебек, хәзер инде яшькелт эшләпәле геологлар, җилфердек палаткалар белән дә Татарстанның бер генә читендә дә берәүне дә таң калдыра алмыйсың.

Кыскасы, безнең якларда гаять бай нефть ятмалары ачкан батыр геологларның берсе Владимир Петрович Керчинский белән, аның шулай нурлы итеп, йогышлы итеп көлә торган кызы Надя белән мин беренче тапкыр әнә шунда очраштым.

Хәзер, әнә, Чагыл тавының нәкъ шул сихри палатка урынында, гүя шушы очрашуның мәһабәт һәйкәле сыман, 129 нчы номерлы скважина тын гына җир мае суырып утыра.

Мондый шанлы скважиналар, биек-биек вышкалар, үзегез беләсез, бездә хәзер атлаган саен.

Безнең яклардагы шул бихисап скважиналарның нәкъ алтмыш икесе хәзер минем һәм минем бригадам егетләре карамагында эшли. Бу скважиналардан башка, бригадам егетләреннән башка тормышымны мин хәзер күз алдыма да китерә алмыйм. Өстәвенә, тиздән кулыма нефтьче инженер дигән диплом да алырга торам. Болар да, кайсы ягыннан гына торып карама, Чагыл таудагы шул яшел палаткага килә дә тоташа. Безнең якларда бай девон нефте ачучыларның берсе булу белән бергә, мине нефть эшенә җитәкләп алып керүче дә булды Владимир Петрович. Ә Надя... Әйе, монда Надяның да катнашы бар. Надя... Надежда... Миңа тылсымлы канатлар да бирде ул, үзе үк ул канатларны...

Тукта, мин тагын алга сикермим әле. Иң яхшысы, ташлы текә ярдан мәтәлеп төшеп киткән чакларыма тизрәк кире кайтыйм.

## 5

Минем исән-сау калу-калмавым турында сүз дә булырга мөмкин түгел, дигән идем. Әйе, хәзер инде сүз дә юк. Әмма теге вакытта сүз булган. Шактый җитди сүз булган.

Иң элек, минем арттан ук шуышып төшеп җиткән Владимир Петрович белән Надя бу турыда нидер сөйләшкәннәр. Аннары, Владимир Петрович мине күтәргән килеш басу капкасыннан килеп кергәч, ярты авыл җыелып мине кызганып сөйләшкәннәр. Аннары минем битемә әнием белән Хәбирә апамның күз яшьләре тамган. Ул арада, минем турыдагы хәбәр район больницасына, тагы да бераздан Казанга да барып ишетелгән. Күпмедер вакыттан соң мине алырга кызыл хачлы самолет килеп җиткән.

Шулай итеп, мин очканмын... Гомумән, ул көннәрнең хатирәсе ярдан мәтәлеп киткәннән алып бик озакка кадәр гел очу да очудан гыйбарәт. Бу очу бик кыйбатка төшкән төшүсен: умыртка сөягем сынган, башым тишелгән, авыз-борыным канаган. Шулай да абзагызны алты яшеннән үк канатлы хис, зәңгәр биеклекләр хисе татыган лачын баласы дия аласыз. Әйе. Эһм.

...Менә утлы-яшелле нурлар арасыннан, алтын болытлар арасыннан очам. Очып-очып йөрим дә, кинәт кенә кап-караңгы упкынга төшеп китәм. Сулышларым кысыла... Бөтенләй дә тын алып булмый башлый. Мин кычкырмакчы булам, нәрсәгәдер тотынмакчы булып кулларымны

сузам. Ләкин тавышым чыкмый, кулларым тотынырдай әйбер таба алмый... Шунда әллә кайдан гына ак халатлы бер апа килеп чыга да мине егылып барган жиремнән тотып кала...

...Шулай, бик күп, бик күп көннәр үткәч, әнием бирегә килеп, мине авылга алып кайтып китте.

Кайтыр алдыннан гына минем өстемдәге гипс күлмәкне галәмәт зәү кайчы белән кискәләп, салдырып алдылар. Аннары, ат тагарагыннан да зуррак ләгәнгә, ягъни ваннага, утыртып юындырдылар. Ак халатлы апа башымны, аркамны сабынлый, ә мин әй рәхәтләнеп тә корсагымны, янтыкларымны кашыйм. Айлар буе кашый алмавымның бар үчен тизрәк алып бетерергә теләгәндәй, хозурлана-хозурлана кашынам. (Бу кычытулар ул вакытта бик тә инде үзегемә үткәнлектән, моның турында да әйтмичә булдыра алмыйм.)

Юынып чыккач, миңа икенче бер бөгелмәс-сыгылмас күлмәк-корсет дигән нәрсә киерттеләр. Монысын шыгырдап торган калын каештан ясаганнар, бөгелмәсен өчен буй-буй ялтыр тимерләр кадаклаганнар. Шушы нәмәрсәне киеп йөрмәсәм, минем яңадан билем кузгалуы ихтимал икән...

## 6

Нәкъ шушы язны, мин култык асларымны чиләндереп, мыш-мыш килә-килә корсет киеп йөргән язны, сугыш бетте. Олыларның кайсы көлгән, кайсы жылаган бик истәлекле Жиңү көненнән соң күпмедер вакыт үткәч, әтием дә кайтты.

Гажәп, карточкасына бөтенләй диярлек ошамаса да, мин әтиемне бик тиз таныдым. Шулай, әлеге яшел чирәмдә малайлар белән мәш килә идек. Чатта кулына зур гына чемодан тоткан, аркасына яшел биштәр аскан, кара тут йөзле, күкрәгенә медальләр тезгән бер солдат күренүгә, моның әтием икәнлеген әллә кайдан гына күңелем белән сизеп алдым да каршысына атылдым.

Өйдәге күрешү шатлыклары нәкъ менә шатлыкмы-шатлык булып истә калган. Ничегрәк булган ул шатлык, нәрсәләр сөйләшенгән? Хәтерләмим. Тик әлеге акбурга бәйле мажараны гына һич онытасым юк.

Менә бер заман әти шул яшел биштәрен, чемоданын актарып ташлады да әнигә һәм Хәбирә апама күлмәк-мазар бирде, ә миңа... йодрык кадәр бер ак таш тоттырды. Бу ак ташны кулыма алуга, әлеге дә баягы, шул бичара акбур хәтеремә килде дә төште бит. Бәлки, мин әйтәм, бу таш Ислай биргәннән дә яхшырак яза торгандыр әле. Һәм мин, бик тырышып, бүлмә тактасына сызгалый башладым. Ләкин, хикмәт, яхшырак язу түгел, бөтенләй эзе дә төшми иде бу ташның. Нәрсәгә дип әллә кайлардан чаклы күтәреп кайткандыр моны әти? Үзебезнең Чагыл тавында беткән иде моның ишеләр...

Шунда әтием бик аптырап сорап куйды:

— Нишлисең, улым?

— Әти, язмый ич бу. Әнә, тырный гына...

— Әй, улым, — диде әти, бик тирән сулап. — Яза торган әйбер түгел бит ул. Ашый торган әйбер ул, улым. Әнә, суырып кара әле...

Шунда әтинең тавышы калтырап китте. Күзләрен ике йодрыгы белән каплап, урындыкка барып утырды. Бераздан башын күтәрде. Күзләре яшьле иде.

— Кара инде, Мәрфуга, — диде ул, әнигә карап. — улым шикәрнең нәрсә икәнен дә белми бит. Әй, сабый... Күрсәтте бу сугыш күрмешләрне...

Чыннан да, бу шикәр дигәннәре бик тәмле нәрсә булып чыкты.

Дөрес, больницада ятканда иртәнге чәйгә кашык очына элеп безгә дә песок дигәнен биргәлиләр иде. Ә бу шикәр дигәне аннан шәбрәк икән, рәхәтләнеп суырырга була. Ләкин... Ләкин, дөресен әйтим, шулай да, әтинең, күкрәгендә нәкъ алты медале булган әтинең, ул көнне алай күз яше тамызуы миңа бер дә ошамады...

## 7

Шул бик истә калган: безнең мич астында гел моңсу гына аваз салып ята торган чикерткәбез, әти кайткач, бөтенләй дә сайрамый башлады. Әтинең яңгыравыклы калын тавышыннан куркып качты микән ул, әллә «бу өйдә инде тормыш түгәрәкләнде» дип, бездә алай моң чыңлатып ятуны артык кирәксенмичә каядыр күчеп киттеме — аңламассың...

Әйе, тормышыбыз түгәрәкләнде. Әни, авыз кырые җыерчыкларына серле генә елмаю яшереп, әти алып кайткан әйбәт көрән күлмәк киеп йөри, өйдә әти кешенең калын тавышы яңгырап, аз гына тәмәке исе аңкып тора, өстәлгә без моңарчы бөтенләй дә күрмәгән тәмле-тәмле ризыклар менгәли — безгә, сабыйларга, тагы ни кирәк?

Шулай да әтинең ул калын тавышы еш кына канәгатьсезлек белән яңгырый иде.

— Их, Мәрфуга, — ди иде, — мин сугыш үткән җирләрдә генә басуларны шулай рәнҗеттеләр дип уйлап кайткан идем. Ул окоп-траншилар белән, ул снаряд-бомба чокырлары белән актарылып-актарылып беткән басуларга карап, ничек әрнегәннәремне белсәң икән. Тизрәк кенә туган кырларыма кайтып, үзебезнең игелекле басуларга бер ятып ауныйсым килә иде. Әмма ләкин... Без киткәндәге басулар юк икән инде ул хәзер. Җелеген суырып бетергәннәр басуларның, җелеген! Бер орлык чәчеп, көчкә-көчкә ике-өч орлык җыеп алгач, ул инде җирнең мәрхәмәте түгел, бу инде җирнең зар җылавы... Юк, Мәрфуга, бу килештән, мин яңадан да буразнага кайта алмыйм. Күреп торам, бу килештән, буразнада аунап та ипи ашый алмассың. Ә бит... Әллә мин монда ач утырыр өчен дүрт ел буе кан койдыммы? Юк инде... Миңа хәзер, покрайнимер, достойный эш бирсеннәр! Минем моңа полный правам бар. Аңлыйсыңмы, Мәрфуга, полный правам бар.

Һәм ул, медальләрен зыңлатып, күкрәгенә сугып куя иде.

Ул еш кына иртүк торып район үзәге Әлмәткә китеп бара, анда да үзенә «достойный эш» даулап йөри иде бугай — әни белән сөйләшүләреннән шулайрак аңлашыла иде. Йөри торгач, үз дигәненә тәки ирешә әти. Кайтуына күпмедер вакыт үткәч, аны үзебезнең Агымсу сельпосына председатель урынбасары итеп куйдылар. (Соңрак председатель дә булды.)

Менә шуннан соң инде әтинең тавышы элеге канәгатьсезлек белән түгел, бөтенләй икенче төрлерәк яңгырый башлады.

— Җитәр, Мәрфуга, мин югында михнәт шулпасын җитәрлек эчкәнсез, — ди иде. — Мин хәзер, покрайнимер, семьяма ит шулпасы эчертергә тиеш. Какой ир ди ул семьясын ашата-киендерә дә алмагач? Юк инде... Бу кыйшайган хәерче алачыгын да төртеп түнтәрергә вакыт. Яңа өй салырбыз...

Шулай итеп, мин авылда үзенә күрә «нәчәлнек кеше» малае булып алдым.

Гомумән, сугыш елларында алтыбыз тиңентен почтальон апаны сырып алып, аннан гел өчпочмаклы хат сорап йөдәтүче без Тегәрҗеп малайларының хәле хәзер инде шактый чуарланды. Мирзаһитның әтисе сугышның соңгы айларында үлеп калды, Әбүзәрнең әтисе хәбәр-

сез югалды. Сәхәпнең әтисе култык таягы белән, Илгизнең әтисе кулын имгәтеп кайттылар. Исламгәрәйнең әтисе, кайтуына, балтасын кулына алды. Ә минем әти, әнә, начальник.

Һәм көтмәгәндә...

## 8

Хәер, менә хәзер уйлап баксаң, алай ук көтмәгәндә булмады бугай бу хәл.

Мин авылыбыз кешеләре авызыннан әтием турында еш кына бик каршылыклы сүзләр ишетә идем. Берәүләр:

— Кемнең кулында — шуның авызында. Үз урыныннан файдалана белә ул Шиһап, — дип, әтине өнәмичә сөйләсәләр, икенчеләр:

— Сәүдәгә оста булып чыкты безнең Шиһап. Әнә Тайсуганда керосин кайтса, чакрым ярым чират була, ә бездә керосинның өзелгәне дә юк. Башка товарын да бик кайтарта, — дип, әтине яклыйлар да иде.

Бу сүзләрнең кайсысында дөреслек күбрәк булгандыр, әйтүе кыен. Әйе, эшенә бик бирелеп, бик тырышып эшли иде әти. Гел каядыр ашыга, гел юлда, гел нәрсәдер исәпли иде ул. Мин атналар буе аның кайчан йоклаганын, кайчан ашаганын да күрми идем.

Икенче яктан, сугыштан соңгы ул авыр елларда да безнең өйдә әллә ни мохтаҗлык сизелмәде. Үзенең «бу хәерче алачыгын төртеп түнтәрергә вакыт» дигән сүзләрен дә акрын-акрын тормышка ашыра бара иде әти. Ишек алдына әледән-әле бүрәнәсе, тактасы, түбә шиферы кайта торды.

Әнә шулай гел ашыга, гел юлда, гел нәрсәдер хәстәрли йөргән әти бер заман күзгә күренеп сүлпәнләнде.

Хәзер инде ул таң тишегеннән торып чыгып чапмый, иртәнге чәйне безнең белән бергә эчә, кичен дә гадәттәгедән иртә кайта, аннан-моннан капкалый да караватка барып ава иде.

Әни белән бик борчулы сөйләшкәннәрен дә ишеткәләргә туры килде.

Иске өйнең һәр идән ярыгына абына-сөртенә, авызыннан «зәмзәм суы» исе аңкыган хәлдә дә кайткалый башлады әти.

Шулай, бармак очлары белән генә стенага таяна-таяна кайтып кергән бер кичне әти минем башымнан сыйпап әйтте:

— Их, улым, райсоюз күсеәләре генә ашады башымны...

Ә бер көнне әтине район үзәгенә чакырып алдылар да шул китүеннән инде ул кайтмады.

Озакламыйча әтигә суд булды. Алты елга хөкем иттеләр.

Иртәгесен үк зәңгәр гимнастеркалы суд башкаручысы килеп, көне буе безнең ишек алдындагы бүрәнәләрне, такталарны, шиферны каядыр ташытты, өйдәге кайбер җиһазларны да тәятеп җибәрде. Әтинең ниндидер тулмаучылыгын түләтү өчен икән...

Хәтеремдә... Ишек алдыннан соңгы машина кузгалуга, мин аңкытинке үзебезнең бакча артына чыгып киттем. Күз алдыма әтинең сугыштан кайткан көнне медальләрен чыңлата-чыңлата «улым шикәрнең нәрсә икәнен дә белми» дип күз яше тамызып утыруы килеп баса... Аның: «җелегән суырганнар басуларның, җелегән...» дигән, «мин югында да җитәрлек эчкәнсез михнәт шулпасын» дигән, аннары «райсоюз күселәре генә ашады башымны» дигән сүзләре бер-бер артлы колак төбемдә яңгырагандай була иде. Ләкин бу сүзләрнең чын мәгънәсе аңыма һичничек барып җитми иде әле ул чакта. Мин аларны шактый соңрак кына төшендем.

## 9

Аннары, шул бик истә... Шушы ук көнне мин ялгызым гына тагын Чагыл тавы башына менеп киттем.

Нигә менәм? Нәрсә калган анда миңа? Менә мин, ихтимал, ул вакытта да ачык кына җавап бирә алмас идем. Була бит үсмер чакның тыелгысыз бер билгесез ашкынуы... Әйтерсең, тау башында мине теге вакыттагыга караганда да гаҗәбрәк күренеш көтә, әйтерсең, шул сихри дөньяда мин җанымны айкаган бар уй-кичерешләремнән котылачакмын. Әлбәттә, бу юлы да ул сихри күренешнең хуҗасы давыл чәчәгедәй башлык кигән шул ук көләч кызыйдыр... Тизрәк кенә менеп җитмәсәм, ул көләч кызый үзенең җаймә өен әкияттәге очкыч-палас итәр дә биек-биекләргә очар да китәр кебек... Мин ашыгам, абына-сөртенә йөгерәм.

Менеп тә җиттем. Күзләремә ышанмыйча һаман да йөгерәм. Узган елгы аксыл-соры кылган кыякларын кыштыр-кыштыр җил тирбәтә. Кара-кучкылт коры әремнәр моңсу гына миңа баш ияләр.

Ниндидер чокырлар, күгәргән консервы савытлары...

Әй, юк, сихри палатка хуҗалары миңа истәлеккә алай чокыр-чакырлар һәм күгәргән консервы савытлары гына калдырмаганнар икән. Әнә арырак нәкъ минем буе имән багана утыртып киткәннәр. Баганага ниндидер хәрефләр, цифрлар уеп язылган.

Менә шул. Әлбәттә, бернинди дә сихри дөнья каршыламады мине тау башында. Ләкин нәкъ менә шушы көнне — әтинең «җелеген суырганнар басуларның, җелеген» дигән, «мин югында да михнәт шулпасын җитәрлек эчкәнсез» дигән сүзләре колак төбемдә гел яңгырап торган шушы көнне — мин нәкъ менә шушы имән багана янына килеп басканмын икән, күңелнең акыл ирешмәслек әллә нинди эчке сиземләүләре барлыгына ничек ышанмыйсың?

## 10

Ул багана күптән инде минем генә түгел, бөтен авылның игътибарын җәлеп иткән иде. «Авылыбыз астында бик зур нефть күле тапканнар икән, әлеге багана шул күлгә җир бораулап төшә торган урын икән» дигән хәбәр күңелләрне еллар буе кытыклап торды. Шөгер ягында, аннары Баулы ягында күпләп нефть чыгара башлауларын да бик яшьләй ишетеп үстек.

Ул арада Писмән ягындагы Тимәш авылы янында куәтле девон нефте фонтан булып атты. Күп тә үтмәде, үзебезнең районда ук, Әлмәт, Габдрахман авыллары тирәсендә дә нефть чыгара башладылар.

Бер иртәне, салам түбәле өйләрне дерт сискәндереп, безнең авылга да зур-зур өч трактор килеп керде. Бер-бер артлы җигелеп, урамга көчкә сыешлы галәмәт дәү тимер шан сөйрәп баралар иде болар. Тегәрҗепнең яшел чирәмен аяусыз ерта-ерта, иң усал маэмайларны да өрүдән гаҗиз калдырып, аргы як басуга таба үтеп киттеләр.

Ләкин шул беренче тракторлар ертып үткән Тегәрҗепнең яшел чирәме — безнең балачагыбыз бишеге булган яшел чирәм — яңадан да инде яшәрмәде...

Аның каравы, тормыш безнең үсмер чакларыбызга әнә шулай гүелдек машиналы юллар — бүгенге көннәрдәге кебек тип-тигез асфальт юллар түгел, ә һәр үтәр карышы чокырлы да чакырлы, сикәлтәле юллар әзерләп куйды.

Кичләрен Әлмәт якларына күз салсаң, ярты күкне иңләп алтынсу-кызыл шәүләләр уйный, колакларыңны торгызыбрак тыңласаң, гел нәрсәләрдер гөрли, гүелди, чыңлый иде ул якта.

...Авылга сугышның соңгы елларында дары исе дә иснәгән, мыек чыгар-чыкмас килеш бөтен Европаны диярлек айкаган, сугыштан соң да ничәмә еллар чит җирләрдә хезмәт иткән яшь солдатлар кайта башлады.

Һәр солдат кайткан саен авыл урамнарында баянына, аккордеонына кушылып җырлаган сагыну моңнары таңга кадәр яңгырап тора, күпмедер көннәрдән соң урамнар янадан тынып кала — солдат погоннарын һәм медальләрен сандык төбенә салып куя да, яшел биштәрен бер як иңбашына гына элеп, Баулы, Әлмәт якларына таба юл тота.

Ул елларда кайткан солдатларның күбесе үзләренә «достойный эш»не әнә шулай нефтьтә таптылар.

Еш кына алар авылга кунакка кайталар иде. Өс-баш бөтенләй шәһәрчә боларның. Кибеткә керсәләр, шыгырдап торган зур-зур кәгазь акчаларны күкрәк кесәләреннән берәм-берәм суырып кына чыгарып торалар, авылдашларны бик юмарт «йөз грам»нар белән сыйлыйлар иде.

Әтием солдаттан кайтканда нефть вышкалары безнең авылдан шактый еракта иделәр шул әле...

Хәзер ул вышкалар авылыбызга көннән-көн якынаялар.

Мәнә минем яшьлегемә каршы атлап киләләр алар, вышкалар.

Тизрәк үсә генә төшим!..

Ләкин миңа ул шаулы кызыл офыкка таба атлап юлга чыгар көнемне әллә ни озак көтәргә дә туры килмәде.



**ИКЕНЧЕ ДӘФТӘР**

# Юллар һәм сукмаклар

## I

Юллар! Кешеләрне очраштыра да, аера да торган юллар. Сине үрләргә алып менә, бәхетенә таба илтә, ардырып чыныктыра һәм, кайсыдыр чатта дөрес атлый белмәсәң, сине әллә нинди упкынга таба да алып китүе ихтималы булган юллар!

Җилкәмдә — әтинең сугыш юллары кичкән яшел биштәре, күңелдә — ул вакытта әле үзәмә дә бик ачык булмаган әнә шундыйрак уйхисләр... Мин көзге дымлы юл буйлап атлыйм да атлыйм.

Атлыйм. Бик ачулы гүелдәп, мине әледән-әле машиналар узып китә. Әйе, бик ачулы гүелдиләр машиналар — ул чаклардагы юри актарып ташлагандай төпсез чокырлы-чакырлы юлларга ачуланалар бугай алар; миңа да сукранып үтәләр шикелле: «Бик олы эшнең әле һич тәртә-чираты эзгә төшмәгән бер вакытта, иреннәреңнән ана сөте дә кибеп җитмәгән килеш, син нигә буталып йөрисең әле монда?!» — диләр кебек.

Әлмәт исә мине тагы да хәтәррәк актарып ташланган юллары һәм тагы да усалрак гүелдәүче машиналары белән каршылады. Хәзерге кебек, берсеннән-берсе чибәррәк таш пулатлары, асфальтлы яшел

урамнары, күперенке келәм буйлап кына атлап йөри торган гостиницасы, урамда ук өч тиенеңне төшерүгә сиңа чыжлап торган тәмле су агызып бирүче акыллы автоматлары булган мәһабәт шәһәр кайда әле ул вакытта! Чокырлар... Канаулар... Җиңел кулдан гына эптәрләнгән бараклар. Палаткалар. Тактадан гына кадакланган контора будкалары. Гүелдәүче, тырылдаучы, төтенләүче, ут чәчүче әллә нинди машиналар. Шул чокырлар, канаулар, бараклар, машиналар арасыннан борма-борма юллар, сукмаклар. Шул бормалы юллардан, сукмаклардан һич адашмыйча йөри ала торган, шул коточкыч машиналарны бик тыныч эшләтә белә торган кешеләр, кешеләр...

Ә кайсысы икән соң монда минем сукмагым? Кайсы сукмактан атлап китәргә дә бик җитди чырайлы кешеләрнең кайсысына килеп йөз суымны түгәргә, кайсысына йөрәгемне бушатырга миңа?

Бу сорауга җиде юл чатында мыш-мыш борын тарта-тарта тик басып торган килеш җавап табып булмаячак иде, әлбәттә. Тоттым да аяклар үзе сайлаган бер сукмактан атлап киттем.

— Абый, ә абый! Мине дә эшкә алыгызчы?

Абый кеше минем нечкә булса да башны шактый нык тоткан сеңгерле муеныма, җиң эченнән инде терсәк тиңентен диярлек үсеп чыккан кулларыма күз төшереп алды да әйтте:

— Син, энем, минем янга иртәрәк килгәнсең бит. Хәзергә мине начальник итеп куймадылар әле. Начальник булгач килсәң, ихтимал, алыр идем мин сине. «Артыш таякларың» эшкә ябышыр күк күренә.

Һәм миңа ничек итеп фәлән контораны эзләп табарга, анда фәлән-фәләневич белән ничегрәк сөйләшергә икәнен бәйнә-бәйнә аңлатырга тотынды.

Ләкин мин, ул өйрәткәнчә, контора эзләп китмәдем. Тагын бер сукмактан үтеп, ниндидер машина янында мәш килүче абыйга шул ук үтенечемне кабатладым.

— Абый, мине дә эшкә алыгызчы?

Җавап тагын шул ук: фәлән конторага, фәлән-фәләневич янына.

Сез, әлбәттә, әйтерсез: «Нигә, чыннан да, конторага кермәдең соң? Эшкә алуның тәртибе шулай бит инде аның», — диярсез.

Моның сәбәбе бик гади һәм шактый катлаулы да иде.

Гади сәбәбе шул: минем кесәмдә бернинди дә документым юк иде. Ә нигә юк? Монысы инде әлегә «шактый катлаулы» дигәненә килеп төртелә.

Болай бит. Кулыңа ул документ дигән, белешмә дигән кәгазь кисәге алу өчен, иң элек, берәр өстәл башында утыручы каршына килеп басарга кирәк; анда килеп басу өчен кемнәрнедер һәм нәрсәдер күтәргә кирәк; бик озак көтәр өчен кат-кат килергә кирәк. Килергә, көтәргә... Янә килергә, янә көтәргә...

Инде менә миңа тагын шулай өстәл башында утыручы берәрсе каршына басарга киңәш итәләр. Анда килеп басу өчен кемнәрнедер, нәрсәләрдер көтәргә... Шулай итеп көтеп-көтеп йөри торгач, ул өстәл башындагы фәлән-фәләневич, иң беренче, әлбәттә, миннән сораячак: «Кайда әле документларың?» — диячәк. Миңа ул документларны юллау өчен... Килергә, көтәргә, янә килергә, янә көтәргә... Кемгә-кемгә, ә миңа, күңелемдә авылыбызга ниндидер үпкә төене яшереп чыгып китүчегә, мондый «килергә, көтәргә»ләрнең очы-кырые, ай-һай булыр иде микән ул елларда?

ФЗӨ мәктәбенә дисәң, вербовать ителеп китәм дисәң — икенче мәсьәлә. Ул чагында кулыңа белешмә дигәне дә, хәтта паспорт дигәне дә әлегергә мөмкин иде. Ә инде үз сукмагыңны үзең эзләп чыгарга җыенсаң... Иң яхшысы, килмә дә, көтмә дә...

Әмма мин барыбер үз сукмагымны үзем эзләп атлый бирәм,

Җинел кулдан гына салынган озынча бер йорт янында кара сырмалы, брезент курткалы кешеләр җыелган иде. Мин туп-туры шунда таба киттем. Инде өченче көнемне шушы тирәдә чуалып йөргәнлектән, мине монда танучылар да очрады. Күңелле генә исәнләштеләр. Ә теге «артыш таякларын эшкә ябышыр күк күренә» дигән абый мине читкәрәк алып китте дә бик үз итеп хәлемне сораша башлады.

Мин аңа ике көн һәм ике төн эчендә башымнан кичкән бар мәҗараларымны сөйләп бирдем.

Абый башта көлде, аннары кинәт җитдиләнде.

— Беләсеңме нәрсә, туган, — диде. — Әйдәле, керик әле конторага. Булмый бу болай.

Һәм дәү кулы белән мине җитәкләп алып та китте.

Бу бүлмәдә минем турыда үзе кемнәрдер белән сөйләшкәч, ул абый мине икенче бер абый кулына тапшырды. Ул абый тагын кемнәрдер белән сөйләшеп, мине өченче абый кулына тапшырдылар... Шулай йөргән арада, бер бүлмәдә, беләсезме кемне очраттым? Владимир Петрович Керчинскийны!

— Абый! Мин бит сезне таныйм! — дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

Владимир Петрович кем беләндер бик җитди сөйләшеп утыра иде.

— Шулаймы? Мөмкин, бик мөмкин, — дип, миңа ялт кына карап куйды да әңгәмәсен дәвам итте.

Минем йөрәк дөп-дөп тибә, ә иреннәрне һич тыеп булмый, иреннәр колакка җиткән иде.

— Абый! Хәтерлисезме... Сез безнең авылда, Чагыл тавында нефть эзләдегез... Палаткагыз да бар иде... — дип, тотлыга-тотлыга сөйләп киттем мин. Аның бер колагына мин сөйлим, икенче колагына әлеге әңгәмәдәше сөйли иде.

— Шунда, хәтерлисезме, сезнең палатка янына бер малай килде. Килде дә... Чагыл-таудан мәтәлеп төшеп китте... Хәтерлисезме?

Владимир Петрович, теге як колагына сөйләүчегә «гафу итегез» дип, миңа бөтен гәүдәсе белән борылды.

— Тукта, тукта... Син Агымсудан мәллә?

— Шуннан инде...

— Самолет белән Казанга очкан егет?

— Әйе инде.

— Һәм... Ничего?.. Тазардын?

— Тазарды-ым!

Владимир Петровичның күзлек пыялалары ялтырап китте һәм шул ялтырау, әйтерсең, аның бөтен йөзен яктыртып җибәрде.

— Менә бит нинди очрашу! Ә без Надя белән гел сөйләшәбез, тазардымы икән ул егет, хәзер нишли икән, дибез. Надя миңа Агымсуга барып, сине эзләп-күреп кайтырга да заказ биргән иде әле... Вакыт тими бит... Бирегә нинди йомыш белән соң?

Мин үземнең нигәдер кызаруымны сиздем.

— Менә... Килгән идем әле... — дип мыгырдана башлаган идем, мине җитәкләп алып кергән абый үзе сөйләп китте.

— Эм-да... — диде Владимир Петрович, аның тагын күзлек пыялалары ялтырап куйды, аннары: — Одну минуточку, — диде һәм кызу-кызу күрше бүлмәгә кереп китте. Тиздән, — әллә чыннан да бер генә минут узды инде, — ул шулай ук кызу-кызу атлап килеп тә чыкты.

— Булды бу, — диде бик гади генә, — моннан соң син икенче промыселның өйрәнчек операторы. Хәерле юл, туган!

— Котлыйм, Хәйдәр! — дип теге абый да кулымны кысты.

Ә мин... Эзләгән сукмагыма житәкләүче бу кешеләргә чын-чын рәхмәтләремне белдерергә кирәк иде бит инде миңа бу минутта. Ә мин... Каккан казык күк бастым да калдым. Битләрем буйлап кайнар тамчылар тәгәрәде, борыным бик ачыттырып йомшарды...

Бәхеткә каршы, минем бу әрсез тамчыларымны тегеләр күрмәделәр. Һәрхәлдә, күрмәделәр дип үземне юатам. Ник дигәндә, алар бу вакытта мине кайсы бригадага һәм кем кулына өйрәнчек итеп тапшыру турында, кайсы тулай торакка урнаштыру турында бик житди сөйләшәләр иде.

Ләкин ул көнне өлешемә тигән бәхет көмешләрем болар белән генә дә бетмәде әле.

Жир мае сеңгән кара киемле яңа дусларым белән Әлмәт урамнарыннан күкрәк киереп атлап кайтулары да, тулай торакта минем үз койкам да — барысы да күңелемә көмеш тәңкәләр булып бер-бер артлы чыңлап төшеп тора һәм тулыр-тулмас бер көн өчен болар бик житкән дә иде инде... Шунда ишек ачылды да Владимир Петрович килеп керде. Хәлләремне сорашты һәм гади генә итеп әйтеп куйды:

— Безнең квартира да моннан ерак түгел. Әйдә бер әйләнеп кайтабыз.

Әйтәм бит, болай да инде күңелем тулы көмеш тәңкәләр иде минем, моннан соң да чыңлап төшкәннәре инде тулып аша башлады бугай... Шунысы бик истә. Надя, вак-вак бөдрә конгырт чәчләрен буш кына итеп күперенке толымга үреп куйган житеп килүче кыз, мине күрүгә, нәкъ инде моннан тугыз ел элекке кебек, нурлы итеп, сабыйларча итеп көлеп жибәрде.

— Ә мин сине тагын да зуррак үскәнсеңдер дип күз алдыма китерә идем. Менә мондый... — һәм кулын югары ук сузып, өстәвенә аяк очларына ук күтәрелеп, минем буем аңынча никадәр булырга тиешлеген күрсәтте.

— Ә мин сине... Нәкъ шушылайдыр дип уйлаган идем, — дидем мин. Дөресендә исә мин аны житеп килгән кыз итеп һичничек күз алдына китерә алмыйм, минем хәтергә аның давыл чәчәгенә ошаган башлыгы, кызыл-зәңгәр чәчәкле күлмәге һәм, барыннан да бигрәк, әнә шул нурлы итеп, йогышлы итеп көлүләре генә сеңеп калган иде.

Надяның әнисе Вера Ивановна бик тәмле чәй һәм аннан да тәмлерәк пирожкилар белән сыйлады ул кичне. Чәй янында өчәүләп минем тормышым турында, авыл турында сорашып утырдылар.

Стенада нечкә билле скрипка асылынып тора иде. Минем еш-еш аңа карап куюымны күреп булса кирәк, Надя озын гына бер көй уйнап күрсәтте.

Надяның скрипка кыллары өстендә бик житез йөгерә торган нәфис бармаклары, шулай итеп, минем күңелдәге көмеш тәңкәләр чынын матур бер көйгә дә салып бирде ул кичне. Бәхет жиле кагылган күңелгә шулай скрипка моңы да бик кирәк, бик тансык икән ул һәм шуннан соң инде ул бәхет жиле дигәнебез чын давылга ук әверелә икән. Якынлашып килгән бәхет давылы...

## 3

Ул еллардагы скважиналарны хәзергеләр белән чагыштыра алмыйсың. Хәзерге кебек, автомат кыргычлар, автомат япкычлар, скважинаның хәлен ерактан ук хәбәр итеп тора торган диспетчерлык системасы — берсе дә юк иде әле ул чакта. Нефть чыгаруда төп эшләр операторның беләк көченә, аның өлгерлегенә һәм тапкырлыгына тапшырылган иде. Барыннан да бигрәк, бар скважиналарның да гайрәтле фонтан булып аткан чаклары иде әле ул; хәзерге кебек, һәртөрле насосларның һич

кирәге юк, жир, әйтерсең, чын хужалар килүен бик зарыгып көтеп яткан да, инде менә куенындагы бу кыйммәтле байлыгын мул итеп бирергә ашыга иде.

Жир ашыга, ә кешеләр, дөресен әйтергә кирәк, бу байлык ташкынын жаен-әмәлен белеп кенә, әрәм-шәрәм итмичә генә алырга әзер түгелләр иде.

Дөрес, дөньяда тиңдәше булмаган безнең ул Тимәш нефть ятмаларын үзләштерешергә илнең төрле якларыннан нефть осталары килгән, эшнең иң авырын, төпкә жигелеп, алар тарта, ләкин төпкә жигелгән ул баһадирларга иңнәрен, жилкәләрен куеп тартышырга корыч беләкле, кыю йөрәкле ир-егетләр көннән-көн күбрәк кирәк иде.

Минем остазым Борһан Галиев әнә шул төпкә жигелгән баһадирларның берсе иде.

Бирегә ул Грозный нефть промыселларыннан килгән, ләкин үзе Татарстан туфрагында туып-үскән егет. Егерме беренче елгы ачлыктан качып, өй әчләре белән бер сынык икмәк эзләп чыгып киткәләр алар... Еллар үтә, Борһан ага байлыкны басулардан түгел, ә жир астында бик тирәннән табучы оста булып, туган якларына әйләнеп кайта.

Хәзер инде мәһабәт нефть каласы үсеп чыккан бу жирләрдә ялан кыр була әле ул чакта. Шул ялан кыр уртасында ялгыз такта будка. Квартира да шушы, промысел конторасы да шушы. Ләкин Борһан ага моңа бик шаккатмый. Аны шаккатырганы бүтән була. Биредәге беренче скважиналар тәүлеккә жиде йөз тоннадан да артык нефть бирә! Ә Грозный скважиналарыннан нибары бер ярым-ике тонна нефть алганнар алар, моның өчен әүвәле меңнәрчә тонна су суыртканнар. Ә биредә... Менә бит никадәр дә мул хәзинә, бетмәс-төкәнмәс байлык яшереп яткызган икән ич аның туган яклары. Менә нинди икән ич аның бер сынык икмәккә тилмереп чыгып киткән туган жирләре!

Скважиналар кабул итеп ала Борһан ага, шул скважиналардан нефть чыгаручылар бригадасының мастеры итеп билгеләнә. Бригаданың мастеры була, ә операторлары... Алар әле тирә-як колхозларда сабан сөрәләр, кайсылары әле, билләренә каеш буып, солдат хезмәте үтеп яталар.

Тиздән әнә шул кичәге сабанчылардан, кичәге солдатлардан бригада оеша. Оеша дигәч тә, бригада алай тиз генә оешмый әле ул. Бригада оешсын өчен, иң беренче, ул кичәге сабанчыларны һәм солдатларны өр-яңа һөнәргә өйрәтергә кирәк. Тагы да мөһимрәге — һәркайсы үз җукмагы белән килгән шул егетләр төркемен бердәм һәм дус коллективка тупларга кирәк.

Һәм өйрәтә, туплый Борһан ага.

Күпмедер вакыттан соң, Борһан ага мәктәбе үткән ул егетләрне яңа оешкан башка бригадаларга өлкән операторлар итеп күчерәләр. Борһан ага тагын кичәге солдатларны һәм сабанчыларны өйрәтә, туплый башлый.

Инде менә ничәнчемедер алмаш булып, мин дә Борһан ага мәктәбенә килеп кердем.

## 4

Хәзергә кадәр сәбәбен үзем дә төшенеп житмим, Борһан ага мине беренче көннәрдән үк нигәдер бик якын итте.

Хәер, «якын итте» дигәч тә, мин моны соңыннан гына сиздем. Ә беренче көннәрдә...

Бик кырыс мәктәп ул — Борһан ага мәктәбе.

Бервакыт шулай төнге сменада торуым. Ул чакларда һәр скважинаны, сменалап, өч оператор карый идек. Куәтле фонтан булып ага

торган ул скважиналарны аз гына да күзәтүчесез калдырырга ярамый, өстәвенә нефть чыгару юлына бик тиз парафин тыгыла, кул чыгырын әйләндерә-әйләндерә, аны гел арчып торырга кирәк иде.

Мин дә яңа гына кыргыч төшереп менгездем. Мерникны карадым. Манометрга күз салдым. Барысы да тәртиптә. Будкага кереп, вахта журналына тиешле саннарны да утырттым. Гадәттә, вахтада аз гына шулай буш вакыт эләктеме, кулыма китап ала идем. Бу юлы укый башлаган китабым онытылып калган. Кырын ятып, уй-хыял диңгезендә йөзеп киттем... Шундый да рәхәт-җиңел йөзеп барганда, кинәт кенә бик каты давыл чыкты. Дөньяның асты-өскә килә, нилэрдер үкерә... Ул арада өермәле җил мине әллә кая ук бөтереп алып менеп китте.

— Нефтең ташый! Будкаң-иең белән агып китәсең бит хәзер, төрткән нәрсә! — дигән тавышка уянып китсәм, чыннан да һавада асылынып тора идем. Борһан ага мине якамнан урап алып өскә үк күтәргән дә дер селкетә, үзе бик яман сүгенә иде.

Останың тимер кулларыннан ычкынуга, аткан ук кебек скважинам янына очтым. Тубык тиңентен нефть күлен ерып үтеп, задвижканы бора башладым. Юк, борылмый. Урыныннан да кузгатып булмый. Мыш-мыш киләм, кабаланам. Бөтен өс-башым, бит-кулларым нефтькә манчылды. Борылмый задвижка... Нефть күлен пыштыр-пыштыр кире чыктым да янгын шитындагы ломны эләктереп алдым. Борһан ага мине туктатты.

— Лом кирәкми монда. Мә, көрәк тот кулына.

— Нигә, Борһан ага? Лом белән хәзер борам мин аны.

— Икенче вакытта шулай итәрсең. Мин бордым инде аны. Хәзер, мә, көрәк тот та, чистарт бу боламыгыңны. Вахта алмашканда ялап алган күк булсын.

Ул төнне агызган җан тирләрем, ихтимал, тагын үзе бер күл булыр иде. Аның каравы, шул көннән бирле, менә ничәмә еллар, вахта вакытында керфекләргә ник кенә бер тамчы йокы эленсен!

Ә тагы да бер вакытта...

Борһан ага кичтән үк әйтте: иртәгә яңа скважина эшләтә башлыйбыз, билләрегезне ныграк буып килегез, диде. Аннары, бик тәфсилләп, моның өчен ничек хәзерләнергә, кайсыбызга нинди эш кораллары алып барырга кирәклеген аңлатты.

Иртәгесен бер генә сорады:

— Мин әйткәннәрнең барысын да алдыгызмы? — диде һәм, без «алдык» диюгә, китеп тә бардык.

Хәзер яңа скважиналарны эшләтә башлау промыселда гади бер эш булып калды ул. Техника һәм кораллар да бик бай хәзер, кешеләр дә бик остарды. Ә теге вакытта — сафка баскан һәр скважина безнең тормышта олы вакыйга иде.

Ул чактагы разведка скважиналары бер-берсеннән биш-алты чакрым ераклыкта. Тимер-томырларыбызны күтәреп, әлсерәп килеп җиттек. Борһан ага шунда гына әйтте:

— Я, карыйк әле, мин әйткәннәрнең барысын да алдыгызмы икән?

Һәм коралларыбызны берәм-берәм барлый, тикшерә башлады. Келт итеп исемә килеп төште: оста әйткән тагын бер ачкычны алмадым түгелме соң?

Борһан ага тавышына алай әллә ни борыч өстәмичә генә, әмма өздереп әйтте:

— Вәйт, төрткән нәрсә... Егерме минут вакыт сиңа, бар, алып кил. Живо!

Нихәл итәсең, очтым гына! Телемне җилкәмә элеп, ары-бире ун чакрымны мыш-мыш әйләнеп килеп житүгә, Борһан ага миңа, бер секунд та сулу алырга ирек бирмичә, нәрсәләрдер күтәрергә, нәрсәләр-

дер борырга кушты. Шул чакта аркадан күтәрелгән пар, ихтимал, кара мунча төтененнән һич ким булмагандыр...

Остаз әйткәннәрне арт ягың белән түгел, колакларыңны үрә торгызып тыңларга әнә шулай өйрәтте безне Борһан ага. Әмма ул сөйләгәндә колакларың чыннан да үрә торган икән, монда инде оста сиңа бер үк нәрсәне кырык кат аңлатырга, йөз кат күрсәтеп бирергә дә һич иренми; син аңа сорауларны никадәр күбрәк биргән саен, Борһан аганың тирәннән карый торган кечерәк соргылт күзләрендә ягымлы очкыннар да шул кадәр мулрак кабына бара аның.

Остазның ул еллардагы тагын бер сабагын һич онытасым юк.

Ул елны безне, яшь нефтьчеләрне, гүя табигать үзе дә кырыс сынау аша үткәрде. Декабрь башында ук ишелеп-ишелеп кар төште. Шуның артыннан ук күз ачкысыз бураннар башланды.

Салкыннар һәм бураннар хәзер дә әле нефтьчеләр эшен шактый катлауландыра. Ә теге вакытта, техникасы һәм кораллары да җүнләп житешмәгән, оешу-тәртип ягына да цементны яңа коеп килгән заманда, кинәт килгән мондый буранлы кыш безнең эшне тәмам чыгырыннан чыгара да язып куйды. Әледән-әле аварияләр булып тора башлады. Иң күп авария нефть җыю һәм товар паркларына үтә торган труба юлларда чыга иде. Күп кенә урыннарда андый трубаларны күмәргә дә өлгерелми калды ул елны, шуңа күрә, я салкыннан труба шартлый да нефть ага башлый, я каядыр труба эчендә парафин тыгылып, пробка хасил була иде. Кар бураны түгел, дәһшәтле зилзилә купса да, һәлакәтле урынны эзләп чыгып китәсең.

Гадәттә безнең Борһан ага пробка урынын булсын, труба шартлаган урынны булсын, эчке бер сиземләү белән әллә кайдан гына чамалап ала, шунлыктан безнең бригада кешеләре мондый җәфаны бүтәннәргә караганда шактый җиңелрәк кичерә иде.

Шулай да, бервакыт безгә дә чикләвекнең бик катысы эләкте.

Әйткәнемчә, декабрь буранының, яшь чыгымчы ат кебек, тәртәләр сындырып дулаган бер көне иде. Без, вахтадан буш өч егет, Борһан ага житәкчелегендә иртә таңнан бирле линиядә йөрдек — пробка эзләдек. Бөтен сөякләребезне шыкыр-шыкыр китереп будкага кайтып кергәндә, көн кичкә таба авышкан иде инде. Газ миче янына өелешеп, чәй кайнаганын көтеп утырганда, телефон шалтырады. Насосныйдан хәбәр: басым кими, каядыр нефть ага, диләр.

Борһан ага иң әүвәл тозлап-борычлап бер сүгенде. Аннары, маңгай җыерчыкларын бик хәтәр тирәнәйтеп, папирос кабызды. Папиросын бер-ике суырып ташлауга, урыныннан торды.

— Ярар, егетләр, сез чәегезне эчә торыгыз, — диде, — мин моннан ерак түгел бер шикле урынны беләм, шунда барып килим. Ярты сәгатьтән әйләнеп кайтмасам, каршыга чыгарсыз.

Хәзер дә әле, искә төшсә, колак яфракларына ут кабына. Өч егет, өч кусәк түгел диген, яше белән дә безгә эти тиешле остазыбызны, күзләребезне чет-чет итенгәләп, котырган буран кочагына, кара төнгә каршы япа-ялгызын чыгардык та җибәрдек шул. Мәнсезлегебез моның белән генә дә бетмәде әле. Боз күк тезләребезне мич җылысына терәп, берәр кружка чәй дә эчеп алгач, тәмам җебегәнбез. Ул арада борыннар да сызгыра башлаган. Мин үзем алай керфекләр ябышканын да хәтерләмим, әмма телефон шалтыраганнан аңыма килеп, сәгатькә күз салсам, Борһан ага чыгып киткәнгә бер сәгатьтән артык вакыт узып та өлгергән. Трубкада остаың тавышын ишетүгә, аркадан утлы кырмыскалар йөгереп узды. Әлегә инде хәзер, мәйтәм.

Ләкин трубкадагы тавыш гаҗәп тыныч яңгырады.

— Синме, Хәйдәр? Таба алмадым бит әле мин... Паркка кадәр життем, юк. Әйдә, Хәйдәр, егетләрне кузгат, булмаса. Мин каршыгызга атлыйм.

Әлбәттә, шунда ук тревога набаты кактым. Кирәкләребезне күтәреп чыгып киттек.

Ә буран тәмам йөгәнсезләнеп котыра.

Биш-алты әдым атлаган саен, кар көрәп, трубаны карыйбыз. Анна-ры тагын, тагын...

Буран котыра, минем эчтә дә әллә нинди җеннәр дулый. Бая Борһан аганы шушы гарасат эченә бирүзен чыгарып җибәреп, үзебез жы-лыда борын сызгыртып калганбыз икән, инде менә ничек тә шатлыклы хәбәр белән каршылыйсы иде бит аны. Шунсыз останың күзләренә ничек күтәрелеп карарсың?

Куллардагы шул кеп-кечкенә көрәкләр әллә ни арада тау-тау көрт-ләрне актарып ташлый. Буран да буран уйната, без дә буран уйната-быз.

Ул төнне актарган ул көрт тауларын, кайнар битләребездән, җил-кәләребездән аккан ул тир-су елгаларын кубометрларга сала башла-саң, ихтимал, әйтеп ышанмаслык саннар килеп чыгар иде. Әмма без барыбер үз дигәнебезне булдырдык — ул каһәр суккан тимер шартлап ярылган урынны таптык. Борһан ага сварщикларны да иярткел, безнең янга килеп җиткәндә, без, телләребезне бер карыш чыгара-чыгара иреннәребезне ялап, бик тәмләп буран суы эчеп утыра идек — тел очы-на буран учлап-учлап кар сибә тора, без ялый торабыз...

Шунда Борһан аганың безне карда тәгәрәтә-тәгәрәтә ничек шаярып йөргәнен күрсәгез икән!

Әнә шулай ул Борһан ага мәктәбе. Аның һәр сабагы күңел дәфтә-ренә ачы да, татлы да тир белән языла. Һәм — гомерлеккә!

## 5

Тагын шуны һич онытасым юк. Әле беренче көнне үк, Борһан ага миңа скважиналар күрсәтеп йөргәндә, бер агач төбенә хәл алырга тук-тады. Борһан ага папирос алып кабызды. Миңа да пачкасын сузды.

— Мин тартмыйм бит, Борһан ага, — дим.

— Анда укытучылардан яшереп кенә суыргансыңдыр әле. Инде парта арасыннан чыккач, ярый ул. Кабыз, әйдә.

— Юк, Барһан ага...

— Ә мин ышанмыйм. Яле, кесәләреңне әйләндер.

Мин буп-буш кесәләремне әйләндереп салдым.

— Юк, ышанмыйм! — ди Борһан ага һаман да.—Бүтән кесәңдәдер? Пиджәкнең дә ике ян кесәсен, аннары куен кесәләрен дә селкеп салырга туры килде.

— Алайса, шәп. Өйрәнмәгәч, өйрәнмә инде син аңа. Шәп! — диде Борһан ага. Үзенең йөзе һаман да бик кырыс иде.

Инде кайтып китәргә дип вахта машинасын көтеп торганда, Борһан ага миңе читкәрәк дәште.

— Ә шулай да... Фчетки, егет кешенең кесәләрендә җилләр уйнап торгач, бер дә шәп түгел. Мә, тыгып куй әле моны.

Һәм моңарчы мин кулыма да тотып карамаган зур-зур кәгазь акча-лар сузды.

— Кирәкми, Борһан ага... Менә бүген үк авылга кайтам да ашарга да алып киләм, акча да... Ә иртәгә иртүк эшкә килеп җитәм. Күрерсез...

Борһан ага шаркылдап көлеп җибәрде. Шундый кырыс кешенең бу кадәр дә күңелле итеп, якты итеп көлә белүе миңа бик гаҗәп тоелды.

— Вәйт, төрткән нәрсә, — диде ул күзләрендәге яшьләрен бармак сырты белән сыпырып алып. — Нефтьче егет әнигә акча сорап кайтсын,

имеш. Кайда күргәнең бар андый хәлне? Әгәр егетләр ишетсә, тотып дөмбәслиләр бит үзеңне.

— Дөмбәсләрләр микәнни?

— Ике дә уйламый дөмбәслиләр. Нигә нефтьче исеменә тап төшереп йөрисең диячәкләр. И дөрес тә! Бер кая жалу белән бара алмыйсың... Әниеңә хәлеңне әйтеп, бүген үк хат яз да, зарплата алгач, күчтәнәчләр белән кайтырсың. Монысы — аңарчы тота торырга. Тыгып куй. Үз жаең белән түләрсең әле бер. Әйдә, машина килде, киттек.

Дөресен әйткәндә, минем үземнең дә өйгә һич тә буш килеш кайтасым килми иде. Кайткач-кайткач, чын нефтьче кебек итеп кайтасы иде инде аны. Күчтәнәчләрең дә мул булсын, өс-башың да кеше күзен яндырсын, кибет яныннан узганда кесәң дә буш булмасын...

Инде менә авылга нәкъ шулай кайтырга да була. Беренче зарплата алуга, әлбәттә, иң әүвәл, Борһан агага әҗәтне түләргә дә калганына — киемнәр, күчтәнәчләр...

Ләкин барыбер ул көнне үк котәргә туры килмәде.

Бервакыт, көндезге сменага вахтага барырга чыккач, урамда Надя очрады. Ике иптәш кызы белән, сумкаларын асып, мәктәптән кайтып киләләр иде. Өчесе дә матур-матур бантиклы чәч толымнарын пальтолары өстенә чыгарып салганнар. Өчесе дә чәчәк күк чибәрләр.

Надя, мине күрүгә, иптәш кызларыннан аерылып, каршыма йөгерде. Өч-дүрт адым кала, кинәт туктады. Мин дә туктадым.

— Хәйдәр!

— Исәнме, Надя!

— Хәйдәр, син нигә бер дә безгә килмисең? Әни дә әйтә, нигә килми икән, ди.

— Минем эшкә барышым, Надя.

— Көн-төн эшлисең, бер дә бушамыйсыңмыни?

Бу сүзләрне шул кадәр чын гаҗәпсенү белән — зур ачылган коңгыртрак зәңгәр күзләре тулы, алсу бит алмалары тулы, ябылмый калган чия иреннәре тулы гаҗәпсенү белән сорады ки Надя, мин ирексездән көлеп җибәрдем.

— Бер дә бушамыйм шул. Көн-төн эшлим, — дидем мин һәм аңа таба атладым. Надя да көлде һәм урыныннан кузгалды. Янәшә атлап киттек.

— Эшең бик авыр түгелме, Хәйдәр?

— Эшем бик авыр, Надя.

Надя ялт итеп йөземә күтәрелеп карады: чыннан әйтәме, әллә шаяртамы?

— Алайса син чын егет түгел икәнсең. Зарланасың.

— Ә мин чын егет булырга тырышам, Надя.

— Күрмим.

Надяның чия иреннәре ачулы турсайды.

Бераз баруга, бу матур иреннәр бик якты елмаеп җибәрде.

— Хәйдәр, беләсеңме, әйдә иртәгә киного барыйк. Ял көне бит иртәгә. Әйдәме?

— Барырга була.

— Беләсеңме, Хәйдәр, без болай итик. Шулай кызык була ул. Хәзер... — Надя ашыга-ашыга сумкасыннан карандаш алды. Коймa буена килеп, багана турысындагы кеше күзенә бик бәрелми торганрак бер төшкә нәрсәдер сызгаларга тотынды. Мин дә якынрак килә башлаган идем, кулын селтәп: килми тор, янәсе.

Бераздан соң кул изәп чакырып алды. Килсәм, коймага шундый рәсем ясап куйган: зәңгәр диңгез дулкыннарында зәңгәр җилкәнле ялгыз көймә чайкалып бара, өстәрәк — зәңгәр болытлар...

— Күрдеңме? — диде ул, серле генә пышылдап. — Күрсәң, иртәгә нәкъ сәгать җидегә нәкъ шушы урынга килеп җитәсең. Шулай кызык була ул... Килештекме?

Һәм, минем җавабымны да көтмичә, йөгереп китеп тә барды.

Күбәләктәй җилпенгән ап-ак бантигы күздән югалганчы карап калдым.

Ак бантик чаттан борылды да югалды, әмма минем күз алдымда вахта буена җилпенеп торды әле ул.

Күз алдымда шулай ак бантик җилпенә, йөрәк бик рәхәт лепелдәп куя, ә күңелнең әллә кайсы гына кыллары авырттырып-авырттырып тартыла иде.

Әлбәттә, киләсе иде ул койма буена — зәңгәр җилкән янына. Карыйсы иде Надя белән бергәләп кино. Ләкин... Тишек ботинка, сүсәргән чалбар белән кызның күзенә ничек күренмәк кирәк?

Автобуста кайтканда күңелдәге наян мәче балалары, тәмам усалланып, тырнаша-тырнаша уйный башладылар.

Ак бантик, зәңгәр җилкән. Кино һәм... Сүсәргән чалбар. Ничек катлаулы бу дөнья дигәнең.

Чуалчык уйларым йомгагын Борһан ага өзде.

— Хәйдәр, иртәгә ял көне бит. Ниме... Синең Сигезенче март урамындагы кибеттә булганың юкмы?

— Юк, Борһан ага.

— Бүген ябылгандыр инде. Иртәгә ачылуына, фчетки сугыл әле син анда. Нәкъ сиңа яраклы ботинкалар, сиңа яраклы чалбарлар күргән идем мин анда... Ял көне бит иртәгә.

Яңакларыма кинәт кайнар кан йөгерде. Әллә минем бөтен уйларым йөземә язылган да, Борһан ага аларны шыпырт кына укып барды микән? Ләкин бит... Әҗәт акчасына киенүне күңел өнәми бит аны. Күңел өнәми...

Мин шул турыда сүз ачмакчы идем, ул арада автобус Борһан ага төшә торган тукталышка килеп тә җитте.

— Ярар, ялың күңелле үтсен! — диде дә Борһан ага автобустан төшеп калды.

## 6

— Хәйдәр, синең диңгез күргәнең бармы?

— Ба-ар!

— О! Кайсы диңгезне күрдең, Хәйдәр?

— Кара диңгезне, аннары Балтик диңгезен.

— Чынмы, Хәйдәр? Ничек бардың? Кайчан? Сөйләче.

— Җилкәмә биштәр астым, кулыма таяк алдым да таң беленә генә башлаганда юлга чыгып киттем. Көн бардым, төн бардым, бик күп авыллар, зур-зур шәһәрләр аша үттем...

— Гел җәяү бардыңмыни?

— Гел җәяү. Бара торгач, бервакыт дөм-караңгы карурман эченә килеп кердем. Әллә нинди куркыныч тавышлар ишетелә, кызыллы-яшелле утлар җемелди. Карыйм — каршыма ук шундый да зур соры бүре килеп чыкты...

— И-и, син шаяртып сөйлисеңдер әле. Барганың да, күргәнең дә юктыр диңгезне.

— Чыннан да күргәнем бар, Надя.

— Кайчан соң? Ничек? Син дөресен генә сөйлә.

— Иң дөресе шул: кинода күргәнем бар минем диңгезне.

Надя минем иңбашыма сугып алып, көлеп җибәрде.

— Алдакчы! Мин барып күргәнсеңдер дип торам.

Һәм Надяның шат күзләре моңсуланып калды.

Минә сәгатькә якын инде без клуб янындагы бакчада сөйләшеп йөрибез. Яна чалбарым кесәсендә — кино билетлары. Күңелем бик күтәренке. Надяның да алай моңсуланып калуы белән һич килешәсе килми.

— Ә синең, Надя, крокодил күргәнең бармы?

— Бар, зоопаркта.

— Мин зоопаркта түгел, үзебезнең Агымсу инешендә күрдем.

— Тагын алдыйсыңдыр әле.

— Бервакыт, ялгызым гына шул инешкә су коенырга төштем. Бик рәхәт кенә йөзеп бара идем, күрәм, камышлар арасында крокодил басып тора. Авызын шундый да зур ачып, мине йотып җибәрергә генә ыргылган иде, мин, аны-моны уйлап тормастан, тегенең авызына үзем атылдым да барып кердем. Атылып килеп тә кердем, крокодилның тамагына кулымны тыгып, тегенең йөрәген, үпкә-бавырларын йолкып та чыгардым. Крокодил мине тешләргә дә өлгермәде, үлде.

— Алдашып та карыйсың, — диде Надя һәм көлеп җибәрде. Минем аны гел шулай көлдереп кенә торасым килә иде.



## 7

Көннәрем гаҗәп бер серле киеренкелек белән үтә башлады. Мине алда һәрвакыт зәңгәр җилкән көтә — Надя белән һәр очрашкан саен, тагын ничәмедер көннән соң очрашырга дигән вәгъдәбез бар. Мин, төрле сәбәпләр табып, алдагы очрашу көнен мөмкин кадәр озаккарак билгеләргә тырышам. Сәбәбе — минем ул көнгә әзерләнәсем бар.

Иң беренче, Надя үзенең яраткан китапларының әчтәлеген сөйли башлап та, иң кызыклы урында гына туктап калырга бик ярата. Минем әнә шул китапларны табып укыйсым һәм икенче очрашуда нәкъ ул туктап калган төштән сөйләп китәргә әзерләнәсем бар.

Икенчедән, минем һәр очрашуга тагын да көчлерәк булып киләсем килә. Әлеге китек кашның яки шуның ишеләрнең яңадан очрап куюлары бик ихтимал иң...

Бүлмәбездә Виталий исемле бораулаучы егет бар безнең. Аю кебек көчле, бик оста спортсмен егет. Шул хәзер мине самбо көрәшенә, бокска өйрәтә. Бу өйрәнү кабыргаларыма, күкрәгемә, җилкә тамырларыма аллы-гөлле бизәкләр дә ясап бетерде бетерүен. Шулай да түзәм. Батыр ярасыз була димени? Һәр иртәне, Виталийдан күреп, маңгайдан тирләр акканчы, гантельләр күтәрәм. Виталий кебек, бил тиңентен салкын су белән юынам.

Бу тырышлыкларым бушка да китми иде, ахры. Беркөнне Борһан ага минем парафин кыргычы менгезгәнне әллә ни исе китмәгәндәй генә карап торды да гадәтенчә күзләре белән генә елмаеп куйды.

— Бик килеште сиңа нефть эше. Үз суына җибәрелгән балык кебек димме... Күзгә күренеп тазара да барасың.

Әйе, үзем дә сизәм — беләкләрем көннән-көн ныгый бара. Спорт турында Виталий биргән бер китапта мондый сүзләрне укыган идем: һәр ир-егет, даими рәвештә физкультура-спорт белән шөгыльләнсә, мускулларының көчен икеләтә арттыра ала, диелгән. Моңа минем башта ышанып та бетәсем килмәгән иде. Тормыш үзе ышандырды. Кайчан гына әле өстәл кырыена терсәкләрне терәшеп, кем кемнең кулын ега дип көчләр сынаша башласак, бүлмәдә күпләр мине җиңә иде. Инде

бик шаярмый торсыннар! Виталийдан кала, бүлмәдә икенче батыр хәзер абзагыз. Иптәшләреннән бер иңле кечкенә булып калган әлеге салам сыйраклы малай юк инде ул хәзер.

Виталийның сөйләгәне бар. Илдә иң көчле штангистлардан Леонид Жаботинский да, спорт белән шөгыльләнә башлаганчы, шундый ябык, хәлсез бер малай булган. Ә спорт әнә нинди могҗиза тудырган! Минем дә хыяллар зурдан...

Кичләрен исә, керфекләр керфеккә ябышканчы, кулымда Надяга сөйләячәк китаплар була. «Ты смешно говоришь по-русски», — дигән иде миңа Надя. Тагын да алай-болай ялгышмаслык итеп, матур итеп сөйләргә әзерләнәм.

Ә һәркөн эшкә барганда я кайтканда берәр хәйлә белән иптәшләрдән аерылып калам да әлеге койма буена — зәңгәр җилкән янына килеп басам. Кесәмдә һәрвакыт зәңгәр карандаш йөртәм — җилкән аз гына уңа башласа, яңартып буяп куям.

Надяның ни өчен анда зәңгәр җилкән ясаганын мин инде хәзер беләм. Александр Гринның «Алсу җилкәннәр» дигән хикәясеннән алган ул аны. Ул җилкәндәге Ассоль алсу җилкәннәр көтсә, Надя зәңгәр җилкән көтә...

Минем хыял уйный... Менә бер заман без Надя белән ерак диңгезгә таба озын сәфәргә чыгып китәбез. Нindидер мажаралар, ниндидер авыр көрәшләр аркасында аерылышабыз. Надя диңгез буенда зәңгәр җилкән көтә. Бик озак көтә, әмма гел ышанып көтә. Ниһаять, еракта зәңгәр җилкән күренә. Ул зәңгәр җилкәнле шхунаның капитаны — мин. Бик күп авыр көрәшләрдә җиңеп, Надяны алырга кайтып киләм...

Эш. Китаплар. Бокс. Аннары — зарыгып көтелгән очрашу. Надяның тагын сөйләнеп бетмәгән хикәяләре... Шулар белән атналар, айлар үтте. Кыш җитте. Алда әйткәнемчә, безне бик кырыс сынау аша үткәргән буранлы, аварияле, авыр кыш.

Ә язлар җиткәч, мине Бөгелмәгә алты айлык курсларга укырга җибәрделәр. Өлкән операторлар хәзерләү курсына.

— Син киткәч, миңа бик күңелсез булыр инде, Хәйдәр, — диде Надя.

— Ә мин ял көне саен кайтып йөрермен.

Надя беразга тынып калды.

— Юк, Хәйдәр, һәр ял көне саен ук кайтма.

— Нигә инде алай?

— Син, иң яхшысы, ике атнага бер генә кайт. Шулай кызыграк.

— Нигә инде алай?

— Шулай кызыграк була ул. Син бит... Ничек кенә аңлатырга... Син бит, Хәйдәр, һәр очрашкан саен күңеллерәк була барасың. Үсеп тә киткән сыман тоеласың. Син шулай күбрәк үс, күбрәк күңелләң дә, аннары очрашырбыз. Бер ял үтеп, икенче ял саен...

Күктә, нәкъ романнарда язганча, тулы ай йөзә иде. Һавада, шулай ук романнардагыча, яз исе, бөреләр исе, дымлы җир исе аңкый иде. Шул тулган ай, шул яз исе безне дә нәкъ шул романнарның геройлары итте дә куйды — мин Надяны беренче мәртәбә суырып үптем ул кичне.

Иртәгесен Бөгелмәгә китеп бардым.

Хәтеремдә, ул иртә — болытлы иде, бик ачы җилле иде, шыксыз иде инде.

Шәһәр дә миңа бер дә ошамады. Өйләре соры, автобуслары соры, мәчеләре дә соры.

Бөтен җаным-тәнем белән яратып өлгергән спорт шушы соры күңелсезлекне җиңәргә дә ярдәм итте. Аз гына буш вакыт булган саен шөгыльләнәм. Бүлмәдәш егетләрне дә котыртып өлгердем. Виталий кебек, аларны бокска, самбо көрәшенә өйрәтә башладым. Янәсе, мин дә тренер хәзер. Егетләрне дә өйрәтәм, үземә дә менә. диген күнегү була...

# Зәңгәр җилкән

## 1

Күңелем тулы өметләр, ашкынулы һәм билгесез өметләр белән алсу офыклы Әлмәт ягына чыгып китүемә дүрт ел тула дигәндә, мин яңадан туган авылыма әйләнеп кайттым. Юк, кунакка гына түгел, кунакка мин гел кайткалап йөрдем. Бу юлы үз авылыбыз тирәсендәге скважиналарның хуҗасы булып, әле җибәрергә өлгермәгән мыек чылгыйларына шактый гына акыл чорнап алган өлкән оператор булып кайттым мин Агымсуга.

Чагыл тавы башындагы әлеге имән багана турысында безнең якларда да беренче нефть вышкасы калкып чыкты. Куәтле фонтан булып аткан бу скважина үз иптәшләрен тиз тапты. Чагыл тавы итәге, Зәй елгасы, Агымсу инеше буйлап бораулаучылар Девон картның мул хәзинәсенә бер-бер артлы юл салып төшә башладылар.

Безнең тирәдә яңа нефть мәйданын үзләштерү башланды.

Тегәрҗеп урамының аргы башында, колхозның ферма каралтыларыннан ерак түгел, бик тиз арада өр-яңа таш биналар төзелде: контора, компрессор станциясе, мастерскойлар, гаражлар.

Авылыбызда яңа промысел оештырылды.

Яңа промысел, яңа нефть мәйданы үзләштерү... Ил байлыгына һәр көнне меңнәрчә тонна кара алтын өстәячәк бу эшнең шулай да никадәр катлаулы, кыен һәм мәшәкатьле икәнлеген, бар кешегә караганда да, ихтимал, безнең Борһан ага яхшырак белә торгандыр.

Зур нефть ятмасының беренче фонтаны аткан көннән бирле инде дистәләгән яңа мәйданнар үзләштерелде. Яңа мәйданнарда тәүге скважиналарны кем эшләтә башлады икән дип кызыксынырга тотынсагыз, бик еш безнең Борһан ага исеменә юлыгырсыз.

Яңа мәйданның уннарча километр еракльктагы ул разведка скважиналарын беренче башлап җиһазлау, көйләү... Юлсызлык... Әледән-әле һич көтелмәгән аварияләр... Барыннан да бигрәк, коллективны ныгыту, өйрәтү... Әнә шулар белән үткән тынгысыз көннәрдән, йокысыз төннәрдән соң, Борһан ага аз гына сулу алырга да өлгерми, аны Берләшмәгә чакырып алалар да әйтәләр:

— Бу мәйданны үзләштерүдәге хезмәтегез әйтеп бетергесез, Борһан ага. Инде менә тагын яңа мәйдан үзләштерәсе бар бит... Синең кебек бай тәҗрибәле оста куллар кирәк, — диләр.

Барысы да өр-яңадан башлана. Тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр... Инде менә эшләр юлга салынып килә бугай, дип кенә йөргәндә, Борһан аганы тагын Берләшмәгә чакыралар.

— Тагын да яңа мәйдан үзләштерә башлыйбыз бит, иптәш Галиев...

Һәр кыен эшнең үз остасы була. Мондый осталык, барыннан да бигрәк, шул эшне бөтен барлыгың белән яратудан килә торгандыр. Әйе, үз эшләренә чын гашыйклар гына хезмәт юлларындагы берниндн авырлыклар каршында да каушап калмыйлар, киресенчә, һәр каршылык, һәр кыенлык алдыйларда яңа көч, яңа дәрман гына үята; яңа кәрәшкә әйтеп аңлатып булмастай яңа бер олы илһамлану белән ыргылалар алдыйлар.

Безнең Борһан ага нәкъ әнә шундыйлар токымыннан.

Инде менә безнең Агымсу промыселының да беренче нефть мастеры булып Социалистик Хезмәт Герое Борһан ага Галиев билгеләнде.

Гадәттә, Борһан ага әнә шулай яңа алгы сызыкка күчкәндә уң кулы итеп берәр операторны да үзе белән ала. Бу юлы андый «уң кул» итеп Борһан ага мине алды. Җитмәсә, туган авылыма бит!

Агымсуга борынны зәңгәр болытларга аз гына терәп җиткезмәстәй югарылыкта тотып кайтты абзагыз...

## 2

Алай дигәч тә, сез мине авылыбыз урамыннан борынны чыннан да һавага бик хәтәр чөеп, бүксәне дугадай киереп атлаучы кукъ егет итеп күз алдыгызга китерә күрмәгез тагын. Акыл дигәнең бик усал бармак янап, андый фыртлыкны эчкә үк постырган яшерен горурлык кына иде бу миндә. Ә инде алай чак кына баш калкыткан эчке горурлыкка тулысынча хакым бардыр дип уйлыйм мин. Йөрәгеңдә авылыңа үзең дә аңлап бетермәгән ниндидер рәнҗү төйнәп, мыштым гына чыгып кит тә, инде менә бөтен тирә-юньнең җир асты байлыкларын табучы сихри һөнәр иясе булып, шаулап-гөрләп кайтып кер — күңел түрендәге ул горурлык дигән җанкисәгем ничек тыныч кына кала алсын ди монда?!

Аннары, тагын менә нәрсә бит әле...

Әнием белән Хәбирә апамның минем болай кайтуыма шатлыклары ничек тулып ашуын сөйләп тә торасы юктыр. Өрмәгән җиргә дә утыртмадылар үземне. Ул арада, урамга чыксам, канцелярия, клуб тирәсенә килсәм, авылдашлардан яше-карты чорнап ала, сорауларның игечиге юк.

— Алай нифте булгач, безнең авылда да Әлмәт кебек шәһәр салмаслар микән?

— Запасы күп микән ул нефтьнең безнең авыл тирәсендә?

— Басуларны бик ертып-казып бетермәссез микән инде?

— Кибетләр, яңа кибетләр дә кирәк, болай булгач. Син анда әйт әле,

— Яңа клуб та кирәк, җәмәгать. Яхшырак кино булса, болай да сыеп булмый хәзер иске клубка, нефтьчеләр дә килсә, бөтенләй баш тыга алмассың. Әйтми калма моны да...

Ул арада берәрсе читкәрәк дәшеп ала.

— Карале, дус кеше, шунда, нифте тирәсендә, миңа да берәр эш булмас микән?

Шулай «нифте тирәсенә» эшкә урнашырга теләүче авылдашлар шактый табылды. Шунысы кызык: андый теләге булганнар иң элек промысел мөдире Николай Ивановичка да түгел, идарәдәге кадрлар бүлегенә дә түгел, башлап миңа килеп мөрәҗәгать итәләр, миннән киңәш сорыйлар иде. Әлеге горурлык кыбыр-кыбыр үзен сиздерүенә шушы нәрсә дә сәбәп өстәде булса кирәк...

Кайткан көнне үк Исламгәрәй кордаш та чабып килеп җиткән.

Сүз җаеннан шунысын да әйтим әле. Бу вакытта Тегәрҗеп егетләреннән авылда без аның белән, Исламгәрәй белән, икәү генә калган идек. Мирзаһитны, Әбүзәрне һәм Сәхипне армиягә озаттык. Илгиз Казанда, авыл хуҗалыгы институтында укып ята. Исламгәрәйне, карт әтисе белән әнисе янында бердәнбер бала булганлыктан, армиягә алмадылар. Комиссия мине дә армия хезмәтенә яраксыз чыгарды. Әллә кайчан сынып тазарган умырткам да ошамады аларга, тагын әллә нинди сәбәпләр тапкан булдылар. Гарьлеге бөтен җанны актарып тулып ашты, әлбәттә. Ләкин нихәл итәсең?

Исламгәрәй белән кордашларны, үткәннәрне искә төшереп бик күңелле сөйләшеп утырдык. Шайтан малай, кесәсенә бер ярты да тыгып

килгән, әни почмак якка чыгып киткән араларда аны да төшергәләп алдык.

Күңеле урынында түгел иде Исламгәрәйнең. Тугыз класс белеме бар, ташып торган тазалыгы бар, ә менә бөтен җаны-тәне белән бирелеп эшләрлек кулында бер һөнәре дә юк. Берәр профмәктәпкә китеп, нинди дә булса һөнәргә ия булырга да бик омтылып караган да... Әлеге дә баягы, карт әтисе белән авыру әнисен калдырып китәргә вөҗданы җибәрми. Ат җигеп, фермага болыннан печән ташый, колхоз наряды белән урманда агач кисеп кайта икән. «Неужели мин шуннан бүтән бер эшкә дә ярамыйм инде», — ди егет, ачынып.

Тел төбен сизеп алдым моның.

— Әйдә, кордаш, безнең нефтькә,— мин әйтәм,— белгәннәрем уртак булыр, бергә-бергә җир селкетеп эшләрбез.

— Белмим шул, малай... Сиңа бер имгәк кенә булмам микән? — дигән була бу, үзенең күзләрендә, ташка баскан ат тоягыннан чәчрәгәндәй, очкыннар сикерешеп алды.

Шулай, ашап-эчеп, бергә-бергә җир селкетеп эшләү турында куллар да сугышып алгач, икәүләп клубка киттек. Яшьләр кичәсе иде клубта. Каян өйрәнеп алганнар диген, япь-яшь кызлар, егетләр, идән ярыкларына сөртенгәләп куеп, теттереп тә танцевать итәләр. Миңа калса, бу һөнәргә мине Надя өйрәтте. Кичәләрдә башка берәр кыз белән әйләнергә туры килсә, «син бик әйбәт йөртәсең» дип мактап та җибәрәләр үземне.

Бу юлы да шәһәрдән кайткан егет маркасын шактый югары тоттым шикелле. Һәрхәлдә, кайсы кызны танцыга чакырсам да, алай ялындырып тормадылар.

Шулай, әле бер кыз, әле икенчесе белән танцы әйләнгәндә, бик сәер бер нәрсә сиздем. Кемдер читтән генә күзләрен тутырып миңа карап тора кебек... Кызлар карашы — монысын да сизәм. Яратып, сокланып карый — күңел дигәнең анысын да әйтә. Ләкин кем соң ул? Сиздермәскә тырышып кына күзләрем белән никадәр эзләнсәм дә, ул карашны һич тота алмыйм.

Инде танцы әйләнүдән дә туктадым. Үзем егетләр белән шаян гына сөйләшкән булам, үземнең күзләрем һаман эзләнә.

Юк, очрата гына алмыйм ла ул серле карашны. Ә бит бар ул, бар! Һаман да миңа төбәлгән ул караш...

Ниһаять, очраттым. Янып торган шомырт күзләр иде ул. Мин карауга, ул утлы шомыртларны шунда ук тетрәнүле озын гына керфекләр каплап куйды.

Хәзер инде ул якка таба карамаска тырышам. Ләкин түзә алмадым, безнең күзләр тагын очраштылар. Озын керфекләр утлы шомыртларны шунда ук бөркәп куйдылар...

Әлбәттә, танылым мин ул кызны. Югары очның Хәтимә апа кызы Айсылу ич. Ни арада шулай үскән дә, ни арада болай җиләктәй пешеп өлгергән соң әле бу? Кайчан гына ялан тәпи йөгереп йөргән чәтнәби бер кызчык иде ләбаса.

Ах, бу кызларның сиңа төбәлгән серле карашы!

Мин үзем алай кыюсыз егетләрдән дә түгел түгелен. Һәрхәлдә, моңарчы чибәрләрнең чибәре каршында да әллә ни каушап калганымны хәтерләмим. Ә бу юлы... Әллә нәрсә булды миңа. Әнә бит, әгәр андый кыю һәм телбай егет икәнсең, көлемсерәп кенә ул шомырт күзләр янына килергә дә кызны шаян сүзләр белән күмеп ташларга, анннары танцыга чакырырга иде инде миңа. Юк шул, хәтта ул якка таба тагын борылып карарга да курка башладым. Йөрәк леп-леп килә, үземнең кызарып-кызарып куюымны сизәм, аякларымны болайрак бассам да, кулларымны тегеләйрәк куйсам да бик килешсез кебек...

Ул арада Айсылу бер иптәш кызы белән, култыклашып, йөгерә-атлый клубтан чыгып киттеләр.

Иркен сулап куйдым. Кулларым-аякларым да үзләренең гадәти иркенлегенә кайттылар шикелле.

Ләкин икенче бер мизгелдә шунысын да сиздем: клуб эче бөтенләй караңгыланып, күңелсезләнеп калды кебек. Түзмәдем, егетләргә сиздермичә генә мин дә клубтан чыгып тайдым. Юк, Айсылу артыннан чабарга, аның белән очрашу эзләргә дип чыкмадым мин. Җаныма урын таба алмыйча чыктым.

Күзнең бөтен тәнне рәхәт сафландырып җибәрә торган салкынча тын кичә иде. Читкәрәк китеп, рәшәткәгә сөялдем. Рәшәткә артында чәчәк клумбалары күренә. Караңгыда бик аерып булмый, инде шиңгәннәрме ул чәчәкләр, әллә күзгә кырауларга бирешмәгәннәре дә бармы? Бөтен күз угым түгеп шуларга карап торам.

— Нәрсә югалттыгыз, Хәйдәр абый?

Күтәрелеп карасам, әлеге иптәш кызы белән Айсылу басып тора.

— Юк, югалтмадым, таптым әле мин монда, — дим, — әнә бит, берниндн кырауларга да карамыйча, шаулап чәчәк атып утыралар.

Кызлар да, рәшәткә аша сузылып, чәчәкләрне карый башладылар.

— Чыннан да, карале, әй, — диештеләр.

Ул арада мин бик житез генә рәшәткә аша сикереп төштем дә, клумба өстенә иелеп, шиңмәгән чәчәкләр эзли башладым. Чыннан да, бар икән андыйлар. Ике чәчәк өзеп алып, рәшәткәдән кире сикердем.

— Моннан соң да кырауда туңарга бирмик без боларны. Кызлар күкрәген бизәп калсыннар алар, — дип, кызларның икесенә дә берәр чәчәк суздым.

Әллә инде шактый житез-матур килеп чыккан шушы кыланышым күңелемне үстереп җибәрдеме, аннары, Айсылуның «Хәйдәр абый» дип бик ягымлы дәшүе дә тәэсир итте булса кирәк, — минем баягы каушавым кинәт юып алгандай юкка чыкты.

— Их, кичләре дә кичләре соң! — дип, кызларны җай гына култыклап алдым да акрын гына атлап киттек.

Тагын, үзем дә аптырыйм, шундый сәер гадәтем дә бар әле минем. Кызлар белән сүз башлаганда беренче сүзләрне килешсезрәк әйтсәм, шунда ук сөйләшәсем килми башлый, алга табан җүнле сүзен дә таба алмыйм. Ә инде беренче сүзләрем шома чыкса, тәмам телем ачыла; остадан остарак әйләнгән телемне хәтта үзем дә туктата алмас дәрәҗәгә җитәм.

Бу юлы да шулай булды. Мин әй жорланып та такылдый бирәм, кызлар бик күңелле көлешәләр. Мин аның саен үсенеп китеп, борчак сибәм.

Шулай көлешә-шаулаша, иң элек Айсылуның иптәш кызын озатып куйдык. Бәхеткә каршы, Айсылулар өе дә минем юл өстендә.

— Хәйдәр абый, минем сезгә бер соравым бар иде,— диде Айсылу, икәү генә калгач.

— Әйтеп кара.

— Сезнең нефтьтә кызларга да эш табылмас микән?

— Нигә табылмасын! Теләгең генә булсын.

— Минем бик тә нефтьтә эшлисем килә. Нефть турында китаплар да укып чыктым инде.

— Бик әйбәт, Айсылу. Мин анда сөйләшермен. Бергә-бергә эшләрбез.

Шулай итеп мин ул кичне «бергә-бергә» сүзен тагын бер кат кабатладым. Анысы, бу әйтүем дә алай җилгә ыргыткан сүз генә булып калмады калуын. Ләкин... Бигрәк әллә ничек кенә төгәлләнде минем Айсылу белән ул кичтәге беренче очрашуым.

Капка төпләренә килеп житкәч, Айсылу, биегәндәй итеп кенә матур-нәфис сикергәләп артка чигенә-чигенә, миңа кул изәде.

— Хәерле кичләр, Хәйдәр абый, — диде. Күзләре, иреннәре әллә нинди сихри нур чәчеп елмая иде аның бу вакытта. Шушы нурлы елмаю тәмам исертте дә жибәрде мине.

— Их син, сылу Айсылу... — дип, үзем дә сизмәстән ашкынулы ыргылып, кызны кочаклап алдым. Кочагымда учтагы кошчык кебек кайнар тетрәнү тойдым, шашынып үбәргә үрелдем... Кошчыгым, бик кинәт талпынып, кочагымнан ычкынды.

— Нигә инде алай, Хәйдәр абый... — диде ул инәлүле өзгәләнеп һәм, куллары белән йөзен каплап, йөгереп китте.

Жылый иде бугай кыз...



## 3

Бер караганда, алай әллә ни дә булмады кебек инде...

Бик нечкә, бик хисчән һәм шактый уйнак бит ул яшь күңел. Минем әнә шул нечкә, хисчән һәм уйнак күңелем кыллары үземә төбәлгән серле карашка түзә алмады, тибрәнә башлады... Аннары, ай яктысында сихри нурлар чәчеп елмайган күзләр, иреннәр мине бер мәлгә бөтенләй дә исертте... Бары шул гына.

Бары шул гына... Ә бит синең Надяң бар. Очкыны күптән, бик күптән кабынып, соңгы елларда сүнмәс ялкынга әверелгән мәхәббәтең бар. Шулай булгач, синең алай күңелең кыллары тибрәнүенә ирек куярга, минутлык шашынуга бирелергә хакың бармы соң? Бармы хакың?

Дөресен әйткәндә, мин үз-үземә мондый сорауны менә хәзер генә бирәм аны. Ә теге кичне...

Капка шапылдап ябылуга, ничектер миңгерәүләнеп калгандай бераз шунда басып тордым да кинәт борылып китеп тә бардым.

Салкын жилгә битемне куеп күпмедер атлагач, тиле кеше кебек тын гына көлеп жибәрдем.

«Бер үптерүдән коты чыкты. Бигрәк сабый бала шул», — дим эчемнән генә.

Шунда күз алдыма Надя килеп басты. Ул да миннән көлә кебек иде... Надя, Надягөл! Аның белән, ичмасам, бөтенләй башкача иде.

Ә хәзер Надя еракта. Менә икенче елын инде Надя Мәскәү консерваториясендә укый. Музыка белгече булып чыгачак.

Еракта шул Надя... Бик сагындым, өзелеп-өзелеп сагындым мин аны. Әнә шулай артык сагынганга күрә дә, бүген күңелем кыллары ул утлы караштан бик тиз тибрәнә башлады микән әллә? Кем белә, бәлки, сагыну хисләремнең шулай үзенчә тулып ашуыдыр бу? Шулайдыр ул...

Шушы сәер фәлсәфә минем жанымны бик тиз генә урынына да утыртты ул кичне һәм мин тулысынча тыныч күңел белән кайтып йокладым.

## 4

Әлмәт промыселында безнең эшләр шактый юлга салынган иде инде. Барлык скважиналарда да автомат кыргычлар, автомат япкычлар эшли; әлеге скважиналарны ерактан торып кына идарә итә торган диспетчерлык системасы да көйгә салынып килә иде. Ул культбудкаларны курчак өе күк жиһазлап, тирә-ягына алмагачлар, чәчәкләр дә утыртып жибәргән идек.

Биредә әле боларның берсе дә юк. Көн саен диярлек бораулаучылардан яңа скважиналар кабул итеп алабыз, ләкин аларны заманча

итеп кенә эшләтер өчен электр да үткәрелмәгән, элемтәсе дә юк, труба юллар да җир өстенә генә салынган. Аннары, һәр скважинаның үз холкы, үз кирчегәсе[1] була — без әле шуларын өйрәнеп бетмәгән. Шунлыктан һич көтелмәгән аварияләр дә чыгып тора.

Борһан ага эшне шундый итеп оештырды ки, вахта сәгатьләрендә безнең бер генә минутыбыз да бушка узмый. Ләкин вахтадан соң да эш җитәрлек. Аварияләрне бетерергә чабабыз, кулга балта-пычкылар алып, культбудкалар төзибез.

Без иртәнге вахтага таралышырга контора янына җыелгач, Исламгәрәй астыртын гына янтыгыма төртеп куйды да, күзләре белән генә ымлап, каядыр күрсәтте. Күреп алдым: арырак, арба күчәре кебек зур-зур катушкаларга чорналган тимер чыбыклар, өем-өем ниндидер фанер яшикләр янында, Борһан ага йөренеп тора, үзе папирос артыннан папирос кабыза — берсен кабызып ничә генә суырып ташлауга, икенчесен кабыза иде. Очлы да соң Исламгәрәйнең күзе. Миңа исә Борһан аганың бу гадәте күптән таныш. Шулай папирос артыннан папирос кабыза башладымы — көт тә тор — оста ниндидер яңа эш башларга, безгә ниндер әйтергә җыена дигән сүз бу.

Шыпырт кына егетләрне җыеп алдым да, без дә шул тирәгәрәк туктап, нидер сөйләшкән булабыз. Менә Борһан ага тагын бер папирос суырып ташлады, төпчекне озаклап үкчәсе белән таптады да безнең янга килде.

— Булмый бит әле бу, егетләр, — ди. — Бу электрикларның кыймылдаганын көтсәң, тимер чыбыклары күгәреп, бар булган әйберләре череп бетә боларның. Әллә үзебез тотынабызмы бу эшкә? Юкса, әйтергә оят, егерменче гасыр уртасында тирләп-пешеп кул чыгыры әйләндерәбез. Булмый бит бу болай. Ничек уйлыйсыз, егетләр? Начальство белән сөйләшеп карыйбыз мәллә?

Тотындык без бу эшкә дә. Ял көннәрендә дә өмәләргә чыгабыз.

Шулай үтә көннәребез.

Ул арада Айсылу тагын бер эш уйлап чыгарды. (Ул хәзер бездә замерщица булып эшли, ягъни һәр скважина биргән нефтьнең бик төгәл исәбен алып бара.)

— Әйдәгез, үзәк культбудка янына быелдан ук алма бакчасы утыртып калдырабыз. Нигә безгә дә Әлмәтләрдән калышырга? — ди.

Монысына: «Хәзер вакыт юк, язга чыккач тотынырбыз», — дип карасак та, кыз үзе кичләрен күз бәйләнгәнче шунда көрәк тотып казына башлагач, безнең дә оятка көч килде. «Әйдә, җирен казып, чокырларын әзерләп булса да калдырыйк», — дип тотынган идек, бер кызып киткәч, будка салганнан калган такталардан әйләнәсен дә тоттык, бер егетне Минзәлә питомнигына җибәреп, үсентеләр дә кайтарттык. Хәзер инде «Айсылу бакчасы» дип йөртелә торган матур бакчага әнә шулай нигез салынды.

«Минем бик нефтьтә эшлисем килә», — дип юкка гына әйтмәгән икән ул кыз. Бик яратып, бик бирелеп эшли Айсылу үз эшен.

Теге истәлекле кичтә артыгын кыюланып киткәнем өчен миңа Айсылу алдында бик уңайсыз иде. Шуңа мин кыз алдында үземне бик әдәпле тотарга тырышам, культбудкага ул килеп керсә, берәр эш табып, тизрәк аннан чыгып ычкыну ягын карый идем.

Әллә нишлим, күтәрә алмыйм мин ул утлы шомырт күзләр карашын...

Аннары тагын әле менә нәрсә... Айсылуны күрүгә, минем хәтергә бер вакыйга килә дә төшә. Үз вакытында авылдашларның җаннарын айкап алган вакыйга ул.

[1] Кирчегә — каприз, кирелек.

Айсылуның этисе Зәйнәгытдин абый сугышның беренче елларында ук яраланып авылга кайта. Култык таягы белән йөрүенә карамастан, аны, кайтуына, колхоз председателе итеп сайлап куялар. Бик тырыш, бик тынгысыз һәм бик гадел кеше иде дип хәтерлиләр аны авылдашлар. Сугышның иң авыр елларында хуҗалыкны шактый төзек алып бара Зәйнәгытдин абзый. Ләкин күпмедер эшләгәч, аңа яңадан армиягә китәргә повестка килә. Юк, тәмам тазарып житкән, солдат хезмәтенә яңадан яраклы булганы өчен түгел...

Көннәрдән бер көнне колхозга районның зур житәкчеләре килә. Әлбәттә, хуҗалыкны карап йөриләр, теге-бу житешсезлекләр өчен председательне яхшы гына «пешереп» тә алалар, аннары күрсәтмәләр бирәләр. Иң соңгы «күрсәтмә» мондый була: тарантастагы печән астына күпмедер он, күпмедер бал һәм күпмедер май салып жибәрергә... Зәйнәгытдин абый мондый «күрсәтмә»не үтәүдән өзеп-кисеп баш тарта, кызып китеп, житәкчеләргә бик ачы сүзләр дә әйтә.

Иртәгесен үк Зәйнәгытдин абзыйга армиягә китәргә повестка килеп төшә.

Әтисе кулындагы таягын селки-селки сугышка китеп барганнан соң, ике ай тулар-тулмаста семьяда бишенче бала булып Айсылу дөньяга килә.

Сугыш беткән дигән шатлыклы хәбәр белән канатланып йөргән көннәрдә генә бу өйгә кара печатьле конверт килеп төшә: Зәйнәгытдин абзый соңгы сугышларда һәлак булган...

Дөньяга килгәндә үк шундый ачы язмышка дучар булган ул кызны минем аз гына да рәнжетергә хакым бармы соң, я?!

Ләкин шул ук вакытта... Теге кичне артык кыюланып китүем бик ямьсез чыккан кебек, инде болай эдәпле генә кыздан качып йөрүләрем дә әллә ничек, бер дә әйбәт түгел кебек...

Еш кына безнең киңәшмәләр, жыелышлар булып тора. Сөйләшеркиңәшер сүзләр күп, хәтта якалашыр дәрәжәгә житкән чакларыбыз да бар. Менә шундый чакларда артыграк кызып китә башладыммы, мин кинәт кенә үземә төбәлгән шул мөлдерәмә утлы карашны тоям. Кызган каным шунда ук үзенчә генә, салмак кына ага башлый, эмма күңелдә башка бер тынычсызлык — үзем дә һич төшенә алмаган авыртулырәхәт тынычсызлык уяна.

Нигә, нигә болай бу? Нинди серле көчләре бар ул утлы шомырт күзләрнең?

## 5

Шомырт күзләр... Шулай да, күпмедер вакытлардан соң, мин ул утлы караш астында алай ук дулкынланмый башладым шикелле. Киресенчә, алай дулкынланмас өчен бик хаклы эмәлен таптым. Ул эмәл дигәне — зәңгәр жилкән! Үземә төбәлгән утлы карашны тоеп алу белән, шунда ук зәңгәр жилкәнне күз алдыма китерәм һәм... Беләсезме, ифрат файдасы тия!

Зәңгәр дулкыннарда чайкалган зәңгәр жилкән... Бар, һаман да бар әле ул! Атнага дүрт мәртәбә мин ул зәңгәр жилкән янында үтеп китәм. Аз гына тоныклана башласа, һаман да шулай яңартып буяп куям.

«Атнага дүрт тапкыр» дим, чөнки мин атнага дүрт тапкыр Әлмәткә кичке мәктәпкә килэм. Быел кулыма өлгергәнлек аттестаты алырга тиешмен. Аннары, исәп — Мәскәү нефть институтының Әлмәттә быел ачылган кичке факультетына керү.

Зәңгәр жилкән!.. Надяның үсмер күңелендә үк уянган ул ашкынулы хыял минем дә хыялым, минем дә өметем, минем дә омтылышым ул хәзер. Әлбәттә, иңнәргә биштәрләр асып, зәңгәр диңгезгә таба озын

сәяхәткә дә чыгып китәрбез, мин Надяны зәңгәр җилкәнле көймәдә дә йөртермен. Бәлки, дингез буендагы ул очрашу бәхетенә бик күп каршылыклар, катлаулы мажаралар кичергәннән соң гына ирешербез... Үсмер чакның ул романтик хыялы да бик саф килеш. Инде шуларга өстәп, минем өчен зәңгәр җилкән бөтен тормышымда иң олы омтылышым символы булып тора хәзер.

Ә нәрсәгә омтылам соң мин?

Әлбәттә, бәхеткә омтылам.

Бәхетемнең иң беренче шарты нәрсә?

Ул — Надяның, Надягөлнең мәхәббәтенә тиң булу.

Әйткәнемчә, бар иде бит шундый көннәр... Мин Надя белән һәр очрашуга ничек тырышып, ничек ашкынып хәзерләнә идем. Ул очрашуга кадәр никадәр күп укып чыгасы китапларым була, тагы да көчлерәк, житезрәк буласым килә, эшемдә дә горурланып сөйләрдәй нәрсәләр булуын бик тели идем.

Хәзер безнең очрашу сроклары, ай-һай, ничек озынайды. «Укулар беткәч, ике ай практикада буласым бар, аннан соң гына зәңгәр җилкәнебез янына килеп житә алам», — дип яза Надя.

Аның каравы, ул очрашуга кадәр минем ирешәсе максатларым да бик күп.

Иң беренче, минем өлгергәнлек аттестатым иң яхшы билгеләр белән генә бизәлгән булырга тиеш (Надяга күрсәтәсем бар). Кичке нефть институтына кабул иту имтиханнарын тапшырып, кесәмдә «кабул ителден» дигән язу да булырга тиеш (анысын да Надяга күрсәтәсем бар).

Аннары, музыка белеме буенча бик күп китаплар җыйдым. Шуларны укып чыгасым, өйрәнәсем бар. Мәскәүдән, «Посылторг» аша, классик музыка язылган бик күп пластинкалар алдырдым. Шуларны кат-кат тыңлыйм. Кайберләре бик ошый, кайберләрен аңлап бетермим — шуның серенә төшенеп житәсем килә. Кыскасы, Надя белән музыка турында рәхәтләнеп уртага салып сөйләшерлек дәрәҗәгә ирешергә тиеш мин.

Болардан тыш та максатларым бар әле.

— Син, егет, мактанырга да яратасың бит,— ди миңа Надя. Үзем дә сизәм, бу гадәтемне тыя белергә өйрәнергә бик вакыт.

— Син артыграк тиз кызып китүчән, Хәйдәр. Бу гадәтең белән мине шүрләтеп тә куясың син, — ди аннары Надя. Бу кимчелегемне дә җиңәргә тиеш мин.

Бервакыт болай дип тә әйтте әле миңа Надя:

— Кыюлык белән ертлачлык арасында, туры сүзлелек белән әдәплелек арасында бик зур аерма бар бит, Хәйдәр. Кайвакыт син шуларны бутап та куймыйсың микән? Кыю булам дип, ертлачланып та китмисеңме? Туры әйтәм дип, әдәп дигәнен онытмыйсыңмы? Кешеләр белән мөнәсәбәттә такт дигән нәрсә бик кадерле бит.

Очрашкач, Надя үзенең бу искәртүе дә җилгә очмаганлыгын сизсен!

Минем бер китапта укыганым бар: кеше дүрт-биш ел эчендә үз характерын танымаслык итеп үзгәртергә сәләтле, тик моның өчен ихтыяр көче генә кирәк, диелгән.

Миндә андый ихтыяр көче бар дип уйлыйм.

О, зәңгәр җилкән! Алга, гел алга әйдәп тор син мине!

## 6

Тагын шунысын да әйтим әле: мин бит хәзер кесәмдә Ленин комсомолы члены дигән, минем өчен аеруча кадерле булган билет йөртәм. Әлмәт промыселында эшләгәндә кабул иттеләр. Әлбәттә, әтием турында да сорадылар. Аңа карап, каршы тавыш бирүчеләр булмады. Еллары да башка, рекомендацияләрем дә әйбәт иде шул.

Күптән түгел промысел комсомол оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды.

Җыелышларның төрлесе була бездә. Еш кына: «Ягез, тагын кем сөйли?» — дип кыстый-кыстый берәүне трибунага чыгаралар да, тегенең ык-мык килүен янсә бик шома газета сүзләре сөйләвен авызыңны ачып исни-исни тыңлап утырасың. Монысы трибунадан төшүгә, тагын: «Кем сөйли?» яки «Аңлашылды. Кыскартырга кирәк».

Ә була шундый җыелышлар, анда инде ораторларны колакларыннан сөйрәп чыгаруның һич кирәге юк. «Минем чират, миңа сүз бирегез», — дип, дистәләгән кул күтәрелеп кенә тора.

Безнең җыелыш та шулай сүлпән генә башланып китте. Әмма соңрак очкыннар чәчрәттек. Беренче очкынны, беләсезме, кем кабызды? Айсылу! Чәч бөртекләренә кадәр кызарып, кыюсыз гына чыгып баскан иде кызый, ул арада тегенең бит кызыллыгы теленнән ялкын булып сибелә башлады.

— Ут эчендә туган комсомолның шанлы ялкынын аз гына да сүндерергә хакыбыз юк безнең, хакыбыз юк! — дип, әй китте кызып, әй китте... Тәнкыйть угы килеп кадалмаган беребез дә калмады бугай. Шактый хәтәр нәрсә бит ул — тәнкыйть угы. Бер-беребезнең кимчелекләреннән башлап, промысел, идарә, хәтта Берләшмә җитәкчеләренә кадәр барып җитәчәк.

Яңа секретарь итеп тоттык та Айсылуның үзен сайлап куйдык. Сүзе белән очкын кабыза белгәнен күрсәтте, инде эше белән ул очкынны дөрләтеп карасын.

Район конференциясенә делегат итеп мине дә сайладылар.

Иртәгесен мин культбудкада вахта журналына көндәлек эшләрне язып утыра идем, ашыгып кына Айсылу килеп керде. Кызның сәламен алдым да, гадәтемчә, чыгып китәргә урынымнан кузгалдым. Айсылу мине туктатты.

— Рәфиков! Мин сиңа комитетның карарын җиткерергә тиешмен.

— Нинди карар?

— Безнең оешма исеменнән конференциядә чыгыш ясауны комитет сиңа тапшырырга булды.

— Әбиеңә сәлам әйт! Аз гына булса да ораторлык сәләтең бармы дип сорагыз сез иң элек.

— Беренчедән, тумыштан ук оратор булып тумыйлар, икенчедән, ничек сөйләгәнеңне күргәнебез бар. Өченчедән...

— Өченчедән, үз алабайларыбыз алдында бугаз киерү белән олы җыелышта чыгыш ясау арасында җир белән күк...

— ...Өченчедән, син комитет карарына буйсынырга тиеш, Рәфиков.

— Тагы да берәр «тиеш»не өстәсәң, аңлашылып җитә.

— Юк, өстәмим. Калганын үз вөҗданың әйтер.

Һәм Айсылу кинәт борылды да йөгереп чыгып та китте.

Башына күсәк белән тондырылган ишәк кебек, күзләремне чет-чет йомгалап басып калдым.

Шунда будкага Исламгәрәй белән тагын ике оператор егет килеп керделәр. Өчесе дә күзләрен миңа текәгәннәр, өчесенең дә күзләрендә миңа шелтә чагыла: янәсе, нигә Айсылуны үпкәләттең...

Миңа шушы шелтәле карашлар мине кинәт чыгырымнан чыгарды да җибәрде.

Исламгәрәй үзе минем алда, өлкән оператор алдында, гаепле иде ул көнне. Чыбыгы өзелеп, кыргычы скважинага төшеп киткән һәм анда бик уңайсыз яткан, ахры, нефть чыгу сизелерлек кимеде. Мин егетләргә әнә шуның өчен ябырылдым. «Ачык авызлар, оешып җитмәгән нәрсәләр...» Тагын, тагын әлләниләр. Хәзер инде кабатлап әйтергә һич телем әйләнмәс сүзләр дә әйтеп бетердем. Өстәл төя-төя кычкырдым:

— Шайтанның үзенә әверелеп, скважина төбенә төшеп менегез, үз хисабыгызга ремонтчылар чакырыгыз, әмма кыргыч иртәгә менә шушы өстәлдә булсын!..

Вахта ахырына кадәр гел шулай тузынып, сукранып йөрдем мин ул көнне.

Ә өйгә кайтып яткач, күздән йокылар качты.

Ничек болай килеп чыкты соң әле бу? Шушымы инде синең үз характерыңны төзәтү өчен тырышуың? Кайда монда такт дигәне, кайда монда үзеңне кызып китүдән тыю? Чүпрәк син! Ирешә алмаячаксың син үз максатларыңа. Тиң түгел син, болай булгач, Надяның мәхәббәтенә. Тиң түгел!

Баш капкачына, әйтерсең, ком-таш төяп тутырганнар, ә эчтә, күкрәк чокыры турында, нидер сулык-сулык сызлый иде.

Таң беленә башлады. Безнең өй түрендәге кечкенә бакчада минем күптәнге дусларым — кызылтүш белән кычыткан чыпчыгы чут-чут сайраша башладылар. Күптәннән сынаганым бар: балачакта ук мин ояларындагы күкәйләрен санап, җимнәр сибеп, мәчедән саклап йөргән ул кошлар сайраша башладымы, күңелләрем сафланып китә минем.

Бу юлы да шулай булды. Башларым җиңеләйде, бөтен барлыгым белән кошлар сайравын тыңлаучыга гына әверелдем.

Һәм кинәт бер нәрсәне бик ачык төшенеп алдым.

Күзләр, шомырт күзләр гаепле монда барысына да! Бүген бит ул күзләр миңа алай яратып, тутырып карамадылар. Бик кырыс һәм артык кырыс иде ул күзләр бүген. Аннары әле... Гадәттәгечә, бик ягымлы итеп, «Хәйдәр абый» дип тә дәшмәде бүген Айсылу, ә «Рәфиков та Рәфиков» дип, әллә нинди тимер тавыш белән сөйләште. Менә бит эш нәрсәдә икән!..

Ә нигә моңа шул кадәр дә кәефең китте соң әле? Харап булган, аңа бүген яраткан бал-маен каптырмаганнар, горчица ягып, кара ипи генә биргәннәр. Каян килгән иркә сабый бу?

Их, Надя! Характерымдагы игәүләп-чүкеп чын кешечә кыяфәткә китерер якларым никадәр күп шул әле минем.

Җиңә алырмынмы мин ул шыксыз гадәтләремне? Синең мәхәббәтеңә тиң булырдай дәрәҗәгә ирешә алырмынмы мин, Надя?

## 7

Искиткеч шәп чыкты, дип үк әйтә алмыйм, шулай да минем конференциядәге чыгышым алай начар булмады шикелле. Трибунага чыгып басканда тез буыннарымның, яңа туган бозауныкы кебек, ничек дерелдәвен, беренче сүзләрне әйткәндә, тавышым, тамакны ертып, яшь әтәчнекенә охшап чыгуын,— аларын исәпкә алып тормасаң да була. Ник дигәндә, соңга табарак тып-тын калган залда тавышымның шактый батыр яңгыравына үзем дә гаҗәпләнеп куйдым.

Миңа кадәр чыгып сөйләүчеләрнең, җитешсезлекләр турында борчылудан бигрәк, башкарган эшләре белән мактанырга яратулары сизелә иде. Мин алай итмәдем. Айсылу кебек, комсомол ялкыны турындагы сүзләрдән башлап киттем дә, тәнкыйть утын сибә башладым. Үз көчебез белән скважиналарга электр үткәрдек, ә Идарә диспетчерлык җиһазлары кайтартуны һаман да суза. Меңләгән-меңләгән тонна кыйммәтле газның факелларда янып әрәм булуы кайчангача кадәр дәвам итәр? Трубаларын, җиһазларын табуда ярдәм генә итегез, без авылыбыз өйләренә үз көчебез белән газ кертәбез. Авылыбызда яңа клуб, яңа магазиннар кирәк. Нефтьчеләрнең бик күп вакытлары юлларда үтә. Ул вакытны карта сугып түгел, файдалы итеп үткәрергә өйрәник — һәр вахта машинасында радио һәм китапханә булдырылсын. «Шешә пат-

ша» га каршы коралды восстание күтәрергә вакыт!.. Укларымны әнә шуларга төзәп аттым.

— Татарстанның яшь нефте язмышы, башлыча, яшьләр кулында. Безгә, яшьләргә, ныграк таяныгыз, безгә ныграк ышаныгыз! — диган соңгы сүзләремә, моңарчы сөйләүчеләрнең берсенә дә алай ук эләкмәгәнчә, гөрләтеп кул чаптылар.

Тәнәфес вакытында Айсылу яныма килде.

— Бик әйбәт сөйләдең, Хәйдәр абый, — диде. — Хотя... Мин аның шулай булачагына шикләнмәдем дә.

Тавышы элеккечә бик ягымлы янгырый иде кызның. Ләкин күзләре ничегрәк карадылар икән? Элеккечә, утлы итеп, матур итепме, әллә, беркөнге кебек, кырыс-шелтәлеме? Анысын әйтә алмыйм — күтәрелеп карарга көчем җитмәде...

## 8

Ул елны яз бик иртә килде. Әле апрель урталары гына, ә басулар инде кардан арчылды. Кар китүгә, нәкъ вакытын белеп кенә, җир давасы — җылы ләйсән яңгырлар явып үтте. Инде кашлак басуларда тракторлар гөрелтесе ишетелә. Мендәр-мендәр генә ак болытлы зәңгәр күктә сабан тургайлары үзләренең җиргә чиксез соклану-мактау җырларын сибәләр.

— Карабодай, житен-киндер кебек соңрак чәчелә торган игеннәргә ничек булыр, әмма арыш белән көзге бодайга бик шәп килде быелгы яз. Җирдә дым күп, җылы җитәрлек. Шуның белән уҗымнар ныгып калсалар, алга табан корырак җәйгә дә бирешми инде алар.

Игенче авылдашларның әнә шулайрак дип сөйләшкәннәре колагыма кереп калган. Аларның күрәзәләре ничегрәк туры килер, әйтә алмыйм, ә безнең өчен, нефтьчеләр өчен, мондый иртә яз — чын-чыннан табигатьнең зур бер бүләге ул. Скважинадан скважинага тез тиңентен былчырак ерып, ташу сулары кичеп йөрүдән дә җинел котылдык быел. Җылы көннәрдә нефть юлына парафин да аз тыгылачак. Шикләнмәскә мөмкин, бу кварталда планны шактый арттырып үтибез, болай булгач. Егетләрнең дә күңеле үсәчәк, — мактау сүзләре дә ишетербез, аннары, кара алтын ташкынын мулрак озаткан саен кесәләргә дә шәбрәк тама ич... Күңелләрнең шундый дәртле чакларыннан остарак файдаланып каласы иде. Скважиналар тирәсендә тәртип-чисталык иң үрнәк карабтагыча булсын, автомат кертүгә барысы да әзер торсын. Бүгенге кебек, нәбатны ныграк суккалап торсак, ул автомат җиһазлары кайтартуны да алай суза алмаслар... «Әйбәт сөйләдең», — ди Айсылу әйтә. Чыннан да, бу сүзләрне әйткәндә, ничегрәк карады икән ул шомырт күзләр?..

Юл чатында ук автобустан төшеп калдым да, тургайлар җырын тыңлый-тыңлый, шуларны уйлап кайтып киләм.

Кайгы — кайгы катына, шатлык — шатлык башына, диләр бит. Дөрес икән. Өйдә тагын бер зур шатлык көтә икән мине — эти кайткан!

## 9

...Менә ул, этием, минем каршымда утыра. Кара тут йөзе тагы да карала төшкән бугай. Аз гына эчкәрәк баткан яңаклары бүйлап ике бүй җыерчык дугайланып сузылган. Элек алар юк иде. Болай бик тыныч күренгән көңгырт күзләренә җентеклэбрәк карасаң, әллә нинди эчке кыбырсын чаткылар кабынып-кабынып китүен шәйләп аласың.

Инде очрашуның эле шатлыклы, эле моңсу дулкыннары чәпәләшкән минутлары узды. Әни белән Хәбирә апам да өстәлдә урын беткәнче тегесен-монысын ташыдылар-ташыдылар да чабышып йөрүдән туктадылар. Башланган ярты да өстәлдә тыныч кына утыра — эти үрелми, миңа килешми.

Сүз мондый вакытлардагыча фәлсәфирәк төс алды. Күбрәк, әлбәттә, эти сөйли:

— Нифте эше белән китүеңне бик хуплыйм, улым. Бик хуплыйм! Нәкъ синең эш бу. Ягъни мәсәлән... Ничегрәк аңлатырга соң?.. Тормыш үзе синең юлыңа китереп бастырган эш бу. Рас тормыш синең алга шушы эшне китереп куйган икән, синең аны әйләнеп узарга хакың да юк иде. Әйләнеп узсаң, үз юлыңнан читкә тайпылу булыр иде бу. Аңлата алам микән?

— Аңлыйм кебек.

— Болай бит. Синең эле буразна исен чын ләззәте белән иснәргә дә, үз маңгай тирең тамган бөртекләрне учыңда агызып карарга да өлгермәгән бер чорда шушы нифте эше килеп чыккан. Әлбәттә, күңелеңне жилкеткән синең бу эш. Җилкетмичә хәле дә юк. Нәкъ жилкенер чакларың. Өстәвенә, мин беләм бит... Япь-яшь кенә җилкәңә нужа бабай да кулын салып өлгерде... Бик дөрес эшләгәнсең, улым, бу юл белән китеп. Болай, яратасыңмы соң эшеңне? Җаның тартып эшлиме?

— Бик яратам, эти.

— Алайса, нык тот син бу юлыңны. Көченне аямыйча ябыш бу эшкә. Үкенмәссең. Бөтен җанын бирердәй үз эшен табучылар бик бәхетле булалар. Һәркемгә дә тәтеми мондый бәхет. Әйе. Ә менә минем өчен... Дөресен генә әйткәндә, минем өчен бик кулай түгел икән бу нефть эше. Бүген менә шуны сиздем мин.

— Нигә алай дисең, эти?

— Шулай дим шул... — Эти стаканга аракы салды. — Әйдә, чеметеп кенә кабып алабыз мәллә?

Күтәрдек.

— Түбән очның Зәйнәгытдин кордаш бар иде минем. Сугыштан кайтмады, мәрхүм. Хәер, бер кайткан да булган, яңадан китkәч башына житкәннәр. Хәтерләмисең микән?

Мин үземнең кызарып китүемне сиздем.

— Хәтерлим. Култык таякларын аршынлап-аршынлап атлатып, каядыр ашыгып баруы әле дә күз алдымда.

— Ашыккандыр. Нәселләре белән шундый иде алар — тынгысызлар, кайнарлар һәм гаделләр. Ярмәкиләр нәселе. Барысы да авылда иң беренче кул игенчеләр иде. Хәтеремдә, әле аерым хуҗалык вакытында ук боларның басуында иген, әллә кайдан күз угыңны алып, каерылып та уңып утырыр иде. Әнә синең белән уйнап үскән Илгизнең этисе Әюп шулар нәселеннән инде. Илгиз — молодец, этисе юлы белән киткән, агроном булырга укый икән. Без монда сөйләштек инде. Әгәр нәселдән ук килгән шундый эш бар икән, аннан тайпылырга ашыгырга кирәкми бер вакытта да. Иң элек көчеңне шунда сынап карарга, аннары гына... Бу эшкә нигәдер кулың ябышмый, күңелең утырмый икәненә тәмам ышангач кына, бүтән бер җан тарткан эш эзли башларга кирәк икән. Мин бу турыда шуның өчен сүз ачуым... Ни бит... Әйт әле, улым, синең нәселеңнең шундый төп эше нинди, беләсеңме?

— Ничек дим... Мин синең, эти, сельпо председателе булып эшләгәнеңне генә беләм.

— Менә шул шул! Мин монда Зәйнәгытдин кордашны юкка гына искә төшермәдем. Әйтәдер иде Зәйнәгытдин мәрхүм: жир ул, диер иде,

үз байлыкларын теләсә кемгә бирми, җирнең аның һәр пышылдавын, һәр сулышын аңлый белергә кирәк, гашыйк булырга кирәк җиргә, диер иде. Әгәр дә инде син җирнең сулышын тыңлый белмисең икән, гашыйк түгел икән син җиргә, лутчы азапланма син аны, кулыңа башка бер һөнәр тап, диер иде. Менә бит! Ә мин... Мин дә бит, улым, җиргә гашыйк идем, аңлый идем мин аның пышылдауларын! Әмма ләкин... Аерылдым мин җирдән. Сугыштан кайткач, буразнага килеп баш имәдем, сәүдә эше белән киттем...

Әти авыр гына сулап куйды да тынып калды. Мин ни әйтергә дә белми идем. Нигә сүзне болайга борды соң әле ул? «Нефть эше миңа кулай түгел икән», — дип башлаган иде бит...

Әтинең күзләрендә баягы чаткылар кабынып алды.

— Зәйнәгытдин кордаш тагын әле болай диер иде: игенче эше дөньяда иң хак, иң изге хезмәт, диер иде. Бу сүзләрне дә, ай, бик иска төшерергә туры килде. Сәүдә эшендә дә хаклык эзләдем мин. Эзләдем, әмма... Ак эт бәласе кара эткә дигәндәй, үзем гаепле булып калдым. Аларны сөйли башласаң... Юк, сөйләргә кирәкми дә. Ахыры болай булып киткәч, хәзер минем сүземә барыбер ышанмыйлар. Бәлки, улым, син дә ышанмыйсыңдыр әле. Ярар! Берәүне дә ышандырырга теләмим мин.

Сүзсез генә стаканнарны күтәрдек.

Әти тагын авыр гына сулап куйды.

— Бу турыда бик күп уйладым инде мин, улым. Би-ик күп уйладым. Ул сәүдә эшенә моннан ары гомеремдә дә яңадан кире кайтасым юк. Шуның өчен дә, язган хатларыгызда безнең якларда нефть чыга башлавын укыгач, күңелемә беркетеп куйдым: тотам да, мәйтәм, кайтуга шул нефть эшенә ябышам. Буразнадан барыбер аерылдым инде, дим, игенчелек хәзер белемле агрономнар да механизаторлар кулында. Ә нефть эше әле ул яңа, минем кебек өйрәнчекләр дә күптер анда, дим. Әнә шундый ният белән кайткан кеше идем мин, улым. Ләкин... Юк икән, кулай түгел икән миңа нефть эше. Күңелем утырмаячак минем ул эшкә. Юк!

— Нигә алай дисең, әти?

— Шулай дим... Кайтып күрешкәч, басуларга чыгып киттем. Нигә чыктым мин анда? Белмим. Аякларым үзләре шунда таба алып киттеләр. Борыныма дымлы җир исе килеп бәрелгәч кенә, күзләрем ачылып киткәндәй булды... Их, ул җир исе, тамыр сүлләре исе!.. Аңлыйсыңмы икән син моның бөтен ләззәтен? Тоя беләсең микән син моның никадәр кодрәтле көчен?

— Беләм дип уйлыйм мин...

— Ай-һай, белеп бетерәсең микән? Алайса, әйт әле син миңа шуны. Ул Чагыл буе басуында нигә уҗым таптап машина юлы салдыгыз? Төбәк басуында, җир куенын актарып, траншы казып үткәнсез дә, кызыл балчык белән ком-ташларны өскә әйләндереп салып, күмеп киткәнсез. Нигә болай мәсхәрәлисез җирне? Ул ком-ташта нәрсә үсә хәзер? Басу уртасында ындыр табагы чаклы тимер-бетон ватыкларыгыз, күгәргән тимер-томырларыгыз аунап ята. Нефть түгелеп, кара көйгән төшләрне дә күрдем. Нигә болай? Әйт әле син шуны?

— Беренчедән, әти, безнең, добытчикларның гына түгел, буровикларның, вышковикларның, электрикларның да гаебе зур. Икенчедән, без һәр карыш чәчү җире өчен колхозга тиешле хакын түлибез. Өченчедән...

— Ә-ә-ә... Аңлашылды. Артыгын сөйләмәсәң дә була. Безнең бер тонна нефть бер тонна икмәктән кыйммәтрәк, дип тә әйтмәкче буласыңдыр әле. Безнең нефть бөтен машиналарның азыгы, нефть ул — җылылык, яктылык, кием-салым, дарулар, тагын әллә ниләр, фәлән-фәсмәтән...

— Нигә, эти, алары да дөрес ич.

— Алайса, тәмам аңлашылып бетте. Алай салкын кан белән аклана алгач, салкын кан белән исәп-хисап йөртә белгәч, булды — аңлашылды. Ә мин... Мин булдыра алмыйм алай! Шуңа төшендем мин бүген. Ул кызыл балчыклы транши эзләрегез җирнең канлы җәрәхәте кебек күренде миңа. Утырып җыларга житештем...

Эти кинәт сүздән туктап калды.

Тәрәзә артында тынмас төн кошы — кызылтүш чут-чут сайрап куйды.

— Тегендә бер врач белән дуслашып киттек. Кеше ялгышмый торамы, нидер булган, әмма болай бик акыллы кеше иде. Миңа шуның бер сүзе искә төште. Һәркем дә чын врач, бигрәк тә, чын хирург була алмый, дигән иде ул. Чын врач, чын хирург булыр өчен кешене иң олы ярату белән яратырга, ләкин дәвалаганда һәм операция вакытында бу олы яратуыңны бик нык яшерә дә белергә кирәк, дигән иде. Бәлки, чын нефтьче өчен дә шулайдыр ул. Җирне бик олы ярату белән яратырга һәм кирәк чакта ул яратуны яшерә дә белергә...

— Чыннан да, эти...

— Ә мин алай булдыра алмамдыр, тәгаен. Сезгә җиңелрәк ул. Әйтәм ич, син әле буразна исен чын ләззәте белән иснәргә дә, маңгай тирең тамган бөртекләрне учыңда агызып карарга да өлгермәгән. Сезгә җиңел. Ә мин... Юк, булмас миннән...

Кызылтүш сайравын тыңлап, беразга тын гына утырдык.

— Инде менә уйлыйм-уйлыйм да һич очына чыга алмыйм... — Эти тагын туктап калды. Күзләрен базык бармакларына текәгән, гүя уйларының очын бик тырышып шуннан эзли кебек иде. — Нишләргә соң миңа хәзер? Җиргә кайтыр идем, агроном да, механизатор да түгел мин, нинди генә җүнле эш тапсыннар ди миңа? Нефтькә китәр идем — җан тартмый. Сәүдә эше турында әйткән дә юк... Нишләргә соң миңа?

— Бәлки, эти, иялнеп китәр идең әле... Нефть эшенә дим...

Эти, һаман да бармакларына караган килеш, үз уйларына батып утыра бирде.

— Ярар, бу куллар үзенә эш тапмый калмас. Куллар эш тапса, җан да тынычлык табачак. Бары тик шулай гына!.. Әйдә, ятыйк булмаса. Дөньялар тыныч булсын да авыру-сырхаулар ябышмасын. Калганы... Әйдә, ятыйк.

## 10

Без еш кына зарланырга яратабыз: төткәзер хәл юк бу вакытны, су урынына ага да тора, дибез.

Ага инде ул вакыт. Гомеребез елгасы шулай һич туктамастан ага.

Ләкин ничек ага? Кеп-кечкенә чуер ташларны да кузгатмыйча челтерәп кенә, сай гына булып агамы? Әллә зур-зур кара ташлар актарып, тирәннән үк ургып, шаулап, гөрләп агамы?

Мактанып әйтүем түгел, мин үз гомерем елгасын алай мәгънәсезгә челтерәп агучы сай һәм көчсез елгаларга чагыштырмас идем.

Елганың көче тамчылардан җыела. Кеше гомеренең тирәнлеге мәгънәле һәм файдалы үткән сәгатьләр һәм көннәр тыгызлыгы белән үлчәнә. Никадәр мәгънәлерәк, файдалырак үткәрә икән кеше үз вакытын — ул шул кадәр көчлерәк, дигән сүз, минемчә.

Көчле булырга! Һәм физик, һәм рухи яктан көчле кеше булырга! Алда әйткәнемчә, мин үз алдыма мондый максатны бик яшьләй үк куйдым.

Шуңа омтылып яшим.

Зәңгәр җилкәнем гел шуңа әйдәп тора мине.

Зәңгәр җилкәнем әйди, мин омтылам. Ләкин... Нигә соң күңел һич тә канәгать түгел?

...Уйлап баксаң, кайбер нәрсәләргә ирештем дә кебек инде.

Ике кулыма да икешәр потлы герләр алып, эһ тә итмичә унбиш мәртәбә күтәрәм.

Кулыма өлгергәнлек аттестаты алдым.

Эшемдә дә яраталар үземне. Аннан да бигрәк, үзем эшемне бик яратам.

Эш хакым да әйбәт. Премияләр дә еш эләгә. Әти хәзер колхозның төзү бригадасында эшли. Кичләрен Исламгәрәйнең әтисе Хәкимулла абзый белән үзебезгә өй бурасы бурыйлар. Исәп — иркен итеп, кухнясыннан кала, тагын өч бүлмәле итеп салырга өйне. Һәркөн эштән кайткач, кулыма балта алып, мин дә картларга булышам.

Киим дисәм киемнәрем күп, тегендә-монда барыйм дисәм мотоциклым әзер тора.

Инде менә, шушылардан соң да, тагын нәрсә җитми соң миңа? Нигә күңел һаман тынычлык таба алмый?

Надя! Бик тә сагындым шул мин сине! Күңел шуңа юксына, шуңа үземне кая куярга белми йөрүем микән әллә?

...Ул көнем дә нәкъ гадәттәгечә башланды. Иртән сикереп торуга, физзарядка ясарга керештем. Аннары, ишек алдына чыгып, гер күтәрдем, бил тиңентен салкын су белән юындым — болары да күптән көндәлек гадәтемә керде.

Ашап-эчкәч — эшкә китәргә сәгатьтән артык вакыт бар иде әле — чыгып, бура янындагы кичәге йомычкаларны җыештырдым, бакчада алмагач төпләрен йомшарттым.

Эштә дә вакытым гадәттәгечә үтте. Ике скважинада нефть чыгу юлын парафиннан чистарту өчен ППУ, ягъни парлагыч машина, чакырткан идек. Килделәр, ләкин бик озак машиналарын кабыза алмыйча азапландылар. Тел очына бик ямьсез сүзләр килеп җиткән иде, шунда ук эчемнән генә санарга керештем. Иллегә кадәр санагач, ул ямьсез сүзләрнең акрын гына эри башлавын сиздем. Ул арада тегеләр дә машиналарын кабыздылар.

Күптән түгел кабул итеп алган бер скважина тирәсен тигезләргә-чистартырга бульдозер сораган идек. Әйтелгән вакытка Исламгәрәй белән шунда барсак, бульдозер әле килмәгән. Исламгәрәйнең анда-монда эше юк, яшел чирәмгә сузылды да йокымсырап тик ята. Ә минем тагын яңак мускулларым сикергәли башлады. Әрле-бирле йөренергә тотындым.

Юк, һаман да килми бульдозер.

Кулыма көрәк алдым да эшкә тотындым. Бер көрәккә монда ай буена җитәрлек эш бар, шулай да маташам — күңел ярсуын басам. Исламгәрәй көлә, тешемне кысып, аңа да түздем.

Ниһаять, бульдозер тавышы ишетелә. Килә...

Мин тагын эчемнән генә саныйм.

Булмады. Ычкындым...

Бульдозер килеп туктауга, үземне белештермичә, кычкырып җибәрдем:

— Хәзер үк борыл да эзеңне тайдыр моннан! — мин әйтәм. — Син анда каядыр чумара эшләп йөрисең, без монда... Күземә күренмә, кит! Простой өчен дә, безнең наряд өчен дә кесәңнән түләрсең, чумараңны да косарсың. Бар кит!

Бульдозерчы егетнең дә чигә тамырлары бүртеп чыкты, шулай да тавышын күтәрми.

— Савельев бригадасында тоткарландым, иң элек тикшер син, аннары кычкырырсың, — ди.

Тәки бик ямьсез әйтешеп киттек. Ахырдан шулай килештек: әгәр чыннан да чумара эшләп йөреп кичексә, егет теләсә нинди җәзага да риза. Әгәр инде Савельев бригадасында тоткарлануы дөрескә чыкса, миннән — бер ярты.

Кул сугыштык та, егет эшкә тотынды. Шайтан малай, үз эшенең чын остасы икән, ни арада скважина тирәсен футбол мәйданы кук итеп матурлап та куйды.

Минем конторада йомышларым бар иде, шунда киттем. Савельев та анда икән, сораштым. Бульдозерчы Коляның әйткәннәрен раслый бу. Тагын бер егеттән сораштым — хаклык алар ягында.

Эчтә нәрсәдер чәнчеп-чәнчеп алды. Тота-каба дары кук кабынып китү гадәтеңне кайчан җиңәсең инде син, булдыксыз адәм! Чүпрәк син, чүпрәк! Характерымны төзәтергә тиеш мин, дип үз алдыңа максат куеп йөрүләрең — буш куык кына синең. Булдыксыз җан!

Кинәт үземә төбәлгән таныш утлы карашны тоеп алдым. Айсылу баскыч төбендә кемнәрдер белән сөйләшеп тора, үзенең күзләре миндә: «Әйе, булдыксыз егет син, тота-каба кеше намусын рәнҗетергә ни хакың бар синең? Ни хакың бар!» — дия кебек иде ул бу шелтәле шомырт күзләр дә.

Коля белән Исламгәрәй дә килеп җиттеләр. Кесәмнән акча чыгардым да, егетләрнең күзләренә күтәрелеп карамыйча гына, Коляга суздым.

— Гаеп миндә икән, туган. Мә, үзегез карагыз инде, минем вакытым юк, — дим.

— Юк инде, без акчадан түгел, яртыдан сөйләштек, — ди Коля, авызын ерып.

Исламгәрәйнең кашлары исә кырыкка сынды.

— Син нәрсә, кордаш! Кешене бер рәнҗеттең, инде тагын нигә кабат мыскыл итәсең? Сез бәхәсче, мин шаһит — яртыны өчәү бергә сындырырга тиеш без. Законы шундый!

Рас «законы шундый» икән, карышмадым. Киттек. Исламгәрәйләрнең кечкенә бакчаларына кереп утырдык та, закускага тутәлдән үк кыярын, суганын өзеп капкалап, күңелләрдәге ямьсезлекне юып төшердек.

Шушының белән тәмамланса, монда барысы да «законлы» гына була иде кебек инде... Юк шул, тәмамланмады.

Минем исәнләшергә дип сузган кулымны Исламгәрәй ике куллап эләктереп алды.

— Дөрес сүзгә хәтерең калмасын, кордаш, борынны чөя башладың син. Масая башладың. Бергә аунап үстек, инде бергә эшләү бәхетенә дә ирештек, әмма күңелләр бергә түгел безнең. Их, бергә түгел. Безнең белән бергә утырырга да хурланасың син хәзер.

Мин, әлбәттә,аклана башладым. «Бүгенгә вакытым юк, икенче бер утырырбыз әле, — дим. — Беләсең ич, кызу чакларым. Институтка имтиханга әзерләнәсем бар, бурачыларга ярдәм итәргә кирәк. Аннары...»

Исламгәрәйнең кашлары бу юлы кырык тугызга сынды.

— Дусны дус итә белмисең, шуңа күрә вакытың да юк синең. Әгәр безне дус итсәң, бер ял көнне бөтен бригада җыелышып килер идек тә ялт итеп күтәреп тә куяр идек бураңны. Менә, Николай да килмәс идемени?

— Бик шатланып! Әйтсен генә... — ди Коля да.

— Бер ял итеп алгач, имтиханга әзерләнергә дә яхшырак кына була ул. Монысы да юк сәбәп, — ди Ислай. — Монда чын сәбәп бер генә: дус итмисең.

Дус итмисең... Бу зур, бик зур сүзне Исламгәрәй дөрес аңламыймы, әллә мин үзем ялгышаммы?

Ни генә булмасын, күңелем кинәт балавыздай йомшарды да китте. Керфек төпләремә үк килеп җиткән күз яшемне көчкә генә йотып өлгердем...

Тагын бер яртыны алып кайттык. Аннары тагын бугай...

Әнә шулай төгәлләнде минем ул көнем.

Хәер, ничек төгәлләнүенең кайбер якларын мин иртәгесен генә, сөйләүләр буенча гына белеп бетердем әле.

Минем тәмам булуым җиткән. Көчемне күрсәтү өчен Исламгәрәйләрнең баскыч төбендәге кечерәк сандык кадәре ташны кубарып алып, ишек алды буйлап күтәреп йөргәнмен. Егетләрне берәм-берәм читән аша ыргытканмын. Бармак юанлыгы тимерне ишеп маташканмын... Болары тагы бер хәл әле... Мине ничек тә урын өстенә яткызгач, Исламгәрәйгә бәйләнәм икән: «Айсылуга әйтәсе сүзем бар, алып кил Айсылуны. Йокысыннан уятып булса да, алып кил. Мине дус итсәң, алып кил», — дим икән.

Ух, искә төшерүләре үк оят...

Әйе, көчле кеше булырга омтылам мин. Әмма бу көнем... Минем бөтен көчсезлегемне ачты да бирде бу көнем.

Тизрәк кенә кайтып җитсәң икән инде, Надя!

## II

Җитте ул көн.

Һәм һәр көтелгән очрашу кебек, һич тә көтелмәгәнчә булды ул.

Скважиналарга өр-яңа автоматлар куеп, диспетчерлык пунктын җиһазлап, мәш килеп йөргән көннәр иде. Өстәвенә, мин институтка керү имтиханнары биреп йөрим, көннәрем шул кадәр тыгыз үтә, күңелдәге әлеге канәгатьсезлек хисе баш калкытырга да өлгерә алмый кала иде.

Шулай да эчке контроль дигән нәрсә кинәт кенә сорап куя:

— Я, Надяның лаеклы каршылау өчен көчеңнән килгәннең барысын да эшләденме соң әле? Тиң була алырсыңмы син аңа?

Күңел шунда ук җавап бирә:

— Алдашасың юк, чын-чынлап көчле кеше булырга ерак әле сиңа. Төптәнрәк уйлый-хисаплый башласаң, һаман да мәгънәсезгә үткән вакытың күпме... Характерыңда да үзгәрешләр, ай-һай, бик аз сизелә...

Скважиналарны әйләнеп, будкага таба кайтып килешем иде. Юлда эчке контроль үзенең нәкъ шул соравын кабатлады да, юл буе үземнең соңгы атнадагы мәгънәсезгә үткән сәгатьләремне, характерымдагы чатаклыкларымны берәм-берәм бик рәхимсез хөкем итеп кайттым.

Үткән эшкә салават, ни кылсаң да үкенмә, дигән сүз дә бар барын. Үкенергә кирәкми, әлбәттә. Ләкин кылган һәр ахмаклыгыңнан чын үтемле сабак ала белергә дә кирәктер.

Эчке хөкемемне шушындый карар белән очлап куеп, будка ишеге тоткасына үрелдем. Шунда йөрәк бик ачы-рәхәт сулкылдап куйды. Надяның кайтыр вакытлары да җитеп килә бит... Менә хәзер телефоннан Владимир Петровичка шалтыратсам, нишләр икән? Надя турында сорашмыйча гына, әлбәттә. Болай, хәл белешеп кенә... Бәлки шунда, сүз җаеннан, Владимир Петрович үзе берәр хәбәр ычкындырыр?

Шушы уй белән ишекне йолкып чыгарырдай итеп тартып ачып, эчкә атылдым. Атылып килеп тә кердем, аякларым кинәт тартышкандай, идән уртасында бастым да калдым.

Түрдәге кечкенә өстәл янында Надя утыра иде.

Әйе, Надя... Ләкин кайда соң синең иңбашларыңа ук төшеп торган дулкын-дулкын бөдрә чәчләрең? Минем гел төшләремә керә торган, исерткеч исләре күңелемә ук сеңгән ул тылсымлы толымнарың кайда? Әлеге «по-мальчишески» дип йөртелгәнчә кыркылган бу кыска чәч... синекемени инде ул, Надя?

Иң беренче күземә ташланган нәрсә, башымда яшен тизлеге белән чагылып узган беренче уй әнә шул булды.

Надя урыныннан торды. Әллә миңа гына шулай тоелды микән — күтәрелеп каравына, күзләрендә нигәдер бик усал, нигәдер шелтәле очкыннар чәчрәп киткәндәй булды. Аннары озын керфекләр тетрәп куйды да, кыз елмайды. Ах, бөтен дөньясын зәңгәр-якты нурга күмә торган бу елмаю! Монысы инде Надяның нәкъ үзенеке, бары тик аныкы гына иде. Болай елмайган көйгә, аңа шул «по-мальчишески» кыркылган чәчләре дә ничек килешеп тора иде.

— Надя!.. Ничек инде... — Мин тәмам башым әйләнеп, телем тотлыгып, алга ыргылдым. Кызның кулыннан тотып, үземә таба тарттым да ашкынып кочаклап алырга омтылдым. Надя икенче кулын минем күкрәгемә терәде.

— Чү-чү! Нефтькә батырасың ич мине, Хәйдәр.

Үземнең майлы эш киеменнән икәнем шунда гына исемә төште. Аннары, авызын ерып, Исламгәрәй дә шунда утыра икән — аны да хәзер генә күреп алдым.

— Мин 221 гә киттем, иптәш начальник, — диде дә Исламгәрәй, ничектер әрсез елмайган иреннәрен һаман да җыеп бетерә алмыйча, будкадан чыгып китте.

Менә ул, ел буе диярлек зарыгып, сагынып көтеп алган минутлар. Менә ул, минем Надям — минем мәхәббәтем, минем бәхетем, минем омтылышым — каршымда басып тора. Менә ул, бармак төпләре уймак-уймак аз гына батыбрак торган, сокланып туймаслык нәфис-нәни кул минем учымда. Мин һәр бармак төбе уймакларын шашып-шашып үбәм, ул чиксез кадерле кулны сак кына күтәреп алып, яңакларыма куям.

— Надя, синме инде бу? Мин һаман да ышанып бетә алмыйм әле. Өнем микән, әллә төшем микән бу?

— Төш кенә булсын иде шул...

— Нигә алай дисең, Надя?

— Төштә йөрәгеңә пычак кадасалар да үлмисең. Авыртмый да... Ә өндә...

— Ә өндә без пычак күтәрүчеләргә каршы көрәшә дә беләбез.

Нәфис-нәни куллар минем аю тәпиедәй кулымны кысып куйды.

— Анысы дөрес, Хәйдәр. Тик менә...

— Тыңлыйм һәм аңларга телим, Надя.

— Кешеләр кайвакыт бер-берсен пычаксыз да суялар...

— Коточкыч сүзләр сөйлисең син, Надя. Аңламыйм.

— Аңларга кирәкмәс тә. Просто, мин җүләр сүз башладым. Әйдә, Хәйдәр, чыгыйк әле моннан.

Җәйнең шактый салкынча көне иде. Иртән бәреп-бәреп яңгыр да явып үтте, хәзер җил нефть түтенедәй авыр кара болытларны каядыр читкә куа.

Надяның практика дигәне бер пионер лагеренда балалар оркестры оештырудан гыйбарәт булган икән — шуларны сөйләп бара. Рухланып, кечкенә шәкертләрен бик яратып сөйли Надя. Ләкин мин аның сүзләрен җүнләп ишетмим. Бу матур иреннәрнең һәрбер хәрәкәте, көңгырт-зәңгәр күзләрнең, ихтимал, мин генә күрә торган һәр нуры, Надя, бары тик Надя гына шулай булдыра ала торган бу горур-йомшак адымнар — барысы да шул кадәр сагынылган, боларны яңадан күрү бәхетеннән хәтта минем йөрәгем бик авырттырып-авырттырып кысылып куя.

— Надя, нигә син шул кадәр сөйкемле?

— Бу комплиментыңны ишеткәнем бар инде, Хәйдәр.

— Нишлим соң? Сокланып туя алмыйм да телемнән үзеннән-үзе ычкына.

— Тагын шулай кемнәргә үзеннән-үзе ычкына икән ул сүзләрең?

— Мөмкин булмаганны сөйлисең син, Надя.

— Ярар, Хәйдәр, мин кайтыйм инде, эшеңне бүлдереп йөрмим.

— Надя, хәтерлисеңме, син әйтә идең: һәр очрашкан саен үзгәрә, үсә барасың дия идең миңа.

— Бик шатлыклы үзгәрешләр иде ул.

— Зинһар, мактана дип уйлый күрмә, Надя, мин сине тагы да зуррак үзгәрешләр белән каршыларга омтылып яшәдем. Ун классны тәмамладым, хәзер институтка имтихан тапшырам. Физикадан гына бирәсем калды, аннары мин дә синең кебек үк студент булам.

— Студент та булырсың, бик зур инженер да булырсың әле син, Хәйдәр. Боларына мин ышанам.

— Ышанычың өчен рәхмәт, әлбәттә. Ләкин жиңәсе кимчелекләрем дә бик күп әле минем.

— Үз-үзеңә тәнкыйть белән каравың бик әйбәт, Хәйдәр. Ләкин... һичнинди тәнкыйть, бернинди ихтыяр көче белән дә җиңеп булмый торган нәрсәләр дә бар...

— Нинди рәк кыяфәттә инде ул... андый җиңә алмаслык дошман?

— Ул — йөрәк хисләре, Хәйдәр.

— Кызык, — дидем мин, ә үемда чагылып үтте: «Алайса, ул дошман миңа куркыныч түгел икән. Минем йөрәк хисләрем сиңа гына омтыла, Надя». Шушы уемны матуррак итеп әйтү өчен, туктап, кызның кулларыннан тотып алдым. Шулчак будка ягыннан егетләрнең мине чакырып кычкырулары ишетелде. Бер скважинага агымдагы ремонт үткәргә барырга тиеш идек, шуңа кәтәләр булса кирәк.

— Ярый, Хәйдәр, мин кайтыйм, эшеңне бүлмим.

— Кичкә зәңгәр җилкәнебез янында мин сине көтәрмен, Надя.

— Анда килеп йөрмәсәң дә була. Әйтергә онытканмын, әни сиңа үпкәли, бер дә күзгә-башка күренми, ди. Бәлки, килеп чыгарсың?

— Киләм, Надя. Вахта бетүгә очып килеп җитәрмен.

Асфальт юлга чыгып, мин Надяны бер узучы машинага утыртып җибәрдем дә егетләрем янына йөгердем. Йөгереп барам-барам да, малай чаклардагы кебек, мәтәлчек атып куям — бәхетем ташый иде.

## 12

...Ни сөйлиләр бу сихри авазлар? Баштарак, алар колакка гына барып җиттеләр. Колагымны ягымлы авазлар иркәли, күзләрем Надяның клавишалар өстендә йөргән җитез-нәфис бармакларын гына күрә иде. Менә салмак кына агылган көйнең көтелмәгән бер борылышы йөрәкнең әллә кай җирен генә чеметеп алды. Җиңелчә генә башым да әйләнеп китте бугай... Хәзер инде мин музыканы ишетмим, күңелем белән тоям; юк, тоям сүзе монда көчсез — тетрәнәм, сулыйм, яшим...

Ниләр сөйли соң бу сихри авазлар?

Моны, әлбәттә, сүзләр белән аңлатып бирүе мөмкин түгел. Әле кайчан гына бер китапта укыганым уйда чагыла: «Әгәр дә кеше җанын айкаган бар хисләрне дә сүз белән аңлатып бирү мөмкин булса, ул чакта дөньяда музыка да булмас иде», — дигән олы музыка белгече һәм композитор Серов.

Болар шулай хәтернең кайсыдыр почмагында чагылып кына уза да онытыла. Сихри авазлар мине бөтенләем белән бөтереп ала, күтәрә, каядыр алып китә... Кая очам, кая омтылам? Бик олы, бик зарыгып

кетелгән бәхетемә якынлашам түгелме?.. Һәм менә һич кетелмәгән яңа бер аһәң яңгырый да мин тагын җиргә төшәм. Җиргә төшәм, ләкин җиңелмим. Бар ул дөньяда бәхет! Аңа омтылудан һичвакыт арымаска кирәк; омтыла белеп омтылырга һәм яулый белеп яуларга кирәк ул бәхетне. Күңел тыелулы гына ярсый. Әйе, тыелулы ярсый, чөнки күңел кайчандыр беләкләргә бирер өчен шулай көч җыя булса кирәк.

Тагын өр-яңа аһәң... Ләкин нигә моңысы бик шөбһәле яңгырый? Тынычсыз кисәтү дә, ниндидер шүрләү дә, шунда ук армас өндәү дә ишетелә. Аннары тагын омтылу, тагын кисәтү һәм тагын өндәү...

Надяның бармаклары инде клавишалар өстендә сихри очынудан да туктады. Ул кулларын аска ук салындырып, башын аз гына артка ташлап, тын гына утыра.

Ә мин һаман да әле ашкынулы һәм кисәтүле, шөбһәле һәм омтылулы авазлар дөньясында гизәм.

Менә Надя миңа таба борылды, оялчан гына елмаеп куйды. Аннары коңгырт-зәңгәр күзләр шунда ук җитдиләнде. «Я, барып җитте микән сиңа минем тел белән әйтеп биреп булмый торган уй-хисләрем?» — дия кебек иде бу күзләр.

— Бетховенмы бу, Надя? — дип сорап куйдым мин.

— Әйе, тынгысызлыгы, гел алга ыргылуы белән Бетховенга бик аваздаш.

— Алайса, Шопен?

— Шопендагы шигъри нәфислек тә яңгырый.

— Наданлыгым кечле шул минем, Надя.

— Скрябинның уникенче этюды бу. Ре-диез-минор... — Надя бу сүзләрне бик акрын гына, хәтта пышылдап диярлек әйтеп куйды.

— Мин бит, Надя... Музыканы я радиодан, я пластинкадан гына тыңлыйм. Бу этюдны беренче ишетүем.

Надя кара түгәрәк урындыгын зыр әйләндереп пианинога таба борылды да музыканың әлеге шөбһәле яңгыраган өлешен тагын бер кабат уйнап алды.

— Мәскәүгә барсам, мин көн саен Чайковский исемендәге концерт залына йөрер идем, — дидем мин, башыма әле генә килгән уйны шулай кычкырып әйтеп.

Надя моңсу гына елмайды.

— Нигә? Йөрерсең дә... Йөрерсез дә әле.

— Гафу ит, Надя, мин синең белән бергә димәкче идем.

Шул чак бүлмә ишеген шакыдылар. Вера Ивановна килеп керде.

— Яшьләр, әйдәгез, чәй эчеп алыйк.

Залга чыктык. Уртадагы түгәрәк өстәл шунда ук игътибарымны җәлеп итте.

Өстәл түрендә болын-кыр чәчәкләреннән зур гына букет көлеп утыра, вазадагы алмалар, һәркайсы иң алсу битләре белән балкып: «Мине ал, мине ал», — диячләр кебек иде. Берничә төр варенье салынган матур-матур савытлар һәркайсы кызгылт, куе кызыл, тагы да куерак кызыл нурлар чәчә — ихтимал, алар электр яктысы чагылсын өчен махсус шулай куелганнардыр.

Гомумән, бу өйнең һәр җиһазында нечкә зәвык сизелә. Әнә ян стена буендагы сервант өстендә агачтан юнып ясалган аю баласы күзләрен түгәрәкләндереп утыра. Шул аю баласы гына, бүтән бернинди бизәкуенчык та юк. Әмма шул гаҗәпкә калган аю баласы менеп утырмаса, ул сервант бүлмәгә алай ямь дә бирмәс иде кебек.

Владимир Петрович та бүлмәсеннән чыкты. Аның белән кул юарга ванный бүлмәсенә кергәч, андагы чисталыкка һәм пөхтәлеккә дә исем китте. Ничек өлгерә ул Вера Ивановна боларга? Музыка мәктәбендә укыта, клубларда, мәктәпләрдә музыка түгәрәкләре дә алып бара бит. Әллә, кайткач, Надя шулай җыештырынды микән?

Утырыштык. Вера Ивановна кухнядан, матур зур тәлинкәгә өеп, пирожкилар күтәреп чыкты.

— Бик матур уйнадың, Надя, — диде ул. — Тик менә дүртенче тактны югарырак алдың шикелле.

Надяның бит алмалары алсуланып китте.

— Мин, әни, ул урынны үземчә уйнарга теләгән идем. Үземчә мәгънә салып...

— Алайса, аңлашыла.

— Мин сезнең ул нечкәлекләрегезне үк сизеп бетермим, әлбәттә, — диде Владимир Петрович. — Ләкин миңа бүген, Надя, синең уйнавың бөтенләй көтелмәгәнчә тәэсир итте.

— Ничегрәк, әти?

Владимир Петрович, әле миңа, әле хатыны белән кызына карап алып, сөйләп китте.

— Һәркем күрә, һәркемнең эче поша... Күпме газны факелларда яндырып әрәм итәбез бит. Бу кыйммәтле чималны скважиналардан кире җир асты куышлыкларына куу турында күптәннән сүз бара. Бу проектта минем дә өлешем бар. Бүген Берләшмәдә тагын шушы мәсьәләне карадык. Министерстводан да кеше бар иде. Ләкин — юк! Һаман да хәл итеп бетерелмәгән кырык сәбәбе чыга да тора. Шунлыктан өйгә коточкыч нервыланып, изелгән кәеф белән кайтып кердем. Һәм менә... музыка! Тормыш көрәштән гыйбарәт. Бирешмәскә, аз гына да көрәштән туктамаска! Скрябин миңа шундый рухны сиздерми генә йөрәккә салды да куйды.

— Скрябин, моннан кырык еллар элек, бу этюдын язганда, синең ул киңәшмәңне, нефть газларынны алдан күрә белгән, алайса, — диде Вера Ивановна, елмаеп.

— Дөньяга килүемә үк бөтен бөек кешеләр игътибарларын миңа җәлеп иттеләр, — диде Владимир Петрович бик җитди кыяфәттә.

Һәм алар икесе берьюлы бик күңелле көлеп җибәрделәр.

Минем дә аларга музыканың үземә ничек тәэсир итүе турында сөйлисем килә, ләкин бер генә дә ятышлырак сүзен таба алмый идем.

— Әлбәттә, бүтән бер вакытта, әйтик, моннан егерме еллар элек, шушы ук музыка миңа бөтенләй башкача тәэсир итәр иде, — диде Владимир Петрович һәм миңа карап елмайды. — Менә хәзер Хәйдәргә тәэсир иткән кебегрәк.

Мин, кызарып китеп, нидер мыгырдандым.

Владимир Петровичның бу сүзләре никадәр дөрес икәненә миңа соңрак та, хәтта шул ук кичне дә ышанырга туры килде.

Надя мине озата чыкты.

Җил басылган, шулай да биткә кисәк-кисәк салкын агым килеп бәрелә — һавалар тагын үзгәрергә тора иде бугай.

Ишек алдындагы үзебездән аз гына биегрәк яшь агачлар янына килеп туктадык.

— Надя, ничек түзәрмен икән инде мин?

— Нәрсәгә?

— Иртәгә кадәр... Шунда, зәңгәр җилкәнебез янына киләсең бит?

— Белмим әле.

— Усал син, Надя.

Һәм мин, ашкынып, аны кочаклап алдым. Надя бер генә мизгел куеныма сыенды да, кулларын күкрәгемә терәп, арткарак каерылды.

— Хәйдәр, җибәр әле, бер сүз әйтәм.

— Мин сине таңга кадәр тыңлар идем, Надя.

— Хәйдәр, әйт әле, син аны бик яратасыңмы?

— Ягъни... Ничек инде «аны»?

— Боргаланып маташма, Хәйдәр. Егет булсаң, дөресен әйт, яратасыңмы?

Кинәт бөтен тәнем буйлап кайнар чымырдау узды. Шунда ук бүген көндез будкада Исламгәрәйнең әрсез елмаюы хәтердә чагылды, Надяның сәер-сәер сүзләре колак төбемдә бер-бер артлы яңгырагандай булды: «Төш кенә булсын иде шул...», «Кешеләр бер-берләрен пычаксыз суялар», «Йөрерсез дә эле...»

— Ник дәшмисең? Димәк... Хәйдәр, мин сезнең бәхетле булуыгызны телим.

Мин, чыннан да, телсез калдым бу минутта. Бик сәер иде бу, башка сыймый иде. Надям, минем кул житмәстәй омтылышым, минем алла урынына күргән гүзәлем Надя, кинәт... көнләшә. Аңлап булмый иде моны, аз гына да ышанасы килми иде.

— Надя, тыңлале, мин син уйнаганны кабат ишетәм. Владимир Петрович әйткәнчә, бөтенләй бүтәнчә яңгырый. Тыңлале... Синең соравына да җавап бирә...

Ничегрәк дип җавап бирә иде ул музыка? Надя аны ничегрәк ишетте икән?

Белмим...

## 13

Иртәгесен Исламгәрәй белән безнең арада менә мондый сөйләшү булып алды.

— Нәрсәләр сөйләдең син кичә Надяга?

— Ничек инде?.. Берни дә сөйләмәдем.

— Авыз йомып, борын сызгыртып кына утырдыгызмыни?

— Әә... Юк инде, анысы минем холыкка туры килми. Җүләр! Янында шундый чибәр кыз, дустыңның сөйгән кызы утырсын да син авыз йомып тор, имеш. Теге, ничек диләр әле?.. Занимать иттем кызыңны.

— Ничегрәк итеп занимать иттең икән?

— Телемә ни килсә, шуны такылдадым. Хәзер хәтерләп тә бетермим инде.

— Шулай да, хәтерлә әле.

— Ә-ә... Теге... Шулай сүз чыкты да, анекдотлар сөйләдем. Надя үзе дә берне сөйләде. Сиңа да сөйләмәде микән, шундый кызык. Болай... Бервакыт колхозның тавык фермасына килгән ди берәү...

— Ярар, анысы соңыннан. Тагын ниләр сөйләштегез?

— Аннары, татар мәзәкләре сөйләдем. Рас, татар егетен ярата икән, белеп торсын. Теге... Кияүләр турында...

— Гел мәзәкләр генә сөйләшмәгәнсез бит. Тагын нидер әйткәнсен.

— Нәрсә әйттем икән соң? Ә-ә-ә... Ну, хәйләкәр ул синең Надяң. Ни, ди... «Каникул вакытында гына булса да, минем нефтьтә эшләп аласым килә, кызлар да эшлиме сездә?» — ди. «Эшли, мин әйтәм, оператор кызлар бар, замерщицалар...» «Ниндирәк кызлар, эшләреннән зарланмыйлармы, кыерсытмыйсызмы?» — ди. Китте сорашып, китте сорашып... Һәр кыз турында аерым-аерым төпченә... Шуннан соң, тел төбен сизеп алдым да әйттем дә салдым...

— Нәрсә әйттең?

— Кызларыбыз барысы да бик чибәрләр, ну, чибәрләрнең дә иң чибәре Айсылу исемле кыз, мин әйтәм.

— Шуннан?

— Көлгән була... Әмма сизеп торам, йөрәгенә ут салдым моның. «Ә ул чибәр кыз кайсыгызны ярата соң?» — ди. «Мәсәлән, мин үзем аны бик яратыр идем дә, миңа тәтеми шул»,— дим. «Хәйдәр кебек аюдай таза, уңган һәм чибәр егетләр барында, ничек без мәхлукларга карасын ул!» — дим.

— Ну и дурак!

— Ә-ә... Бер дә дурак түгел. Синең файдага тырыштым мин, беләсең килсә. Кызлар алар, шулай бераз көнләштереп алсаң, сине тагы да яратарак бирәләр. Белгән инде!..

Мин көлдем. Ә үземнең ярсуым менә-менә ташыр дәрәҗәгә җиткән, кордашымны якасыннан урап алып, селкеп салырга да күп сорамам кебек иде. Әлеге сыналган метод буенча, эчтән генә саный башладым.

— Әллә ачулана инде? — диде Исламгәрәй, күзләрен уйнаклатып. — Җүләр! Синең файдага бу, менә күрерсең... Карале, кордаш, уртага бер яртыны куеп сөйләшмичә булмый әле бу, болай булгач. Синең мотоциклга гына атланып, барып килим?

— Бармыйсың бер кая да.

— Син инде... Безнең эше белән...

— Ярар. Бетте бу турыда. Точка.

## 14

Нәкъ егерме биш көннән соң Надя китеп тә барды.

Егерме биш көн... Минем егерме өч еллык гомеремдә, ихтимал, иң бәхетле көннәрем булгандыр алар. Көн саен очраштык, ләкин очрашу сәгатьләрендә генә түгел, Надя һәрвакыт минем янымда, мин үзем генә күрә торган сүнмәс нур булып, янымда даимән балкып тора иде.

— Хәйдәр, мин синнән куркып та куям...

— Мин шулай куркынычмыни?

— Куркыныч шул... Нигә икәнен үзем дә белмим... Куркыныч.

— Җүләркәем!..

Һәм мин исерткеч исле кыска чәчләргә яңагымны куям.

— Хәйдәр, мин беләм бит... Чәчемне болай алдыруым сиңа бер дә ошамады. Әйе?

— Ошамаган иде. Хәзер ияләндем инде.

— Мин ни өчен ошамаганын да беләм.

— Ни өчен икән? Мин үзем белмим.

— Чөнки Айсылуның толымнары бик озын, бик матур...

— Ә Надяның бөтен җире матур. Чеховча. Төсе дә, киеме дә, уйлары да...

Надя минем кочакларга сузылган кулларымны тотып алып, җай гына читкәрәк этәрә.

Мин сагаеп калам. Моннан элек тә, шулай Айсылу турында сүз чыккач, мин үземнең ул кыз белән чак кына мавыгып алуым турында, моның Надяны артык сагынудан, бары шуннан гына килеп чыгуы турында кызып-кызып аңлата башлаган идем... Надя бөтен тәне белән калтыранып куйды да кинәт урыныннан сикереп торды. Мин артыннан килә башлагач, «Зинһәр, йөрмә!» дип, йөгерә үк башлады. Үзенә күренмичә генә барып, подъезд ишеген дә япмыйча йөгереп кереп киткәнен карап калдым.

Бу юлы да шул хәл кабатланмагае дип, мин сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыгам.

— Надя, без болай итик... Икенче елга синең каникул вакытына мин дә отпуск алыйм да, китик ерак диңгез буена сәяхәткә. Күптәнге хыялыбыз икән, сузмыйк, ирешик без ана.

— Син инде институтта укый башлагач, бушый алырсың микән соң?

— Бик омтылсаң, барысына да вакыт табып була.

— Анысы шулай... Ой, ничек кызык булыр иде!

— Менә бер заман, таң беленеп кенә килгәндә, иңнәргә биштәрләр асабыз да...

— Әйе, Хәйдәр, бераз юлны җәяү үтәрбез, бераз юлны пароходта, бераз юлны машинада, аннары тагын җәяү... Ой, ничек кызык булачак.

— Бер заман, карурман аша үткәндә, каршыбызга соры бүре килеп чыга...

— Ул арада давыл куба да, мине Черномор алып китә...

— Син диңгез ярына басып, зәңгәр җилкән көтәсең...

— Ниһаять, зәңгәр җилкән килеп җитә...

— Һәм без менә болай итеп күрешәбез.

Мин Надяны кочаклап алам. Бөтен барлыгым тоташ бәхеткә әверелә. Алда мине көткән зур, бик зур бәхетнең беренче хәбәрчеләре итеп җибәрелгән никадәр кадерле минутлар...

— Син дөрес әйтәсең, Хәйдәр. Ничә еллар буе омтылган зәңгәр җилкәнебез инде бөтенләй якын икән ич... Бер ел... Ә аннары нәрсә?

— Аннары нәрсәме? Аннары нәрсә икәнен сүз белән әйтүе дә куркыныч... Ул бәхет артык зур булганы өчен куркыныч. Шунда, зәңгәр диңгез буенда, ихтимал, без мәңгегә кавышырбыз. Укып бетерәсебез бармы? Монысы комачау була алмый. Миңа да заочник булып түгел, Мәскәүнең үзендә торып та укырга мөмкин ич. Башкалада укуларыбызны тәмамлагач, яңадан бире кайтырбыз...

Миңа нигәдер Надя боларны сүзсез дә аңлый, Надя да бу минутта нәкъ менә шушылай уйлыйдыр кебек тоела...

...Иртәгә китәсе дигән кичне Надя бик озак пианинода уйнады. Классик музыкадан этюдлар, прелюдияләр уйнады ул. Надя аларның берсенең дә исемен, авторларын әйтеп тормый, уйнап туктый да, беркөнге кебек, «Барып җитә микән бу сиңа?» дигәндәй моңсу гына миңа карап куя, аннары яңадан уйный башлый иде. Миңа ул уйнаганнар таныш та, күбесе таныш та түгел... Минем киноларда күргәнем бар, кыз уйнаганда, егет пианино янына килеп баса да алдагы нота китабының битләрен, берсен уйнап бетерүгә, икенчесен ачып тора. Минем дә исерткеч исле бөдрәләргә иелә төшеп, шулай басып торасым бик килә дә бит... Нишлим, мин ул буй-буй тезелешкән кара чукмарбашларның нәрсә аңлатканын бөтенләй диярлек белмим шул...

Мин, сихри авазлар дөньясына чумып, сүзсез генә утыра бирәм. Надяның «Барып җитәме?» дигән сораулы карашларына да җавап бирмим. Берәр сүз әйтсәм, беркөнге кебек, музыкадан наданлыгымны гына күрсәтермен кебек.

Сибелә авазлар... Никадәр тирән моң, тынгысыз ашкыну, каядыр өндәү һәм, беркөнге кебек, ниндидер кисәтү дә яңгырый.

Китте Надя.

Әнә шул моңлы, ашкынулы, өндәүле һәм кисәтүле музыка яңгырап калды да, алда инде бик, бик якын зәңгәр җилкән шәүләсе калды...

## 15

Көннәрем дә шулай ук ашкынулы, омтылулы һәм тынгысыз үтә иде.

Безнең Агымсу промыселы күптән инде Әлмәт идарәсеннән башка чыгып, үзе зур нефть идарәсе булып әверелде. Тирә-як авыллардагы тагын өч промысел карый безгә. Үсте, бик зурайды хәзер хуҗалыгыбыз.

Авылдашларның: «Әлмәттәге кебек, бездә дә шәһәр салмаслар микән?» дигән хыяллары да чынга әверелде дияргә була. Авылыбызда ук булмаса да, бездән еракта түгел, яңа яшь калага нигез салынып ята. Аңа хәзер үк инде халкыбызның батыр улы Муса Җәлил исемен биреп куйдылар.

Скважиналарга хезмәт күрсәтүдә яңа тәртипкә күчтек. Промысел участокларга бүленде, участок начальнигына нефть чыгаручылар бригадасы да, җир асты ремонты бригадасы да буйсына.

Борһан аганы тагын күрше участокка күчерделәр. Мине үзебезнең участокта мастер итеп күтәрделәр.

Айсылу Башкортстандагы нефть техникумында читтән торып укый иде, быел ул соңгы курсны шунда торып укырга дип китеп барды да, мине промыселның комсомол оешмасы секретаре итеп тә сайлап куйдылар.

Әле кайчан гына мин югары трибунадан торып: «Татарстанның яшь нефте язмышы, башлыча, яшьләр кулында. Безгә, яшьләргә, ныграк таяныгыз, безгә ныграк ышаныгыз!» — дип аваз салган идем.

Миңа ул — үз авазымның кайтавазы... Никадәр зур җаваплылык йөкләнде хәзер минем җилкәмә.

Җаваплы эшнең мең борчу-мәшәкатенә акрынлап ияләнеп тә барам шикелле... Егетләр дә, промысел җитәкчеләре дә минем эшемнән азмы-күпме канәгать тә бугай... Ләкин синең хезмәтеңә кешеләр хөкеме белән бергә, үз күңелең хөкеме дә бар шул әле.

Минем күңелем хөкеме исә эшемнән һич тә канәгать түгел, бик күп, бик күп нәрсәләрне болай түгел, бөтенләй бүтәнчә эшләргә тиеш идем кебек.

Борһан ага белән бер сөйләшүдән соң мондый күңел канәгатьсезлеге тагы да көчәйде.

Соңгы вакытларда Борһан ага белән минем әти ничектер бик дуслашып киттеләр. Эштән соң Борһан ага еш кына Әлмәткә кайтып китәргә ашыкмый, безгә килә дә әти белән озаклап сөйләшеп утыралар иде. Әти хәзер балтадаш иптәшләре белән безнең яңа өйне күтәрәләр, колагыма чалынган сүзләренә караганда, әңгәмә шул турыдарак куера иде шикелле. Өйнең бүлмәләрен ничек уңайлырак бүләргә, верандасы ничек ясасаң матуррак һәм уңайрак булыр?.. Картлар шундыйрак нәрсәләр турында кызып-кызып бәхәсләшеп тә алалар иде.

Бер көнне Борһан ага килгәндә, әти эштән кайтмаган иде әле. Икәүләп бакчага чыгып утырдык.

— Шиһапка да әйткәнем бар, бакчаны зурайтырга кирәк сезгә. Алмагачына, чиясенә, грушасына күмелеп утырсын ул авыл өе — их! Һаман да матуррак итеп яшәргә өйрәнеп җитмибез.

— Үзебезнең дә исәп шулай да... Вакыт кына тими.

— Әллә вакыт тими, әллә игътибар җитми.

Борһан ага, чын бакчачыдай, безнең һәр агачны, һәр куакны берәмберәм карап йөрде. Бу алмагачның ботаклары дөрес киселмәгән, карлыган куакларыгыз картайган, яшәртәсе бар, дип киңәшләрен дә әйтә иде.

Аннары ул яңа гына кабызган папиросын бер-ике суырып ташлады да күңелле генә елмаеп куйды.

— Күзеңә чалынмады микән, бер көнне минем турыда газетада язып чыгардылар бит. «Борһан батыр адымнары» дигәннәр. Янәсе, ул атлап узган урыннарда ургып-ургып нефть чишмәләре ага башлый, зур-зур калалар үсеп чыга...

— Нигә, Борһан ага, дөрескә дә килә яза ич. Сез беренче скважиналарны эшләтә башлаган урыннарда — хәзер Лениногорск шәһәре, шулай ук беренче скважиналарын сез эшләткән җирдә — Әлмәт каласы, инде бире килгән идегез — Җәлил шәһәренә нигез салына...

— Матурлап-матурлап, арттыра-арттыра язарга язучыларга бир инде. Анысы, дөрес, халыкка матур сүз дә бик кирәк. Ләкин... күңелемә бер дә хуш килмәде минем бу сүзләр.

— Нигә, Борһан ага?

— Бәлки мин картлыкка таба барган акылым белән ялгышамдыр да, ләкин миңа әнә шул «зур-зур калалар үсеп чыга» дигән сүзләр бер дә ошамады.

— Сәеррәк, Борһан ага.

— Кеше ул, Хәйдәр энем, нинди генә һөнәр иясе булмасын, һәрвакыт табигатькә, җиргә омтыла. Борын-борыннан шулай. Нигә хәзер Әлмәт янында теге коллектив бакчалар, язгы ташкын кебек, үскәннән-үсә? Нигә кеше урман-су буена килдеме, бөтен борчу-хәсрәтен оныта? Шуңа болар барысы да. Ә без кеше күңеленең шушы хосусиятенә каршы килеп, зур-зур шәһәрләр сала башладык. Күпме кешене җирдән аердык. Шул зур шәһәрләр салырга түккән акчаның күпмесендер авылларга бирергә иде дә безгә, бакчаларга күмелгән матур-матур йортлар төзергә иде. Шәһәрдәге кебек, бакчаны сигез-ун чакрымга йөреп түгел, үз янында үстерер иде кеше. Күпме кешегә вахта машинасында дырык-дырык һәр көн утыз-кырык чакрым вакытын заяга уткәреп йөрергә дә туры килмәс иде. Их, кемгә-кемгә, әйтик, машина төзүчеләргә, бәлки, кирәктер дә ул зур шәһәрләр, әмма безгә, шул ук җир байлыгы табучыларга, бик кирәге юк иде аның. Аермаска иде нефтьче халкын җирдән. Безнең, әнә, еш кына җиргә хөрмәт белән карый белмәвебез дә, бәлки, шуннан килеп чыга торгандыр...

Минем әтинең кайткан көнне бик ачынып сөйләгән сүзләре хәтергә килеп төште. Менә бит, нефть остасы белән игенче тагын әле нәрсә турында уртак тел табалар икән!

Борһан ага, урыныннан торып, алмагач кәүсәсен сыпыргалый-сыпыргалый тын гына басып торды, яңадан килеп утырды.

— Әй, Хәйдәр энем, күңел күзе күреп җиткермәгән, уйлап акыл җитеп бетмәгән эшләр күп әле ул бездә. Менә үзебезнең нефть эшендә генә дә... Күпме скважина хәзер фонтанлаудан туктады. Нефтьтә су арткаңнан-арта. Нигә? Яшерен-батырын түгел, нефтьне бөтен җаен-әмәлен белеп бетереп ала белмәдек. Гел ашыктык, гел ашыктык. Хәзер инде күпме акча түгеп, скважиналарга насослар куябыз, нефтьне судан аеру өчен нинди генә әмәлләр кылмыйбыз. Бер дә яшерен-батырын түгел, бөтен җаен-әмәлен белеп бетереп тотынсак, бу хәлгә бүген үк калмый идек без. Һәрхәлдә, тагын ничәмә дистә елларга кичектерергә мөмкин иде мондый хәлне. Һаман да шул, җирнең аның юмарт байлыкларының кадерен белеп бетермибез... Уйлаганың бармы бу турыда?

— Бар, Борһан ага. Егетләр белән дә гел сөйләшәбез. Бәхәсләшеп тә бетәбез.

— Уйлагыз, бәхәсләшегез. Никадәр күңел теләмәсә дә, ышанасы үк килмәсә дә, безгә, картларга, пенсиягә чыгарга да вакыт җитә бит. Сезгә кала барысы да. Бик уйлап, бик акыл белән эшләргә тырышыгыз.

...Ул кичне мин бик озак радиолода музыка уйнатып утырдым. Чайковскийны тыңладым. Баянак Борһан ага сөйләгәннәрне музыка сихри авазлар белән янә кабатлый, хәтта төшенеп тә бетүе кыен булган яңа мәгънә, яңа тирәнлек өстәп, күңелгә сеңдерә кебек иде. Яңа дәрт, яңа моң, яңа ашкыну, яңа тынычсызлык. Надядан байтактан инде хат юк — күңел әнә шуңа да тынычсызлана иде бугай...

## 16

Юкка гына тынычсызланмаган, нидер сизенгән икән ул күңел.

Кисәтүле аһәңнәр дә юкка гына яңгырамаган икән.

...Бураннары, салкыннары белән безнең эшкә мең мәшәкатьләр өстәп, кышлар җитте. Шул мәшәкатьләр, кичке институтта укулар өстенә, минем әле үзем генә белгән тагын бер тынычсыз хәсрәтем бар иде. Борһан ага әйткәнчә, скважиналарның фонтанлаудан туктавына тиз

генә юл куймый торган эксплуатация режимы эзләп табасым килә иде минем.

Минә хәзерге тәҗрибәм, хәзерге белемем күзлегеннән караганда, ул чактагы эзләнүләрем, турысын гына әйткәндә, бигрәк малайларча булган икән минем. Хәзер һәр идарәдә фәнни эзләнү бүлеге бар, Бөгелмәдә фәнни тикшеренү институты эшли. Шулар белән даими элемтәдә мин ул эзләнүләремне хәзер дә дәвам итәм, инде кайбер уңышларга да ирештем шикелле. Ә теге көннәрне... Хәтта Борһан ага белән дә киңәшмичә, үзем генә баш ваттым. Баш ватып кына да калмадым, бер скважинаны чак кына сафтан чыгармадым.

Һәр скважинага инженерлар, геологлар тарафыннан эшләнгән, идарәдә расланган эксплуатация режимы бирелә. Мастерлар, операторлар скважиналарны әнә шул режим белән генә эшләтергә тиешләр. Минем исә үз режимым, әйткәнемчә, нефть коесын гел фонтанлап кына эшләтә торган режимымны табасым килә иде.

Хәзер уйлап баксам, үзем дә шаклар катам. Кайчан гына йокладым да, кайчан гына бераз ял итеп алдым икән мин ул көннәрдә? Эш сәгате бетүгә, Әлмәткә — кичке институтка китеп барам. Аннан кайтканда инде төн уртасы авышкан була, ләкин урын өстенә аварга ашыкмыйм, китаплар, сызымнар белән утырам. Шушылар арасында әле комсомол эше белән чабарга, җыелышларда утырырга да ничектер вакыты табылып тора иде.

Барысына да өлгерергә, барысына да вакыт табарга!... Шуңа омтыла идем. Ә менә Надя — вакытын-нисен сорап та тормый, Надя һәрвакыт уемда иде. Эш арасында булсын, дәрестә утырганда булсын, тегебу кыенлык чыкканда булсын, күңелдә Надя белән сөйләшеп-киңәшеп алам. Надя елмаеп кына җавап та бирә кебек.

Тазалык-саулык хәбәре белән сәламнәр житкергән уч төбедәй открыткаларны искә алмаганда, Надядан һаман да озынрак хат юк. Хәер, үземнең дә хатларым бер дәфтәр битеннән артмый — элеккечә, булдыра алганын сүз белән, кыюлык житмәгәнен күп нокталар арасына яшерә-яшерә бит артыннан бит язып утырырга вакытым тими иде. Бәлки, Надя үзе дә вакытым тарлыгын сизәдер дә, шуңа күрә мине озын хатлар белән борчымаска булгандыр? Аның каравы, очрашкач, сүзләребез никадәр күп булыр безнең, зәңгәр диңгезгә таба озын сәяхәттә туйганчы сөйләшергә вакытыбыз да бик иркен булыр.

Язлар житүгә, мин эзләнүләремне эштә дә сынап карарга булдым. Һичкемгә әйтмичә, бер скважинаны үз режимым белән эшләтә башладым. Штуцерны үземчә ачам, басым кимегәне сизелми, ә нефть гадәттәгедән күбрәк килә иде. Шатлыгым эчемә сыймый, әллә ничә тапкыр серне Борһан ага белән уртаклашырга да омтылдым, ләкин тыелып калдым: тукта, ахырынача сынап бетерим.

Әнә шулай яшерен шатлык белән канатланып йөргәндә, Надядан бик сәер хат килеп төште.

«Хәйдәр! Мин хәзер тулысынча ышандым, син аның белән («аның» сүзенең астына сызылган) чынлап та бәхетле буласың. Ә безнең юллар бергә кушыла алмады. Үзең сизәсең микән, элекке Хәйдәр түгел инде син хәзер. Үстең син, ә киләчәгең тагы да зуррак. Шул зур киләчәгеңдә мин сиңа юлдаш була алмыйм. Чөнки юлларыбыз, омтылышларыбыз икебезнеке ике төрле. Хуш, булдыра алсаң, мине ямьсез итеп искә алма. Сиңа бәхет, бары тик бәхет кенә теләп калучы Надя».

Нәрсә бу? «Син аның белән бәхетле буласың...» Ни дигән сүзләр бу?

Күз алдымда хәрефләр сикерешә, хат юллары бер ерагая, тагын якыная, ул арада зыр-зыр әйләнә башлый иде.

Нәрсә соң бу? Чынлап та Надя язганмы моны?

Конверттан мул булып ислемай исе аңкый иде. Монысы тагын нигә? Надя хатларын ислемайга манчу түгел, гомумән, андый нәрсәләрне бик тыйнак куллана иде ич...

Шул күңел болгаткыч ислемай исен борыныма бәрдермәскә тырышып, хатны кулымда әйләндерә-әйләндерә басып торуым хәтердә дә, аннары, бик ашыгып, каядыр барганым хәтердә. Битемә тып-тып итеп нәрсәдер бәрелә иде — кармы, яңгырмы, әллә агач ботаклары иде микән?

Иртәгесен колак төбемдә үк әтәч кычкырган тавышка уянып киттем. Кайчан менгәнмендер, үзебезнең печәнлектә ятам икән.

«Китәргә, менә хәзер үк Мәскәүгә китәргә дә барысын да аңлашырга. Аңлашырбыз бит, Надя?..»

Башымда, уянуга, әнә шундый уй чагылды. Шушы уй белән эшкә килдем. Шушы уй белән промысел мөдире кабинетына килеп кердем.

— Ну, Рәфиков, Борһан ага югында да сынатмабыз дип уйлыйм мин, — диде Николай Иванович. Үзе елмая иде бугай, күз алдымда эре таза тешләр җемелдәде.

— Борһан ага кая китте соң?

— Ничек кая? Кичә сессиягә озаттык бит.

Исемә төште. Борһан ага барыбыз белән дә берәм-берәм исәнләшеп йөргән иде шул...

«Китәргә, хәзер үк Мәскәүгә китәргә...»

Соң, китәргә булгач, нигә тораташ кук басып торасың соң әле монда? Николай Иванович янына да нәкъ шул киту турында сөйләшергә кердең түгелме?

Икенче бер мизгелдә мин каядыр атлый идем.

«Китәргә, хәзер үк Мәскәүгә китәргә...»

Ләкин «хәзер үк» әллә кая китеп өлгермәгәнмен икән, тәҗрибә скважинам янына җиткәч, аңыма килгәндәй булдым. Манометрга күз салгач, бөтенләй дә айнып киттем.

Манометр скважинада басымның бик нык кимегәнлеген күрсәтә иде. Коточкыч хәл иде бу. Скважинада басым кими, димәк, тиздән аның бөтенләй дә фонтанлаудан туктавы ихтимал иде.

О, дөнья! Моңарчы да рәхимсезлегеңнән авыз иттермәдең түгел, иттердең. Ләкин берсе дә бу кадәр үк булмаган икән әле...

Тәҗрибә, имеш. Фонтаннарны саклау әмәлен табам, имеш. Әй, булдыксыз адәм!.. Юк, булдыксыз гына да түгел, җинаятьче син! Җинаятьче... Скважина кадәр скважина сүндерәсең. Аңлыйсыңмы моның халык байлыгына күпме зыян китергәнен? Төшенәсеңме шуны аз гына?..

«Китәргә, хәзер үк китәргә...»

Ә-ә-ә, инде менә эшләгән җинаятеңнән качып котылырга телисеңме? Җинаятьче намусың белән мәхәббәттә нинди аңлашу өмет итәсең тагын? Ахмак!..

Мин конторага таба йөгердем.

Барысын да Николай Ивановичка сөйләп бирергә. Сүнеп барган скважина турында да, ахмак тәҗрибәм турында да... Хөкем итсен. Кирәк икән, хәзер үк милициягә озатсыннар үземне. Инде барыбер. Озата бирсеннәр...

Күпмедер йөгергәч, тукталып калдым. Бәлки, моны бүген үк әйтмәскә, Борһан ага кайтканны көтәргәдер? Карт оста, бәлки, скважинаны сүндермичә саклап калырга нинди дер әмәлен табар?

О, куркак җан! Инде үз җинаятеңнән качып котылырга төрле сәбәпләр дә эзли башладыңмы? Куркаклыкның иң беренче билгесе нәкъ шул инде — качу әмәлләре эзләү...

Мин тагын йөгердем, тагын туктап калдым. Шулай да барып җиттем.

Николай Иванович конторада юк иде.
Икенче көнем дә шулай аңкылы-тиңкеле үтеп китте. Шунысы гына хәтердә, сәгатьләр буе авыру скважинам янында басып торам, берәрсе килеп чыкса, «Борһан ага кайчан кайтыр икән?» дип сорый идем.
Өченче көнне иртүк Әлмәткә киттем. Исәбем — Владимир Петровичны күрергә, барысын да аңа сөйләп бирергә, аннан киңәш сорарга иде.
Ләкин мине ул өйдә бикле ишек каршылады. Владимир Петрович белән Вера Ивановна Мәскәүгә Надяның туена китеп барганнар.
Кем әйтте миңа бу хәбәрне? Кайда? Хәтерләмим.



## 17

Ничек болай килеп чыкты соң әле бу? Миңа канатлар биргән, мине гел алга өндәгән, беләгемә һәм йөрәгемә күпме көч өстәгән мәхәббәтем... Нигә болай кинәт чәлпәрәмә килде?
О, дөнья! Син Ромео — Джульетта, Ләйлә — Мәҗнүн, Галиябану — Хәлил мәхәббәтләрен беләсең. Ниһаять, кара фашизм кан дәрьялары белән агызып киткән мәхәббәтләрне беләсең... Монда сәбәпләр ачык. Алар турында ишеткәндә, укыганда, аларны сәхнә-экраннарда карагандa йөрәкләр ник тетрәнгәнен белеп тетри.
Ә безнең соң?.. Андый кара көннәр күптән артта калган якты бер көндә... Нигә җимерелде минем мәхәббәтем?
Нинди кара көчләр аерды? Бездә, безнең көннәрдә андый кара көчләр һаман да бармыни соң әле ул? Булса, нindирәк кыяфәттә ул каһәр уты көйдерәсе нәмәрсә?
Көнчелекме, ышанмаумы? Эш-уку белән вакытлыча аерылган юллармы?
О, тау-ташлар актарырлык, хәтта үлемне дә җиңәрлек бик олы көчкә ия булган мәхәббәт каршында бу сәбәпләр артык кечкенә түгелме соң?
Көч ул хәрәкәт итсә генә көч. Алайса, сүнеп барган скважинам каршында нигә болай хәрәкәтсез басып торам соң әле мин? Һәм физик, һәм рухи көчле кеше булырга омтыла идем ич. Нигә шушы кадәр дә көчсез адәмгә әверелеп калдым соң әле мин?
...Ул көннәрдә дә башыма нәкъ шушындый уйлар килгәндерме, ачык кына хәтерләмим. Әмма шунысы бик истә: гел Борһан аганы көтә идем. Карт оста, кайтуга, скважинаны да сүнүдән коткарыр, хәтта йөрәк җәрәхәтемә дә ниндидер дәвасын табар кебек иде. Бәлки, җинаятем өчен иң каты җәзага тартыр? Анысына да риза идем.
Кайтты Борһан ага.
Күрешүгә, шунда ук үземнең ахмак тәҗрибәм турында сөйли башладым. Борһан ага елмаеп кына кулын селтәп куйды.
— Соң... Иҗат эше шулай маңгайны да күптерә инде ул. Кеше егылудан курыкса, оча да алмас иде.
— Нишли алмас иде?
— Нефтьне бөтенләй дә таба алмас иде. Ярар, бу турыда бергәләп уйлашырбыз. Син миңа, иң әүвәл, шуны әйт әле — өй туен кайчан ясыйбыз?
— Нинди туй?
— Өй туе. Хан сарае кебек өй салып куй да, туен да үткәрмә, имеш. Тарих гафу итмәс моны.
Бик гаҗәп иде бу. Скважина кадәр скважинаны сүндерү хәленә җиткерүем өчен иң каты җәза көткәндә, кинәт... өй туе!
Шушы ук сүзләрне миңа ул көнне тагын әллә ничә егет кабатлады. Күптән түгел Әбүзәр белән Сәхәп тә армиядән кайтканнар иде. Ислам-

гәрәй белән өчәүләп килеп, алар да кыстады. «Очрашуыбыз хөрмәтенә бер типтереп алырга менә диган сәбәп ич бу. Әйдә, кордаш!..»

Өйгә кайтсам, анда инде ду китереп әзерләнеп тә йөриләр иде. Күрше хатыннары да кергән. Пешеренәләр, чыжлаталар, дөбердәтәләр...

Шулай итеп, менә, мин өй туенда утырам.

Ах, язмыш! Миннән шушы кадәр дә ачы итеп көлүен микәнни бу? Анда, Мәскәүдә, хәзер Надя үзенең никах туенда утыра торгандыр, ә мин... өй туенда утырам.

— Бәхетле нигез булсын! Шатлык, тигезлек, муллык нигезе булсын!

Ике сүзнең берендә шушы изге теләкләрне кабатлыйлар. Өстәлләрдә, ихтимал, күгәрчен сөте генә юктыр. Эчемлекләрдән ниндиен җаның тели... Бүләкләргә нинди генә җиһазлар китермәгәннәр!.. Җыр, гармонь, хәтта курай белән балалайка да яңгырый.

— Бәхетле нигез булсын! Шатлык белән муллык ташып торсын бу нигездә!

Бәхет, шатлык, муллык... Ихтимал, Надяга да бу минутларда нәкъ шушы ук теләкләрне телиләрдер.

Миңа да телиләр. Чын күңелдән телиләр. Бу өй туен да нәкъ шул изге теләк белән оештырдылар. Сизәм, аңлыйм. Җанымны айкаган күңелсез уйларымны басарга телиләр дуслар.

Никадәр изге ният. Ләкин... Бәхетемә мәтәм җыры булып яңгырый түгелме соң бу?

Ничек болай килеп чыкты соң әле?

Нигә Надядан хат алгач та, шунда ук Мәскәүгә китеп бармадым? Бәлки, аңлаша да алган булыр идек ич. Нәрсә тоткарлады мине? Хезмәт вазифаммы? Уңышсыз тәҗрибәм өчен җәзадан куркумы? Әдәп кагыйдәләреме? Әллә ирлек горурлыгымы?

Ах, никадәр көчсезлек!

Ә матур теләкләр яуганнан ява...

Дусларым! Җаныма кече яшьтән үк рухи көч өстәп, эзләгән үз сукмагымны табарга ярдәм итешеп мине үстергән дусларым! Инде менә шул изге ният белән, үзегез дә сизмәстән, бәхетемә мәтәм җыры җырлыйсыз түгелме соң?

Мин урынымнан сикереп тордым.

— Матур теләкләрегез өчен барыгызга да бик зур рәхмәт, дуслар. Инде шуларга өстәп, миңа тагын бер изге теләк теләгез. Юлларың уң булсын диегез! Мин... мин шушы нигезгә үз бәхетемне алып кайтырга китәм. Хәерле юл теләгез миңа!..

Мин урындык артларыннан кысыла-кысыла ишеккә таба атладым. Болай кысылып атлау кинәт ярсытып җибәрде дә бер өстәлне дөбершатыр читкәрәк эттем. Эттем генә түгел, аударып ук җибәрдем. Кемнәрдер егылды, кемнәрдер кулымнан тотты, нәрсәләрдер кычкырдылар... Мин ишек алдына йөгереп чыктым да, мотоциклымны кабызырга тотындым. Шул чак әллә ничә егет өстемә килеп асылынды. Юмалыйлар, нәрсәдер аңлатырга телиләр иде. Ярсыган арслан көче белән барысын да як-якка чөеп ыргыттым да тагын мотоциклыма ябыштым. Егетләр тагын өстемә асылынды, мин аларны тагын чөйдем... Шунда әнинең ачыргаланып кычкырганы ишетелде:

— Оланнар! Тотмагыз улымны! Тотмагыз...

Мин мотоциклыма атланып китеп бардым.

Әйе, тотарга кирәкми мине. Мәхәббәткә бернинди тоткарлык та киртә булмаска тиеш. Тоткарламагыз... Җитәр! Аннан башка да ничәмә көннәр тоткарландым. Инде юк! Тиздән Бөгелмә, аннары самолет белән Мәскәүгә. Надямны кияве куенынннан йолкып булса да алып кайтырмын. Мәхәббәткә бер нәрсә дә киртә була алмый! Юк, киртә була алмый...

Артымнан тагын икеме, өчме мотоцикл килә иде. Әллә дуслар мине куа чыктылар микән?

Юк, барыбер тоткарлый алмассыз хәзер мине. Юк!

Мин тизлекне арттырганнан арттырдым. Тиздән Бөгелмә, аннары Мәскәү, аннары Надя...

Тоткарлый алмассыз. Тизрәк, тизрәк...

Һәм кинәт...

Нәрсәдер шартлады, нәрсәдер сынды... Мин кап-караңгы упкынга тәгәрәдем.

## 18

Шулай итеп, уналты елдан соң мин тагын мәтәлдем...

...Әле уяулы-саташулы ятканда ук бик йомшак бер кулның маңгаемнан сыйпаганын тоя идем. Шушы ук кул башымны күтәрә төшеп, миңа су эчертә, мендәремне кабарта, аннары тагын чәчләремнән назлап сыйпый башлый иде. Шушы кул сыйпаса, авыртуларым басылып китә, тәнемдә, үземә сизелеп, көчем арта бара иде.

Кем кулы икән соң бу шушы кадәр дә йомшак, шушы кадәр дә шифалы? Әллә инде... Надя кайтты микән?

Ләкин ул Надя кулы булып чыкмады. Бу — Айсылу кулы иде.

— Ничек син монда, Айсылу?

— Менә... Кайткан идем. Практика вакыты безнең, Хәйдәр.

Айсылуның шул шифалы куллары сәгатьләр буе массаж ясап, минем сынган аякларыма җан кертте, шушы куллар култыгымнан кочаклап, мине яңадан тәпи йөрергә өйрәтте.

Бер кичне Айсылу килгәндә, палатада мин ялгыз гына идем. Бүтән авырулар, инде тазарып килүчеләр, кайсы кая чыгып киткәннәр иде.

Айсылу, күзләрен соңгы шәфәкъ нурлары уйнаган тәрәзәгә текәп, сүзсез генә янымда утырып торды. Менә ул минем одеал өстендәге кулымны сак кына сыйпап куйды.

— Никадәр көч бу кулларда, Хәйдәр.

— Көч бар иде кебек тә... Хәзер инде...

— Бу куллар күрсәтер әле көчен. Җиңелүне белә торган куллар түгел бу.

— Җиңелде бугай шул инде...

Айсылу кулын минем кул аркасына куйган килеш, беразга тагын сүзсез генә утырды.

— Тиздән мин техникум бетерәм. Яраткан һөнәремә ирешәм. Беләсеңме, Хәйдәр, мин моның өчен сиңа бурычлы.

— Сәер бурыч.

— Бәлки, сәердер дә... Соңгы елларда мин гел синең кебек үк көчле кеше булырга омтылып яшәдем. Синең көчеңә соклана идем дә, шулай ук көчле буласым бик килә иде. Физик көчне генә әйтмим, рухи яктан да...

Ул көнне мин бу сүзләргә әллә ни игътибар итмәгән идем. Соңрак төшендем мин ул сүзләрнең мәгънәсенә.

Мин таякка таянып больница бакчасына чыгып йөри ала башлагач, Айсылу яңадан укуына китеп барды.

Яз, яшьлек, дусларым кайгыртуы һәм Айсылуның кул җылысы... Болар мине тиздән тәмам аякка бастырды.

Тәнем савыкты, ә җаным...

Никадәр куарга тырышсам да, Надя минем уйларыма һаман килә дә керә. Кемнәндер аның кияве дә музыкант икәнлеген ишеткән идем. Шуңамы, Надя минем күз алдыма нәкъ теге кинолардагыча килә: Надя пианинода уйный, ире, янына баскан да, алдагы нота битләрен ачып

тора... Колак төбемдә музыка да яңгырый кебек. Ашкынулы һәм моңсу, өндәүле һәм кисәтүле музыка... Ул арада миңа Надя сораулы күзләре белән карап куя: «Барып житә микән бу сиңа? Аңлыйсың микән?»

Аңлыйсың микән?.. Ә менә музыкант ирең син андый сорау белән карамыйсыңдыр. «Безнең юллар кушыла алмады» дип, шуны уйлап әйтүең микәнни?

Ә бит һәркемнең күңелендә үз музыкасы бар. Кеше үзенең хезмәтен, туган җирен, сөеклесен никадәр ныграк яратса, аның күңел музыкасы да шул кадәр көчлерәк, минемчә, менә моны, Надя, син үзең дә аңлыйсың микән? Ах, бу турыда без нигә, нигә элегрәк сөйләшмәдек икән соң?

Гомумән, бик күп, бик күп нәрсәләр турында сөйләшергә өлгерә алмый калдык без синең белән, Надя. Мин гел сиңа тиң булырга омтылып яшәдем. Сиңа тиң булгач, зәңгәр диңгездә зәңгәр җилкәнле көймәдә аңлашырга тиеш идек без барысы турында да.

Зәңгәр җилкәнле диңгезгә кадәр барып җитә алмадык...

Ә Айсылу әйтә: «Соңгы елларда мин гел синең кебек үк көчле кеше булырга омтылып яшәдем», — ди. Бик кызык килеп чыга ич әле бу. Мин Надяга тиң булырга омтылган кебек, Айсылу да... Бик кызык бу.

Һәм без көчле кешеләр икәнлегебезне расларбыз әле, Айсылу!

О, әгәр үз эшенә чын гашыйк, үз эшенең остасы Борһан ага күңелен музыкага салсаң, никадәр көчле симфония булыр иде бу. Ә без, Айсылу, синең белән — Борһан аганың шәкертләре һәм варислары — ул музыканы тагын да көчлерәк яңгыратырбыз әле. Яңгыратырбыз! Надя да ишетерлек итеп яңгыратырбыз.

...Җаным да савыгып килә иде бугай инде..

## 19

Вокзал. Кабаланып каядыр йөгерүче, сабыр гына көтеп утыручы юлчылар. Кемнәрдер китә, кемнәрнедер каршылыйлар, кемнәрнедер озаталар. Һәркемнең тормышында менә-менә нидер булырга тора. Сузып-сузып кычкыртучы паровозлар шул турыда хәбәр салалар.

Мин дә көтәм, мин дә каршылыйм.

Айсылу, хәлемне сорашып, миңа гел хат язып торды. Соңгы хатында имтиханнарны уңышлы тапшыруын, инде кайтырга билет та алып куюын язган иде. Шул хат китерде мине биргә.

Радио хәбәр итте: Мәскәү — Чиләбе поезды килгән.

Сикереп тордым да перронга таба йөгердем. Ишеккә җиткәч, тукталып калдым. Кая ашыгам, бу бит әле мин каршылыйсы поезд түгел. Миңа Мәскәү ягыннан түгел, киресенчә, Чиләбе ягыннан килүче поезд кирәк. Айсылу кайтып җитәргә тагын сәгатькә якын вакыт бар әле.

Шулай да перронга чыктым.

Йөгерешәләр, үбешәләр, шаулашалар.

Әнә бер хәрби кеше вагонның биек баскычыннан бер кызны күтәреп төшерде. Кыз, аяклары җиргә тиюгә, җинелчә генә сикереп куйды да бер генә мизгел егетнең күкрәгенә сыенып алды, аннары икесе берьюлы җирдәге чемоданга үрелделәр, үзләре бер-берсенә карашып көлештеләр.

Бире таба киләләр. Аякларым үзеннән-үзе каршыларына таба атлады.

— Мирзаһит! Син ич бу?!

— Хәйдәр!

Кочаклаштык. Каерылышып бер-беребезгә карап алдык та тагын кочаклаштык,

— Карале бу баһадирны! Хәйдәр, нишләвең бу? Кайдан җыйдың бу кадәр тазалыкны?
— Үзең сон! Офицер киеме ничек килешә сиңа.
Мирзаһит нигәдер русчага күчте:
— Ах, мы забыли... Прошу признать, моя половина — Марите. Или, по-нашему, Мәрьям.
Мин алсу бармак очларын тотып куйдым.
— Поздравляю.
Һәм күтәрелеп карадым. Күтәрелеп карауга, коточкыч кызаруымны сиздем.
Шул кадәр дә ошаса ошар икән! Минем алда, ул — Надя елмаеп басып тора иде.
Хәер, юк, ошашлык бөтенләй үк түгел... Надяның чәчләре коңгырт-рак иде. Буйга да чак кына озынрактыр. Әмма елмаюлары, күз караш-лары... Ошаса да ошар икән!..
— Сине нинди җилләр ташлады соң әле монда, Хәйдәр? Кайтуыңмы, китүеңме дигәндәй?
— Менә бит... Каршыларга килдем.
— Оһо! Нинди фәрештәләр хәбәр итеп өлгерде әле безнең кайтуны? Марите, смотри, ему феи на крылышках молву о нас принесли...
— Бывает такие предчувствия.
— Әй, юк. Мин, ни... Берәүне каршыларга килгән идем.
— Бик әйбәт. Бергәләп каршыларбыз да, бергәләп Агымсуга кай-тырбыз.
— Юк, юк, Мирзаһит. Сез кайта торыгыз. Минем әле тагын бер сәгать көтәсе.
Мирзаһит Маритега карап елмайды.
— Он кого-то ждет. Давай не будем смущать молодого человека в свидании. Зато там мы их встретим как следует!
Автобус кузгалып киткәндә, тәрәзәдән Маритеның елмаюлы йөзе күренеп калды.
Мин әрле-бирле йөренергә тотындым.
Шушы кадәр дә ошаса ошар икән. Надя елмаюлары, Надя күз карашы...
Автобус киткән якка таба атладым. Кире борылдым.
Такси машинасы алдым да аэропортка китеп бардым. Касса янына килеп бастым.
— Миңа Мәскәүгә китәргә кирәк. Хәзер үк китәргә.
Нигә алдым соң әле мин бу билетны? Чыннан да Мәскәүгә очмакчы буламмы? Җүләр! Иртәгә иртүк эшкә барасың бар. Айсылуны каршы-лыйсың бар. Мирзаһит көтә. Марите белән бергә... Нишләвең бу?
Нишләвем булсын? Бәхетемә омтылам.
Бәхетеңә омтыласыңмы, әллә бәхетеңнән качасыңмы? Нишлисең?
Радиодан Мәскәү самолетына утырту башлануын хәбәр иттеләр.
Билетымны учымда йомарлап, мин дә чемоданлы кешеләр артыннан иярдем...

*Беренче төпләм дәфтәрләр тәмам.*

Әдип Маликов

# САЛКЫН-АЛАН

ПОЭМА

*Татарстанның атказанган укытучысы,*
*Бөек Ватан сугышы ветераны коммунист*
*Нури ага Сибгатуллинга*

Чайкап алды,
Айкап салды
Дәрьялары бу дөньяның.
...Эзләп килдем чыккан җирен
Нәни генә бер елганың.
Салкын-Алан дигән авыл,
Тирә-ягы яшел урман.
Салкын-Алан дигән елга
Башын ала менә шуннан.
Кайнап,
ургып чишмә чыга,
Баш очында ялгыз каен.
Яшьләр чәчкә бәйрәменә
Җыела монда һәр яз саен.
Бөтен авыл килә суга,
Суы аның бетеп тормый.
Җырлый-җырлый чишмә ага,
Килмәгәнне көтеп тормый.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Чишмә буе сусыл чирәм,
Бәбкәләргә тигән өлеш.
Тилгән күреп, кемдер шунда
Сөрән салды:
— Мәлгунь, көш-көш!..
Оялыпмы үз тавышыннан,
Ышыкланды коймасына...

— Нихәл, Сырур?
— Нури абый,
Хәл бар әле тырмашырга.
...Күргән саен шул Сырурны
Сызлап куя аның җаны.
Ничә еллар буе менә
Юк бер уйдан арынганы:
Тол хатынның каршысында
Гаебе бар гүя бик зур.
...Ирек бирми андый уйга,
Үзенекен сөйли Сырур:
— Телевизор куйдык, абый,
Туеп булмый карап бер дә.
Кире илтеп тапшырмасам,
Бәбкәләрем калмас көзгә...
Карганса да, зарланса да,
Балкый йөзе сөенеч белән.
Су китерде йөгереп кенә
Чишмәдән ул чүмеч белән.
Нури абый йола саклап,
Сый-хөрмәттән авыз итте.
Чүмечтәге калган суны
Каен төбенә илтеп сипте.
Тыңлап ускән зифа каен
Бу якларның җыр-моңнарын.
Ничә еллар буе Сырур
Түккән аңа күз нурларын.
Сөйләр иде бер хикәят,
Каенкайның юк шул теле.
Шул каенда бөреләнә
Ире — Газиз истәлеге.

2

Укучысы иде Сырур...
Газизе дә истә калган.
Мадрид утта янган еллар,
Бөтен класс испанкадан.
Чкаловлар батырлыгы
Таң калдырды бар дөньяны.
Соңга калып туганбыз дип,
Балаларның кайгырганы
Истә калган...
Мәш килделәр бакча ясап
Укучылар һәр яз саен.
Газиз белән Сырур бергә
Утырттылар зифа каен.
Туйларын да күрде Нури.
Газиз — уйчан, юаш кына...
Афәт купты ил өстендә
Алар семья корган кына.

3

Каны кызыл солдатның да,
Чәч агарткан маршалның да...
Тигезләде сугыш барысын,
Ватан ул бер —
барсының да!
Укытучың — тере аллан,
Соры шинель киде ул да.
Укытучы һәм шәкерте
Чыкты озын,
хәтәр юлга.
Йөрәк тулы сагыш белән
Әйтте Сырур озатканда:
— Абыеңнан калма, Газиз,
Җиңгәч тә кайт,
озаклама.
Нури белән Газиз бергә,
Бер взводка эләктеләр.
Өйдән килгән тәмәкене
Бер янчыктан көйрәттеләр.
Бер шинельне ястык итеп,
Берсен өскә ябындылар.
Янып-көеп бер утларда,
Бергә сыкрап сагындылар.
Сабый бала сыман,
Газиз
Сорап язды хаты саен:
«Без утырткан теге каен
Дәү булдымы, СырURкаем?»
Сакладылар Идел ярын,
Яр сызыгы — соңгы сызык.
Артта — җир юк,
яшәү дә юк,
һәм алга да булмый узып.
Туфрак та юк баскан җирдә, —
Таш өеме, металл оны.
Туган илен күкрәк белән
Каплап торды Ватан улы!
Укытучы һәм шәкерте —
Сынау үтте бер окопта.
Яндырылган танкларның
Санын алар штык белән
Язып барды котелокка.
Кайнар иде,
ялкын сыман,
Сталинградның һавасы да.

---

Козгындай бер мина төште
Ике дусның арасына...

---

4

Кузен ачты госпитальдә,
Кинәт елан чакты гүя:
Окоп та юк, Газиз дә юк,
Ә гәүдәсе ярты гына.
Ята бала койкасында,
Сабыйдан да көчсез булып.
Кырык атна узды шулай
Бер сызланып,
бер онтылып.
Язалмады өенә хат;
Ятты барлап тормыш юлын.
Кузгатмыйча күкрәгеннән
Исән калган ике кулын.
«Инвалидлар йорты, имеш,
Җыя Нури ишеләрне».
...Гафу итмәс бу уенны
Салкын-Алан кешеләре!
Менеп каен башларына,
Балаларың көтәр сине.
Ятим калып,
хәсрәт йөген
Бер үзләре күтәрсенме?!
Үлгән булып саналыргa? —
Тиз ачылыр юк-бар хәйләң.
Архивларны тенти-тенти,
Ил бетереп эзләр Сәйдәң.

---

«Җиңгәч тә кайт, Газизкәем,
Кала күрмә абыеңнан...»
Үлгәннәргә
дөнья тыныч,
Калганнарның хәле яман.
Әрни-әрни дусты өчен,
Ерак юллар урый-урый,
Носилкадан
Носилкага
Күчә-күчә кайтты Нури.
Ул райкомга кайтып төште.
Хатыны һәм балалары,
Райондагы дус-ишләре
Түгәрәкләп урап алды.

Күрде шунда Сырурны да,
Күз төпләре эчкә баткан.
Таптырмады Газизен ул,
Әйтте бары:
«Абый кайткан...»
— Абый кайткан!
Күрергә дип
Авылдашлар эзләп килгән.
Сиздe Нури,
килгән халык
Курка елап җибәрүдән.

---

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Нури абый узып бара
Юкәлекләр буйлап кына.
Арыган башка шифа таба
Баллы һава сулап кына.
Көнләшәләр бер-берсеннән
Балавыздай нарат өйләр.
Ишетелеп куя кинәт
Әллә нинди назлы көйләр.
Комсызланып
Ил авазын
Аулый биек антенналар.
Башкалалар белән тоташ
Картада юк Салкын-Алан.
Кайткан елын госпитальдән
Бик хәтерле Нури абый:
Сандыктагы бәрәңгене
Берәмтекләп саный-саный
Пешерттерде хатыныннан,
Салып китте портфеленә.
Ялманырлык әбәт чыкты
Укучылар әртиленә.
Үтенделәр авылдашлар:
Синдә булды безнең терәк.
Инде яудан исән кайткач,
Син тагын да кадерлерәк...
Парторг итик сине, Нури?
Шефка алды бөтен мәктәп
Колхоздагы терлекләрне...
Дөнья ачтан сөрлексә дә,
Халык күңеле сөрлекмәде.

### 2

Нури абый узып бара,
Бер кулында кәкре таяк.
Борылганда,
юл биргәндә
Протезлары куя сайрап.
Юнәлде ул тау ягына,
Яшь терлекләр утарына.
...Томырылып чаба бозау,
Белми кайда туктарын да.
Аяклары нәзек, озын,
Сырт өстендә — соры тимгел.
Шул гөнаһсыз «бәби» өчен
Дулап йөрде Сырур бер көн.
Бозау тугач,
Локман картка
Барып җитте бик тиз генә:
— Нишләп ферма сыерлары
Йөри урман үгезенә?
Ике поши бозау алдык
Син көтүче булып калгач.
Үскәч күпме сөт бирә ул,
Поши савып норма тулмас.
Француз телен бик беләсең,
Маллар телен аңламыйсың.
Пошынмыйча гына йөреп,
Пенсиягә чамалыйсың!..
Әйткән Локман:
— Шәйләп, килен,
Намусыма кагылма син...
Хәтерлиләр Сырурның да
Юаш вакытын, сабыр чагын.
Матур чагын, сылу чагын,
Балкып торган Сырур чагын...
Күпме еллар наз күрмичә,
Онытып яши ир кочагын.
Таптап узды ферма юлын
Чирек гасыр гомерләре.
Көйри-көйри көлгә әйләнде
Учактагы күмерләре.
Халык әйтә:
ялгыз дөнья
Тормый сыйпап баштан гына.
Тол хатыннар
пычакларын
Кайрый кабер ташларында...

---

Аласы иде сине, Нури,
Йолып кеше кайгысыннан...
— Юкәләр шул бик тиз корый,
Аерып алсаң кайрысыннан.
Илдән ничек аерыласың,
Син бит шунда туып үскән;
Авыз итеп бер икмәктән,
Бер чишмәнең суын эчкән.
Локманны да рәнҗетәсе
Килми аның бер дә генә.
Күкерт түгел, май саласы
Иде картның йөрәгенә.
Дүрт ел буе әсирлектә
Җанын асрап йөргән солдат,
Минутларын минутларга,
Көнен көнгә көчкә ялгап,

Француз партизаны белән
Бергә,
бер җәзаны көткән.
Кайтса фашист коллыгыннан —
Өйдә семья тузып беткән...
Йөри менә гомер буе
Иелә алмый җиргә чаклы.
Фашистерткыч
бил сөяген
Таптап изгән теге чакны.
Җирдән аерып игенченең
Эшчән кулын, каты кулын,
Теләгәннәр җимерергә
Үз бәхетенә кайту юлын.
Ялгыз калса Нури абый
Уйларына чума шулай...
Биеп килә поши бозау,
Матурлыкны биргән ходай.
Тәрбияли бик кадерләп,
Какмый Сырур «килмешәген»,
Ана диеп, «Мальва»сының
Саумый куя бер имчәген.
Шундый хәлләр.
Поши бозау
Атна үсә ай үсәсен...
Юллап кайтты Нури Вафич
Локман картның пенсиясен.
Нури, диләр, кеше хәлен
Күңеле белән күрә белә.
Авылдагы һәр вакыйга
Тиеп уза йөрәгенә.

---

### 3

Нури абый узып бара,
Көмеш чәчен тарый җилләр.
Локман бабай кебекләр дә
Аны зурлап: «Абый», диләр.
Кабынганда ликбез[1] уты
Алар да бит укып йөргән.
Бөек Ленин исеменнән
Наданнарга каләм биргән.
Узып мәктәп баскычларын
Вузга китте күпме яшьләр.
Тракторларга, танкларга
Утырдылар авылдашлар.
Урап кайтты Европаны
Салкын-Алан малайлары
Залларында рейхстагның
Уелып калды имзалары.
Акбур белән коймаларга
Язып йөргән шаяннар да
Күкрәкләргә орден такты...
Шулай булды кай арада?!

---

[1] Ликбез — ликвидация безграмотности.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Китеп барды тагын бер яз,
Җәйләрне дә булмый тотып.
Сандугачлы Салкын-Алан
Калды кошлар җырын отып.
Җырлар отты,
Муллык отты,
Ул бодайның шәплекләре!
Дөбердәтте бөтен эшне
Нури абый шәкертләре.
Дулкынланып үзләренчә,
Уйга салып сабый башны,
Беренчеләр килде көзгә,
Яулап алды буш классны.
Шытым биргән гөлләргә дә
Без яшибез хәйран калып.
Имчәк тоткан нәни куллар
Өлгерделәр каләм алып.
Хыяллары океан гизә,
Коенсалар да ялгашта.
Бар булачак профессор да,
Космонавт та бу класста.
Үзгә булды быел җәйләр,
Узды тирән эзләр салып.
Эзтабарлар
Волгоградтан
Кайтты Газиз исемен табып.
«...Ватанына биргән антка
Туры калып ахыргача,
Огнеметчы Газиз Гатин
һәлак булды батырларча».
...Ялангач мина төшеп,
Ут ачкан ул утка каршы.
Һәм үлемнән йолып алган
Канга баткан авылдашын...
Шушы саран, кырыс сүзләр
Айкап узды күңелләрне.
Раслап кайтты пионерлар
Нури күптән сизенгәнне.

### 2

Үсеп килә яңа мәктәп;
Кызу эшләр арасында,
Авылдашлар өмә ясап,
Өлеш кертә янасына.
Эзтабарлар кайткач
Сырур
Килде мәктәп өмәсенә.
Атлап узды уйчан гына
Укып йөргән классына.
Күзе төште зур картага...
Исемнәргә карта саран,

Идел дә бар,
Кама да бар,
Сыймый калган Салкын-Алан!
Салкын-Алан!
Нурын өстәп,
Моңын өстәп каеннарның,
Илтеп куша зур Иделгә
Шатлыкларны, кайгыларны.
Сыйпап уза нәни елга
Мәрмәр ярын Волгоградның.
Лэйсән яңгыр булып яу син
Каберенә һәр солдатның!
Глобусны алды Сырур,
Игътибарны сизми генә...
Әйләндереп җир шарын ул,
Газиз каберен эзли гүя.

## 3

Мәйдандагы атынчыкта
Шаяралар җилләр генә.
Анда дисең атынмаган
Заманында кемнәр генә.
Атындырган Газизне дә
Шул борынгы имән таган.
Бишек иткән яшьлегендә
Аны бөтен Салкын-Алан.
Дәрес бирә Нури абый,
Һәр баланың җанын тоеп.
Укытучы
сабый күңелен
Өр-яңадан ясый коеп.
Наян халык!
Шуклык җене
Посып тора һәр караштa.
Бала ничек бала булсын
Шаянлыгы булмагач та.
Булмасын тик боек йөзләр,
Әйдә, кайчак үртәсеннәр, —
Кызганучан караш белән
Йөрәгеңә үтмәсеннәр.
...Шыр сөяктән калган тәнгә
Үлеп беткәч җан өрделәр.
Карый алсын күзләргә дип,
Протезларга мендерделәр.
Күпме газап кичерсәң дә,
Рәхмәт яшәү биргәннәргә.
Кайтарырга ләкин ничек,
Бурычың калса үлгәннәргә?
Авылдашлар йөргән юлда
Аның ярты гомере узды.
Басып металл буыннарга
Күтәреште ул колхозны.
Син бурычлы ләкин һаман
Яшәсәң дә батырларча.
Җирдә яткан Газизләргә
Бурычлы син ахыргача!
Хыяллары үлгәннәрнең
Күңелләрдә яши күкрәп,
...Сискәнешеп ала класс,
Протезлары күйса сыкрап.

* * *

Океаннарга чыкканым бар
Басып елга салларына.
Гудок бирде корабларым
Ничә диңгез ярларына.
Кайтып сулар эчми йөрсәм
Туган яклар елгасыннан,
Мин йомычка булыр идем
Шул океаннар дөньясында.
Кешеләрең кайнар җанлы,
Булсаң да син «Салкын-Алан».
Синнән алган ялкын белән
Яшим мин дә,
ялкынланам!

*Әлмәт, 1967.*

## Әхсән Баянов

### Синең вөжданың

(ДИАЛОГ)

— Кычкырсам мин чыгып трибунага,
Афишага менеп елмайсам,
Бу — мин түгел, колак, күзләрегез
Ышанмасын моңа һичкайчан.
Ун маркалы затлы эчемлектәй
Китерсәләр мактап өстәлгә,
Бу — мин түгел, күренмәм дә бәлки
Бәйрәмдә сез шатлык эчкәндә.
Макталуга тотмыйм исәп бер дә,
Мөмкин мине хәтта тиргәргә.
Тик җаныгыз сулыгып сызлаганда,
Йокысыз төн, моңсу көннәрдә
Ишетегез минем тавышны сез...

Икәү генә калып күзгә-күз,
Җавап эзлик — миллион сорау алда,
Газапласам күбрәк, кума, түз.
Ташлама син, таптама син мине,
Яратмыйм мин идән тузанын...
— Төсең дә юк синең, исең дә юк,
Кем син, әйт, әй!
— Синең вөжданың.

1968

### «Мин—диңгез»

Мин — диңгез.
Сез, кешеләр,
Герой улыгызны
Минем ярга китереп күмдегез.
Мәрмәр куеп китте берегез.
Мин күрдем,
Мин — диңгез,
Мин — диңгез.

Мин — диңгез.
Сез, кешеләр,
Бу егетне сагынып,
Кабат-кабат монда килдегез.
Яшьсез елый иде күзегез.
Мин күрдем,
Мин сиздем,
Мин — диңгез.

Мин — диңгез.
Сез, кешеләр,
Бәхет белән мавыгып,
Шаярдыгыз соңрак, көлдегез.
Кайгы белми хәзер күбегез.
Мин беләм,
Мин сизәм,
Мин — диңгез.

Мин — диңгез.
Мин — диңгез.
Сез, кешеләр,
Көннәр, еллар узып,
Шушы ярда көн дә йөрдегез,
Күрмәде бит шунда берегез:
Мин ярлар
Җимердем.
Мин — диңгез.

Мин — диңгез,
Сездән, кешеләр,
Алдым җимереп,
Кочагымда хәзер егетегез.
Төнлә түгел, алдым бит көндез!
Җимердем
Таш ярны!
Мин — диңгез.

Мин — диңгез.
Әй, кешеләр,
Бәхеттәнме сезнең,
Ояттанмы алсу йөзегез?
Берни сизми һаман күбегез:
Талчыгам
Ачудан,
Мин — диңгез.

Мин — диңгез.
Сез, кешеләр,
Җуеп ишетүен,
Күрмәс булса әгәр күнелегез,
Актарылган ярга килегез.
Килегез!
Мин — диңгез.
Мин — диңгез!

1967

# Кеше кайгысы

*Мәршидә истәлегенә*

Килде тыйнак
Чакырылмаган кунак.
Килде,
Хәнҗәр сымак,
Көзге тын төндә;
Җимереп төннең бөек тынычлыгын,
Керде кайгы
Күрше өенә.

Үкседеләр...
Күкрәктәге килеш буылса да
Төнне куркытырлык тавыш,
«СОС» сымак,
Торды чыңлап... —
Ишеттем мин.
Янды күкрәк,
Күршем йөрәге тәсле сулкылдап.

Җылы юрган, йомшак мендәр тәнне
Кабынып китәр булып пешерде.
Мин йөрендем.
Мин басканда
Идән
Сулкылдады,
Вөждан шикелле.
Ярдәм итик ничек?
Аста утлы күмер —
Күзлы кайгы...
Кеше кайгысын
Болай йөреп, таптап рәнҗетүдән
Авыррак хәл бармы, бармы соң?!
Нишлим?

...Ә хәбәр бит килде башта безгә.
Күрше-тирә
Авыр хәбәрне
Куарга без тырышып
Кич уздырдык.
Ул түзде тик төнгә кадәрле.

Төнлә керде кайгы
Күрше өйгә.
Вакыт кебек,
Туар көн күк туры, рәхимсез.
Йөрде үксү...
Кичерегез,
Ярдәм итик ничек, нишлик без?

...Үзе иң зур кайгы:
Мондый чакта
Ярдәм итми һични, һичнәрсә.
Дус булсак та, меңнәр булсак та без,
Язмыш килсә, аерым сөйләшә.

1968

## Ышан елларга

Нидер әйттең,
Һәм ташладым мин дә,
Бүтән сүз урынына бөтенләй:
Авыр сүз бугай.
Киттең.
Үләннәрне түгел, киттең таптап
Елларны шулай.

Мин алдадым бугай
Сине һәм үземне.
Син ышандың.
Коеп күз яшедәй чиста чыкларны,
Киттең.
Эзләреңне иртән кояш алды,
Авыр сүз калды.

Язгы кырда, тирә-якта
Күтәрелә төтен.
Бөтен чүп-чар яна, чиста кала:
Туфрак — кап-кара.
Киттең.
Сиздем: кирәк булган ул сүзләрне безгә
Утка атарга.

Язгы туфрак
Зарыгып бөртек көтә.
Челләләрдә сусап игеннәр
Янгыр көтәрләр.
Киттең.
Сине сагынып сүнәр минем
Кичләр, иртәләр.
Утлар ягам.
Чиста калсын күнел,
Син дә яндыр шулай, я булмаса
Ташла суларга.
Кайт син,
Тиз кайт!
Ышанма син минутларга,
Ышан елларга!

1968

●

Уйладым да кабат кайтасымны,
Бикләмәдем басу капкасын.
Тәнем китсә, синдә җаным кала,
Өшетмичә, авылым, сакларсың.
Авыл башындагы таныш өйләр!
Кайткан саен каршы алгансыз;
Киткән саен туган җирнең соңгы
Теләкләрен әйтеп калгансыз;

Кайткан чакта ерак мәктәптән мин
Берегезгә туңып кергәнмен;
Чакырганнар мине мич янына —
Ул җылыны саклый йөрәгем.

Тыңламагыз, оныткан ул диеп,
Кемдер нахак сүзләр китерсә.
Сагынуым булыр, җил-хәбәрче
Тәрәзәләр какса кич-иртә.
Мин бәхетсез, әгәр түрегездә
Инде миңа җылы калмаса.
Бурычым бетмәс, беләм,
Тик сөюем
Җырлар булып кайта лабаса!
Теләкләрем яши һәрбер өйдә:
«Капкаларны хәвеф какмасын,
Тәрәзәләрне такта капламасын,
Капласа, тик гөлләр капласын».
...Чәчәк тотып каршылаулар көтмим,
Сөйми, ахры, диеп баш ватып,
Тиргәмәгез бары.
Юкса авылым
Калган төсле булыр таш атып.

1967

## Уянсалар

*Сибгат Хәкимгә*

Мусалар уянса, торсалар,
Тезелеп барсы да яңадан,
Колонна, колонна булсалар,
Тулырлар һәм шаулар иделәр
Җирдәге бар урам, бар мәйдан.

Килсәләр җыелып Мусалар,
Бәхетне, яшисе елларын
Кайтарып бирергә кушсалар,
Калтырар иде бар күк йөзе,
Каушатып кешелек вөҗданын.

Җыелса, кычкырса Мусалар,
Гүрләрдә аларны тыңлар да,
Сискәнер мәңгелек дошманнар,
Һәммәсе кузгалып куяр да,
Теләмәс чыгарга дөньяга.

Чыксалар мәйданга Мусалар,
Бүгенге дошманнар куркудан
Хыялда мең сугыш корсалар,
Әйталмас иделәр һичбер сүз,
Язып тел, акылдан һәм кулдан.

Аналар күз яшен жыйсалар,
Ясалыр бер океан, өр-яңа.
Шауласын ул сөенеч яшьләре,
Ургылсын ул океан елларга.
Чыксыннар мәйданга Мусалар!

●

Сөйгән җирем, төнге киңлек,
Кемнәрнедер чит күреп,
Тын каласың кайбер көнне,—
Ташлашкан ярлар шикелле,
Кичәге дуслар кебек...

Сөйгән җирем, без икәү бит
Сөйләшәбез — «син»гә «син».
Ач әле, зинһар, сереңне,
Азмы таптау, казу сине
Ә син мәңге ямь-яшел...

Юк-бар сүзләрдән дә минем
Йөземне каплый сагыш.
Ургылып вулкан шикелле,
Нишләп әле бөтенебезне
Капламый синең каргыш?

Сөйгән җирем, тавышың килде,
Җилләр, ахры, китерде.
Яфрак сүзе, кошлар теле,
Чишмә җыры шикелле,
Синең сүзләр ишетелде:

«Бала! минем рәвешем шул:
Тау, үзән, урман, дала.
Мин — йөрәк, сизәм барысын,
Ашый мине ут, су, салкын,
Гүя сине — шик, яла...

Тетрәр идем, вулкан белән
Шаулар идем мәңгегә,
Үземне гел яңартырлык,
Сезне кичерер, яратырлык
Көч тоймасам тәнемдә».

Сөйгән җирем, сереңкүптән
Йөргән икән хисемдә:
Шатлыгы җирнең — мәңгелек,
Син яшә, дим, аның кебек,
Син — Җир улы, түз син дә.

1967

Рэдиф Гатауллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

*(«Диңгез эзлим» китабыннан)*

●

Гомер бакый
булган — ышанганнар,
булган — алданганнар:
хыяллар, чынлык, дуслар, яшәү-язмыш —
бик күп алдаганнар.
Күпләр алданганнар.
Тик,
яшәсен алар! —
Бер кайгыдан коелып төшкән,
максаттан ваз кичкән,
язмыш ачысын күнеп эчкән
көчсез кешеләр түгел!
Бәлки алар —
үзсүзлеләр, йөрәклеләр,
көчлеләр, дип аталганнар,
Һиндстанны эзләп чыгып,
Америка ача алганнар;
тынгысызлар, оптимистлар —
бер генә түгел,
мең мәртәбә алданып та,
мең дә беренче очракка
барырга көч табалганнар.
Уйлан, каләм:
әнә шундый кешеләр бугай,
шагыйрь, дигән ат
алганнар!

●

О, күңелнең көче! —
Өстәлеңдә гөлләр сулса бүген,
күңелеңдә аның таныш исе;
сөйгән ярлар китсә,
мәңгелеккә
кала
яд итәргә исеме...

Дуслар китсә —
истәлеге,
шагыйрь китсә — күңел җимешләре,
шигырьләре.

Килә гөлләр исе...
Хыял көченнәнме,
истәлекме? Каян
ул исемнәр, күңел, синдә калган?
Фина, Альбиналар — алар кем дә,
Инессалар, Ленизалар — нигә?
Кышкы көндә
шагыйрь учагында
атыла зәңгәр йолдыз төркемнәре.
Алып кайта хәтер — китkән дусны,
ярны, шагыйрьләрне,
алып кайта —
калган исемнәре,
истәлеге, шигырьләре...
Күңелдә ут яна төн буенча,
таныш исле —
гөлләр дөрли анда.
...Ялгыз булып кара
шундый чакта шагыйрь,
һәм язмыйча кара!

●

Үземә дә сиздермичә,
Үземә кайтып барам.

Р. И.

Кайларда йөрмәдем,
кайларга бакмадым,
алыны, гөлеме,
аз түгел тапканым.
Кайларга кермәдем,
нәрсәләр күрмәдем,
ачылды йөзләрем,
ярылды эзләрем.
Дөньяның һәр көне
ал түгел, гөл түгел, —
аңладым, юандым:
гел түзем бул күңел!
Карадым дусларга,
карадым күзләргә;
киңәшләр бер булды:
— Эзләргә, эзләргә!
Булганны бүлештем,
тапканны өләштем;
акыллы кешедән
күп вакыт көнләштем.
Күгемә, җиремә
әле аз бакмамын —
эзләрмен...
(Эзлимен үземне!)
Әлегә тапмадым.

●

Нинди яз бу?
һәр көнемдә шатлык килә,
кайгы килми.
Ләкин гаҗәп:
бер шатлыгым арткан саен, бер дус кими.

Язмыш шаярамы шулай?
Шатлыгыма түшенә алмый
дуслар мине ташлап китә
яки алдый.

Сәер яз бу!
һәр көнендә бәхетлерәк була барам...
һәм кемнедер, нәрсәнедер җуя барам.

...Иң зур шатлык — бәхетемне —
(сине сөюем — сөелүемне)
мин һичкемгә әйтми торам...
Соңгы дустым бүген янда...
Ул да
кутәрәлмәс бу хәбәрне,
ташлап китәр мине. Куркам...

●

Бер як читтән торып карый алсам
көннәремнең әгәр агышын,
чуер ташлар булып калкыр иде
су читендә һәрбер ялгышым.

Әә елгалар шулай: башланганда,
гел ташлардан сикерә түбәнгә,
тик киңәйгәч комлы, зур ярлардан
тыныч ага...
Карыйм көннәргә:

Шаулы чагым, җырлы чагым бүген,
(ялгышлардан мәллә җыр туа?!)
Күңелем минем шул чагыннан риза,
ялгышларсыз картлык куркыта.

Юк, үкенмәм —
яшьлек ялгышымнан
мәнге төзәлмәслек яра алсам;
ләкин —
елгам койган җирдә уйланырга,
утырырга бер таш табалсам;
Әгәр бүген матур язалсам...

●

Ерак Марс авылы!
Башлап
мин дөньяны күрдем —
синнән.

Карап —
туган йорт тәрәзәсеннән.
Тәрәзәләр...
Өч малай һәм әнкәй — безгә,
дүрт тәрәзә дүртебезгә.

— Әнкәй, нигә һаман әле
тәрәзәгә тегәләсең?
Ни күрәсең?
Нигә һаман-һаман күзен яшьле синең?
(Үскәч белдек,
            еллар буе
ерак юлга карап көткән
кайтуын ул — әтиемнең...)

— Рәшит! Әйтче,
синең тәрәзә аша
ни күренә? Нинди кызык? Ни тамаша?
(Җәй булса — яшел басулар,
кыш булса — кар...)
— Ә син, Рәфит, ни күрәсең?
(Ана күренә олы урам,
аннан — урман...)
Ә мин карыйм күрше авылга
                        илткән юлга,
юлга няреп
үйлар сәяхәткә чыга...
— Күрше авылдан соң ул юл, әй, кая китә?..
Юлның ахыры кайда?
            Җирдә? Күктә? —
Ә абыйлар җавап бирми, дәрес ятлый,
һаман да бер сүз кабатлый:
— Барлык юллар Римгә илтә, Римгә илтә.
...Якын Марс авылым! Туган йортым,
туган җирем! —
Мин дөньяга чыктым
                    тәрәзәңнән синең.
Кайткан саен (искергән өй исән әле)
тәрәзәмнән һаман карыйм...
Юллар күренә... (еллар күмелә).
«Кая илтә?» дип сорамыйм.
Беләм хәзер: барлык юллар Римгә илтми,
Тормыш ләкин ирне кайда гына
                        йөртми?!
Юллар алга,
юллар артка...
юл — шатлыкка,
кайгыларга,
хыялга, чынга —
барысына алып чыга...
Көрәшкә кертә,
            бәхеткә илтә.
Мина, бәлки, шулар җитә?!

•

Әллә бик тугры түгелбез,
әллә инде тынгысыз без,
һаман-һаман үзгәрәбез.
Эзләнәбез...
Кичә табынган алланы
онытып, бүген
янасына ант бирәбез,
күңел диварларына һаман
яңа рәсемнәр эләбез.
Яңа җыр өйрәнәбез,—
кырык көйгә көйләнәбез,—
Кумирларны искерәләр,
үзебезме
акыллыга әйләнәбез?!—
Үзгәрәбез...

•

Ул чакта мин сине көткән идем
Казанның бер яшел урамында...
Ә син, очрашканда
танымаганга салышып,
узып киткән идең.
Ничә тапкыр яшел төскә кайтты урам —
ул урамны хәзер читләп узам.
Үзем һаман әле мәхәббәтнең
мине син калдырган
кыен ноктасында торам.
Ләкин инде сине көтмим, ышан!

•

Зур рәхмәт тапкан анама:
мин — талант,
көчле талант.
О, горур гүзәл! Син мине
шул талант өчен ярат?!
Тик уйлама... минем көчем —
шагыйрьлек түгел, бүтән...
Мин — гашыйк, кешеләргә мин —
кояштай сөю йөртәм.
Мин сиңа карыйм, матур син
илаһи көчләр белән,
ә мин — өстен. Мин янып һәм
яндырып сөя беләм.
Сөю илтәм сиңа! Шуңа —
мин — талант, көчле талант...
О, горур гүзәл шагыйрьне
шул талант өчен ярат!

## Булат Сөләйманов

●

Мин ялгызым йөрим урамда,
Бар да таныш, бар да ят монда.

Чал Себердән Казан каласына
Кемне эзләп килдең, йөрәгем!
Салкын җилле бураннарың белән
Кемгә бар соң синең кирәгең!

Йортлар гүя бармак янап кала:
Күрмәгәнең монда күрерсең!
Төнге утләр канат кагып көлә:
Әй, адашкан, нишләп йөрисең!

Урам буйлап тагын алга үтәм,
Әнә мәйдан, тагы алгарак,
Кара плащ ябынып шагыйрь тора, —
Таш һәйкәлнең киләм янынарак.

Карашлары белән һаман гашыйк,
Ул Казанны сөеп туймаган.
Хисен язган халкы йөрәгенә,
Берсен дә ул ташка уймаган.

Кара плащ ябынып шагыйрь тора,
Учы белән тоткан йөрәген.
Мин китердем аңа чал Себернең
Күкрәгендә шыткан гөлләрен.

Мин ялгызым йөрим урамда,
Бар да таныш, бар да ят монда.

●

Кара төндә, аулак өйдә
Ике йөрәк бергә янды.
Ә урамда — яңгыр яуды...
Аннан... кызның күзләреннән
Тамчы булып өзелеп-өзелеп,
Мәхәббәте җиргә тамды.

●

Мин Себердә туып-үскән егет,
Туган җирне
Аркылыга үттем, буйга да...
Мин бәхетле!
Әгәр үзем кебек йөрсә җырым,
Юллар салып кыргый тайгада.

Кирәй Мәргән

# ПАРЧАЛАР

*Күренекле галим, филология фәннәре докторы, профессор Кирәй Мәргән исеме мәдәният кешеләренә күптән таныш. Ул озак еллар буе СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалында әдәбият һәм фольклор секторларын җитәкли. Хәзерге көндә Башкорт дәүләт университетында татар филологиясе кафедрасының мөдире булып эшли.*

*Кирәй Мәргән танылган әдип тә. Аның пьеса һәм романнары, повесть һәм хикәяләре илебез халыкларының бик күп телләренә тәрҗемә ителгән. Соңгы елларда ул язучының иҗат лабораториясен, иҗат эшенең күп төрле үзенчәлекләрен һәм психологик якларын чагылдырган хикәяләр җыентыгы әзерләде. Журналыбызның бу санында шул циклга караган хикәяләрнең берничәсен укучыларга тәкъдим итәбез.*

РЕДАКЦИЯ

## Тыңламады

— Сезгә ни булды? Ни өчен бик күңелсез күренәсез?

— Ни булганын сөйләргә дә кыенсынам инде, туган. Просто оят. Хурлык!

— Бәлки ачыграк әйтерсез...

— Ачыграк әйткәндә шул: балам ташлап китте.

— Балагыз ташлады?

— Әйе, әйе, баш бирмәде дип әйтимме инде, сүземне тыңламады дип әйтимме, кыскасы, мин теләгәнчә эшләмәде. Менә шул.

— Да-а. Моның киресен ишетергә туры килгәне бар, әлбәттә. Ә сез әйткән хәл, дөресен әйтергә кирәк, сирәк очрый. Димәк, үзегез гаепле инде, туган. Балагызга тиешле тәрбия бирә алмагансыз.

— Нинди тәрбия?

— Соң, атасын тыңламаган баланы тәрбияле дип булмый инде.

— Нинди бала ул тагы?

— Бәй, бәй! Үзегез бит әле «балам китте» дип сөйләп торасыз, тыңламады, дисез.

— Китүен китте, әйе, тыңламады. Ләкин, чынын әйткәндә, ул бит инде бала түгел, олы кеше.

— Олы булмагае, карт булса да, сезнең баладыр бит инде, үзегезнеке?

— Минеке, әлбәттә, үземнеке. Ләкин бит ул чын бала түгел.

— Һе. Баланың чыны, ялганы буладыр шул! Кем соң алай булгач?

— Бер яктан караганда, әлбәттә, ул минем балам. Әйе, мин тудырган, мин дөньяга чыгарган зат. Ләкин аны турыдан-туры балам дип әйтүе дә кыен. Беләсегез килсә, мин тудырган образ ул. Соңгы әсәремнең төп герое.

— Образ? Сезнең героегыз?

— Әйе, беләсезме, күңелемдә генә тудырдым мин аны. Ләкин барыбер ул яши. Менә әле дә күз алдымда: йөри, утыра, сөйләшә. Хәтта тавышын да ишетәм мин аның!

— Юк, мин андый геройны белмим.

— Дөньяга чыгып җитмәгән әле ул. Кулъязмамда гына яши. Китап битенә кергәч, аны сез дә күз алдына китерә алырсыз. Уртача гына буйлы ул, какча йөзле... Төсе-башы, сыны, кыяфәте һәммәсе дә үз урынында. Кыскасы, унай геройлар өчен хас булган басынкы һәм эчтәлекле биография бирдем мин аңа, матур гомер бүләк иттем. Ә исеме! Исемне мин аңа өч көн буе сайладым һәм таптым: Дәүләт. Тыңлыйсызмы? Дәүләт! Әйтер өчен дә уңайлы, егетнең басынкы табигатенә дә туры килеп тора. Менә шул Дәүләт дигән егет салды мине кайгыга!

Бу сүзләрне ишеткәч, күршем шикләнепме, аңларга теләпме, озак кына миңа карап тора һәм әкрен генә сорау бирә:

— Шаять сез мине ахмак дип уйламыйсыздыр бит?

— Ни эшләп алай дисез? Мин бит... Мин бит сезгә...

Күршем, бөтенләй икенче якка әйләнеп утыра һәм борылып мине әрләп ала:

— Балаларга сөйләгез сез андый хәбәрне, ямә! Минем кебек олыгая башлаган кешенең башын катырмагыз. Аңлашыламы?

— Аңлашылмады шул, — дим мин көрсенеп, — менә шуны аңлатып булмады сезгә!

— Соң, үзегез тудырган образ булгач, шул җирен генә сызыгыз да ташлагыз! Сызыгыз да тагын икенче төрлерәк итеп, үзегез теләгәнчә, язып алып китегез.

— Булмый шул, дус кеше, булмый! Мин үзем дә шулай итеп караган идем... Ә Дәүләт һаман үзенекен таләп итә: алай түгел, менә шулай булырга тиеш, ди. Тәмам аптыраган инде!

Мин ярсып-ярсып күршемә Дәүләтнең биографиясен сөйләргә тотындым. Күреп торам инде: ышанмый теге, күзләрен бераз кыса биреп, иренен бөрештергәләп, һаман эндәшми утырган була: «Сөйлә әйдә, сөйлә!»

— Беләсезме, — дип дәвам итәм мин аңа ни дә булса әйтергә ирек бирмәстән, — урта мәктәпне тәмамлаттым да, аны мин бер совхозга эшкә җибәрдем. Ә ул үзе институтта уку теләге белән яна. Ни эшләмәк кирәк, мөмкинлек юк. Закон буенча ике ел эшләп алырга тиеш. Совхозга килде бу, яхшы гына эшли башлады. Шуннан бит инде, срокны җиңел генә үткәреп, институтка җибәртеп булмый. Бик кэры чыга. Тоттым дэ мин Дәүләтне эш белән нык лап мавыктырырга булдым. Теге, шунда янып йөри торгач, институт турында бөтенләй онытырга тиеш иде...

— Ә менә монысы хата! Җиңеллек бу!

— Туктагыз, сабыр итегез. Мин аны, әлбәттә, соныннан барыбер җибәрәчәк идем. Әйе, соңыннанрак... Моның өчен хәтта мин бик унай бер «йөреш»тә әзерләп куйган идем. Менә болай: Дәүләт институт турында уйламый башлагач кына, совхозга шәһәрдән бер кыз килә. Институттан. Практикага...

— Һәм сезнең героегыз мотлак ул кызга гашыйк буламы?

— Әйе.

— Һәм шушы мәхәббәт аркасында институтка киту дәрте кабат аның йөрәген биләп аламы?

— Әйе, шулайрак уйланылган иде.

— Менә монысы арзан алым. Тапалган, кырык тапкыр ишетелгән нәрсә.

— Туктагыз әле. Ашыкмагыз, эш бит барыбер мин уйлаганча барып чыкмады. Дәүләт үзе ошатмады бу юлны: «Син мине, ди теге, андый алдан ук әзерләнгән төче юлдан йөретмә. Уңышлы булмас, кеше дә ышанмас. Андый вакыйгаларга килеп кергәнемне мин үзем дә сизми калырга тиешмен!» Күрәсезме, ничегрәк диктовать итә!

— Сон, кабаттан нәрсә эшләттегез?

— Шуннан мин ул егетне көннәрнең берсендә килеп, тоттым да якындагы станциягә җибәрдем.

— Станциягә? Ни өчен?

— Хәзер әйтәм. Шул көнне шәһәрдән совхоз директорының кызы кайтырга тиеш иде (әнисе белән). Директор хатынына совхоздан машина барамы? Бара. Бик яхшы сәбәп бит әле, мин әйтәм, шул машинаны әлеге егет Дәүләт алып барсын...

— Нигә, шофер булып эшлимени әле ул?

— Әйе, шофер! — дим. Мин инде үз көймәмнең комга утыра башлаганын тоеп, алдаша башлыйм. — Шофер ук түгел, ну, өйрәнчек. Машина йөртә белә инде. Политехнизация үтәләр бит. Шуннан ни, бу әлеге әниле-кызлы ике пассажирны алып кайтыр. Юлда теге кыз белән Дәүләт арасында мәхәббәт җебе сузылып калыр. Һәм шул җеп Дәүләтнең алдагы язмышын билгеләргә сәбәп булыр.

— Монысы бераз тормышчан сыман. Тик әле һаман тапалган якка китеп бара.

— Юк шул. Дәүләт алай итмәде, сез әйткән тапалган якка бармады ул, каһәрең. Машинаны да, вакыйганы да үз юлы белән алып китте.

— Я, я, ничек булды, сөйләгез?

— Ул станциягә килеп төште. Әлбәттә, машинасын бик шәп алып килде. Чөнки мондый бәхет әле аңа сирәк төшә. Әгәр гараж мөдире Мансур агайның эше булмаса, бу аңа тәтемәгән булыр иде! Килде, бераз көтеп утырды. Поездны каршылады. Ләкин кирәкле пассажирлар төшмәде. Шуннан машинаны борып кире кайтыргамы, әллә тагын икенче поездны көтәргәме дип кенә утырганда, мона ике кеше килде. Берсе армиядән кайтып бара, икенчесе аны каршыларга килгән. Илтеп куюны сорадылар. Бу тыңлады. Хәтта тегеләр белән буфетка кереп «юл аягы» төшереп чыкты һәм җилтерәтеп тегеләрне алып та китте.

— Шуннан, шуннан?

— Менә шул! Һич тә мин теләгәнчә барып чыкмады бу! Әле менә шуны уйлап утырам: я ул машинаны кайда булса алып барып бәрергә тиеш, я инспектор кулына эләгергә тиеш бит.

— Шуннан, шуннан?

— Менә шулай ул бәлагә эләгергә тиеш һәм шул бәладән соң инде ул үзе өчен уңайсыз шартларда теге кыз белән очрашырга тиеш.

— Менә монысы табигыйрәк яңгырый, ышандыра... Ә бит образның көче шунда: ул сине ышандырырга һәм җәлеп итәргә тиеш.

Мин җилкәмнән авыр йөк төшкән сыман хис итеп куйдым. Димәк, ышандыра. Димәк, Дәүләтнең язмышы өчен башкача кайгырырга ярамый... Димәк, мин теләгәнчә эшләнүе яхшыга булган!

Дөрес әйтәләр шул: һәр образның үсеше бар!

Күршем тагы нидер сөйләнә, ләкин бу юлы инде мин аны тыңламыйм. Минем башымны башка уйлар урап ала хәзер: күпме шундый уңышлы образлар тудыра алдым икән мин дип уйлыйм. Һәм шуларның күпмесе кеше күңеленә барып җитә алды икән? Әгәр дә җитә алган булсалар, димәк, алар кайдадыр, кемнәрнеңдер янында йөри бирәләр, кемнәрнеңдер күңелендә яшәп яталар. Әнә шундый образларым күбрәк туса иде ул!

# Серле сөйләшү

Иртәнге томансу һаваны ярып, ашыгып кына бульвар буйлап китеп барганда, берәү минем беләгемнән тотып алды.

— Кая болай ашыгасыз?

Бик таныш бер кыз тавышы булды бу. Мин шунда ук аңа борылдым һәм, гаҗәпләнеп, катып калдым: янымда бер кем дә күренмәде.

Мондый гайре табигый очрашудан тизрәк котылырга теләп, мин тиз генә алга атладым. Ләкин ягымлы тавыш мине җибәрмәде:

— Туктагыз инде, ашыкмагыз.

— Кем буласыз соң сез? Ни кирәк сезгә?

— Ни кирәк дип, ни, мин бит инде сезнең өчен ят кеше түгел,— дип дәвам итте ягымлы хатын-кыз тавышы, — хәтта би-ик якын кеше.

Дөресен әйтергә кирәк, шикләнү генә түгел, мин инде хәтта шүрләп куйдым: шаярумы бу, әллә... Юк, юк, мондый очракта һәр чак каты булырга кирәк. Һәм мин дә кырт кисеп җавап бирдем:

— Сезне белгәнем дә, күргәнем дә юк. Китегез тизрәк янымнан. Комачауламагыз.

— Юу-ук, мин комачауламыйм бит, — ди әлеге тавыш, бу юлы бераз кыланчыклана бирсп. — Менә шулай аз гына яныгыздан барыйм әле. Сүзем бар...

— Кем соң сез? Кайдан килдегез?

— Минме? Мин сезнең китабыгыздан төштем.

— Китабымнан!

— Әйе, әйе. Мин — сез тудырган шәхес. Хәтерегездәме, бик озак сез мине күңелегездә йөрттегез. Ул чакта мин сезгә бик якын идем. Мине һәр вакыт үзегез белән бергә ала идегез. Хәтта кинәш иткән чакларыгыз да булды. Шуннан ни... Шуннан вакыт житкәч, сез мина китап битендә урын бирдегез дә дөньяга, кешеләр арасына, чыгарып җибәрдегез.

— Шуннан, шуннан?

— Шуннан соң инде үзегез мине бөтенләй оныттыгыз.

— Я, я...

— Менә мин, шулай, кеше арасында йөреп ятам. Алар белән эшкә барам, бакчада утырам, өстәл янына киләм, вагон купесына керәм, бергәләп курортка йөрим...

— Әһә! Димәк, алай булгач, сез үз бурычыгызны үтәгәнсез. Димәк, мин дә...

— Ашыкмагыз әле, ашыкмагыз. Мин, әлбәттә, сез кушканнарны мөмкин кадәр төгәл үтәргә тырыштым. Сез әйткәнчә, мөмкин кадәр ягымлы булырга, алып караган кешеләргә ошарга тырыштым. Ләкин...

— Нәрсә тагы?

— Барысына да ошап булмады.

— Ошап булмады? Ни өчен?

— Менә шулай, берәүләр минем танавымны ошатмый, икенчеләре — күзләремне, ә өченчеләренә көлүем табигый күренми...

— Болары инде аның мөһим түгел: тышкы кыяфәтегезгә кайтып кала.

— Алай гына түгел шул. Кайберәүләр мине, кыланчык, диләр. Икенчеләре, тагы төчерәк булгансыз, диләр. Өченчеләре бөтенләй җиңел табигатьле хатыннар рәтенә кертәләр. Менә шунысы бигрәк авыр! Сез үзегез бит инде бер дә мине алай күрсәтергә уйламаган идегез.

— Юк, әлбәттә, сез уңай герой бит.

— Шулай шул. Мин үзем дә инде, сез язганча, уңай күренергә тырыштым. Ләкин ул гына җитми икән шул.

Бу сүзләрдән соң мин, үз гаебемне тоеп, мәсьәләне тиз генә шомартырга яки икенчегә борып йомарга тырышкан кеше сымак, сер бирмәгән төс чыгарып, кулымны селтәп алдым:

— Анысы билгеле инде ул, — дигән булдым мин. — Һәркем тормышны үзенчә кабул итә.

— Монда бит сүз тормыш материалы турында бармый, ә аның чагылышы турында...

— Белмиммени инде мин аны!

— Әлбәттә, беләсез, сүз бит монда бөтенләй икенче турыда бара...

Тәкатем калмады хәзер минем, чиксез ачуым килде. Тоттым да, аңламаган укучысына лекциясен кабатлаган профессор төсе чыгарып, җитди һәм коры тавыш белән күптән билгеле булган хакыйкатьне тезә башладым:

— Икенчеме, түгелме, барыбер бер мәсьәләгә кайтып кала — образның тормышчанлыгы, яшәеше һәм укучыга барып җитүе... Тормыш материалын чагылдыру буенча бердәмлек булмаган кебек, шушы тормыш материалын чагылдырган сәнгать әсәрен кабул итүдә дә бердәмлек юк. Берәү ошатыр, икенчесе баш тартыр. Анда минем эшем юк!

— Тынычланыгыз. Ошаткан кешеләр күбрәк булса, үзегез өчен яхшырак бит. Образларыгыз озын гомерле булып чыга. Әсәрегез озак яши. Шулай түгелме?

— Монысы да күптәнге хакыйкать.

— Хакыйкать онытылмаска тиеш. Ә сез шуны онытып җибәргәнсез.

— Я, ярый, сезнеңчә булсын, — дидем мин, бераз тынычлана төшеп. — Хәзер мин сезне ни эшләтә алам? Кайда куям? Китабым битеннән кире тартып ала алмыйм бит инде!

— Ә нигә, ул китабыгызга яңадан кайтырга мөмкин. Абайлабрак карагыз, бәлкем, минем шикелле зарланып йөргән образларыгыз тагын табылыр...

— Юк инде, сезгә яңадан кайтырга минем вакытым да, мөмкинлегем дә юк. Мине хәзер башка образлар көтә.

— Һәрбер яңа нәрсә кадерле була инде ул, — ди мине озатып килүче хатын, көрсенеп. — яңа теккән кием матуррак була. Яңа пешкән икмәк тә, хәтта яңартылган чәй дә тәмлерәк була... Бәлкем, алар да матуррак, яшьрәк булырлар. Кешеләр, бәлкем, аларны, миңа карагандa, яратып кабул итәрләр. Ләкин шуны онытмагыз: алар да үзегезгә кире әйләнеп кайтырлык булмасын. Ә моның өчен ни кирәк икәнен үзегез яхшы беләсез инде. Хушыгыз. Берәр уңай чак туры килсә, бәлкем, тагын янгызга килеп чыгармын әле.

Минем күңелемдә аңа карата кызгану тойгысы кузгалды. Кулын ягымлы гына кысыйм әле, ичмасам, дип борылсам, ул юк иде инде.

— Хушыгыз, кадерлем, — дип куйдым мин, ярым пышылдап. — тагын килегез. Тик яхшы хәбәр белән килегез.

Аның тавышы колак төбендә генә тагы бер тапкыр яңгырап китте:

— Монысы сезнең үз кулыгызда!

Бу серле сөйләшү минем файдага булмады. Ләкин ул минем рухымны күтәреп җибәрде. Образларым әнә шулай килсеннәр иде, тик һәрвакыт яхшы хәбәр алып килсеннәр иде алар!

## Минем гөнаһым

Берәү мине буып алды.

Мин дерелдәп киттем һәм, куркуымнан ни эшләргә белми, әкрен генә тавыш бирдем:

— Кем син? Ни кирәк сиңа?

— Минме? — диде ул салмак кына, — мин синең гөнаһың булам.

— Гөнаһым? Минем гөнаһым. Юк, минем гөнаһым булырга тиеш түгел!

Теге мине ычкындырырга теләмәде. Тагы бераз кыса төшеп дәвам итте:

— Ю-у-ук, туган, — диде ул, — гөнаһың күп синең! Һәм, әйтергә кирәк, бәләкәй дә түгел. Һәр гөнаһ, йола буенча, әйләнеп килеп башкз төшәргә тиеш. Менә мин дә синең үзеңә кайттым. Әгәр дә менә минем кайдан ябралганымны, ни өчен килеп чыкканымны үзең яхшы һәм дөрес итеп билгели алсаң, мин торып китәргә әзермен. Әгәр инде, билгели алмасаң... миңа үпкәләмә!

Әлбәттә, мондый бәладән тизрәк котылу яхшы. Мин дә ашыга-ашыга хәтер сандыгымны актарып, дөньяда нинди аламалыклар эшләгәнемне барлый башладым.

— Бәләкәйрәк чакта әтиемнән яшерен тәмәке тарткалый идем. Шул гаебем гөнаһ булып алдыма килдеме әллә?

— Юк, анысы — пустяк!

— Эчүме? Анысы булды инде. Эчкәләдем...

— Юк, эчү синең өчен хас нәрсә түгел.

— Ә соң тагын нәрсә? Хатын-кыз ягыннанмы әллә? Әйе, бер чак мин урамнан үткәндә бер матур кызга карап сокланган идем. Юк, юк, соклану гына түгел, аның артыннан күзәтеп бардым мин... Хәтеремдә: мин аның алдына чыктым, борылып күзләренә карадам. Ул да елмайды һәм эре генә үтеп китте. Шул чак башыма яман уйлар килде: мин әйтәм, әгәр бу кыз минем хатыным булса, үзен ничек тотар иде икән... һәм хәтта... һәм хәтта...

— Юк, юк! Монда бернинди дә гөнаһ юк!

— Ә соң тагын нәрсә? Урлашканым юк минем, кешегә зарар иткәнем юк. Кайдан булсын ди ул гөнаһ?!

— Сайрак йөзәсең,— диде теге, тагын да якынрак килеп,— тирәнрәк уйла. Ләкин шуны бел: вакыт күп түгел. Ашык, тизрәк бул!

— Бәлкем, син минем гаебемә бәйле тумагансыңдыр әле. Бәлкем, бәлкем, син күбрәк минем бурычым тирәсендә йөрисеңдер?

— Менә монысы дөрес, якынаясың.

— Алай булса, алай дисәң... Әлбәттә, бераз урын бар шикелле. Әйе, әйе, аз гына түгел, хәтта күп тә! Мин әле күптән башымда йөргән вакыйгаларны сюжет итеп оештыра алганым юк. Гомумән, мин дөньяның тышкы матурлыгы белән мавыгып, күбрәк ләззәт алып калыйм дип, мәгънәсезрәк яши башлаганмын. Чын ләззәтнең анда түгел, бәлки дөньяны танып, аның матур ягын ача белүдә икәнен онытып җибәргәнмен. Әгәр дә бит шушы ачышымны мин дөрес итеп кәгазьгә төшерә алган булсам, үземне генә түгел, хәтта китабымны кулга алып укыган кешеләр өчен дә ләззәт чишмәсе биргән булыр идем. Кызганычка каршы, әнә шундый ачышларым аз булды минем!

— Әнә шул игътибарсызлыгың, шул кимчелегең, килә-тора синең гөнаһыңа әйләнде дә инде. Хәзер аңлашыламы? Аңлашылса ярый. Тик кабат минем турыда онытма, ямe? Ә оныта башласаң, мин тагын килеп чыгармын. Һәм... инде болай гына коткармам үзеңне! Хәзергә хуш булып тор...

— Тукта, тукта, китми тор, әле! Сүзем бетмәде минем!

Кинәт кенә килеп чыккан шикелле, бу шөкәтсез нәрсә шунда ук юк та булды. Мин уянып киттем һәм шушы мәрхәмәтсез нәрсәнең китүенә үкенеп куйдым.

— Ни эшләп ул элегрәк килмәгән соң әле минем яныма?



**Малик Хәмитов**

# ГЕОЛОГИЯ ДОКТОРЫ

ОЧЕРК



Яз житкәнен, җәй житкәнен көм дә көтеп ала. Берәүләр ял итәргә, ел буе эшләп арыган тәннәрен ныгытырга, дөнья, мәшәкатьләрен онытып, җылы ярларда су коенырга, кояшның шәфкатьле нурларыннан көч җыярга дип көтәләр елның бу матур айларын. Ә икенчеләре иса, киресенчә, җиң сызганып эшкә әзерләнәләр: игеннәрне үстерү, урып-җыю, бакчаларда тәмле җиләк-җимеш җитештерү, терлекләрнең кешегә иң күп файда бирү вакыты шул айлар бит.

Асия Дәминованың да бу матур айларда ял итәргә, җылы ярлардагы диңгез буйларында бөтен дөньясын онытып күңел ачарга хокукы бар. Хокукы да бар, мөмкинлеге дә бар. Ул — Мәскәүдәге төсле металлар институтының доценты, кафедра мөдире һәм хәтта институтта минералогия һәм петрография кафедрасын оештыручыларның берсе. Аның фикерләренә геология буенча профессорлар, академиклар да хөрмәт белән карыйлар. Ләкин эш анда түгел, аның үз омтылышы бар. Ул омтылышны тормышка ашыру — аның өчен ял да, күңел ачу да. Аның эше игенчеләрнеке кебек үк җир белән бәйле. Хәер, кешенең бөтен тормышы, барлык казанышлары җирдән башка мөмкин түгел. Тормышның чыганагы җир булган икән, аның бөтен эшчәнлеген, бөтен теләкләрен, бөтен яшәешен тәэмин итүче шул ук Җир. Җирдән аерылып галәм киңлекләрендә очып кайткан космонавтларның сүзләрен генә искә төшерик: алар өчен иң зур бәхет — Җиргә кайту. Син Җирдән очкансың икән, Җиргә кайтырга тиеш, аның кешеләрен, урманнарын, елгаларын, күлләрен, кырларын, хәтта анда яши торган ерткычларның ерткычы булган хайваннан башлап, теңкәгә тиеп бетә торган черкиләренә кадәр — барчасын, барчасын кабат кайтып күрү аның өчен иң зур бәхет.

Бу бик табигый: үз эшенең файдасын, үз эшенең җимешләрен күреп горурлану бик күп кешеләр өчен Җир белән бәйле. Бу игенчеләр өчен генә түгел.

Игенче үзе үстергән арыш бөртекләре, бәрәңге, кәбестә белән горурлана. Әлбәттә, «космос», «спутник», «атом» сүзләре ниндидер «бәрәңге» дигән сүзгә караганда бик матур, бик гайрәтле яңгырыйлар. Ләкин җирдә казынучылар хезмәтеннән башка — аларның берсе дә юк!

Игенче җитештергән икмәк белән бәрәңгедән тыш, шул ук җир космик корабльләр, станоклар, машиналәр ясау өчен никадәр казылма байлыклар бирә. Ә аларны геолог дигән һөнәр иясе эзләп таба.

Шуңа күрәдер, игенче эше белән геолог эше арасында уртак яклар бик күп. Игенчегә хас булган сыйфатлар — хезмәт сөючәнлек, түземлелек, тазалык, ихтыяр көче, киләчәккә өмет — геологлар өчен дә кирәк. Геологлар үткән сукмакларда, аңа кадәр кеше аягы басмаган җирләрдә игенче хезмәтендәге кебек авырлыклар, киртәләр тулып ята. Хезмәттән башка җир мул иген уңышы бирмәгән кебек үк, хезмәттән башка җир үз эчендә яшереп яткан байлыкларны да күрсәтми. Геолог булу өчен шулай ук физик көч тә, рухи сәлә тә кирәк. Җилкуарлар, ялкаулар игенче була алмый, андыйлар шулай ук геологиягә якын да килмәсен.

Игенче дә, геолог та тау токымнары белән эш итәләр. Туфрак кояш, һава, су тәэсирендә шулай ук тау токымнарыннан, таштан барлыкка килгән. Туфрак иң әһәмиятле табигать байлыкларының берсе. Димәк, игенчелек, җир эшкәртү үзе дә геология белән турыдан-туры бәйле.

Игенче җир, туфрак серләрен тирәнтен белеп кенә мул уңыш ала, шулай ук геолог та җир асты хәзинәсенә ачкыч яратырга тырыша. Ә ачкычлар күп. Кирәклесен сайлый белү өчен бик зур физик көч, фикер тирәнлеге, белем кирәк. Җир куенындагы хәзинә ишекләре һәркемгә үз йозакларын ачмыйлар...

Хәзинә ачкычларын яулап алу җиңел генә булмады Асия Дәминовага.

* * *

Зәя елгасына коя торган кечкенә генә бер Әрә дигән елгачык бар. Инеш дип әйтер идең, яз көннәрендә шактый дулап ага ул, елга дияр идең, җәйге эссе көннәрдә урыны белән тавык тезеннән генә кала. Ул елгачыкның уң ягы — үзән, сул ягы — таулар. Ә сульяк тау итәгенә урнашкан Әрә дигән авыл аша, җитмәсә, тирән-тирән ерганаклар үтә. Алар шундый тирән һәм текә — бер урамнан икенче урамга чыккан-да, шул ерганак ярыннан менә-менә, картларның түгел, яшь җилкенчәкләрнең дә тыны бетә.

Авылы шулай «алла каргаган» урында булгач, аның җире нинди булсын? Анда шуңа күрә гомер-гомердән җир тәмен белеп торучылар булмаган. Берәүләр сәүдә эше белән шөгыльләнгән, икенчеләре, моңа мөмкинлекләре булмаганнары, һөнәргә өйрәнү ягын караган. Тирә-юньдә — чуваш, татар авыллары. Алар чын крестьяннар. Ничек кенә булмасын, азмы-күпме җирдән табыш алалар, шуның белән тамак туйдыралар. *«Әрәләр — чиләк төбе бәрәләр».*

Бу әйтем хәзергә кадәр Әрә кешеләренә карата әйтелә торган бер кушамат булып калган. Әрә кешеләре авылдан авылга йөреп савыт-саба төзәтүче, чиләк, ләгән төпләүче, калайдан түбә ябучы булып йөргәннәр. Шуның белән көн күргәннәр.

Ә Мисбахетдин, яшь егет, бәхетне ераграктан эзләмәкче булган. Һәм ул билбавын буган да туган авылын калдырып, җәяүләп Төрләмә станциясенә барган, поездга утырып, авылдашлары янына, Екатеринбург шәһәренә юл тоткан. Һөнәрле кешегә «читтә» дә эш табылган.

Авыл егетләренең иң кыюлары, иң осталары, үз-үзләренә иң ышанганнары гына чит җирләргә китәргә батырчылык иткән. Әлбәттә, Мисбахетдин шундыйларның берсе булган. Авылларында аңа «зимагур Мисбах» дип кушамат таксалар да, ул, ничек кенә булмасын, бәхетен табарга тырышкан. Эшчеләр арасында тиздән үз кеше булып киткән. Өйләнеп җибәргән. Хәмзә туган, аннан Асия дөньяга килгән, аннары — Мансур...

Революция җиңеп чыкмаса, кем булган булыр иде Асия, әйтүе кыен. Бик яшьтән әтисез калган Хәмзәгә дә, Асиягә да, Мансурга да революция укырга, белем алырга мөмкинлек бирә.

Абыйсы Хәмзә Казанда укый. Мансур әле яшь. Ә ул инде акча табарлык зур кыз булган. Аның да укыйсы килә, ләкин әнисен һәм энесен кыен хәлдә калдыра аламы соң? Әгәр ул эшләмәсә, абыйсы укуын ташларга тиеш.

Күп уйлап тормый Асия, Уралга килгән бер геология партиясенә коллектор булып эшкә керә.

Менә шунда, таулар, ташлар актарып йөргәндә, геологиянең нәрсә икәнен белә дә инде Асия.

...Менә хәзер, Патрис Лумумба исемендәге халыклар дуслыгы университетында әзерлек курсларына килгән төрле ил яшьләре алдында чыгыш ясаганда, эченнән генә

шуларны исенә төшерә Асия ханым. Үзенең яшь кыз вакытларын искә төшерә, үзен тыңлаучылары урынына куеп сөйли. Һәм ул мөмкин кадәр гади итеп тау катламнарының үзенчәлекләре, аларның барлыкка килүе турында аңлата.

Ул таулар турында сөйли: Җир шарын каплап алган тау токымнары, беренче карашка, гел шулай булып үзгәрмичә ятканнардыр кебек. Әмма бу алай түгел, тау токымнары төрле геологик процесслар нәтиҗәсендә бер үк вакытта җимерелэләр һәм барлыкка киләләр.

Җир шарының 60 километр калынлыктагы кабыгы төрле каты, йомшак, сыланучан, таралучан массалардан гыйбарәт. Алар, физик сыйфатлары төрле булуга карамастан, барысы да тау токымнары.

Ә тау токымнары табигый рәвештә барлыкка килгән химик кушылмалардан һәм химик элементлардан торалар. Фәнгә өч меңгә якын минерал билгеле. Ләкин аларның берничә дистә төрен генә кешеләр киң куллана, бүтәннәре бик сирәк табыла.

Тау катламнары минералларның очраклы тупланууыннан гына гыйбарәт түгел, алар билгеле бер закончалыкны саклыйлар. Аларның үз тарихы бар. Алар барлыкка киләләр, аннары җимереләләр һәм бүтән бер матдәгә әвереләләр...

Шулай иттереп, Асия ханым әкренләп тыңлаучыларга геология фәнендәге үзе эшләгән өлкәнең нечкәлекләрен аңлатуга күчә.

* * *

Петрография.

Геология фәненең тау токымнарын өйрәнә торган бу тармагы буенча белгеч булып ирешкәнче, җитез һәм зирәк кыз Асияга күпләрне кичерергә туры килә әле.

Үзендә аның тырышлык та, омтылыш та, җегәрлек тә җитәрлек. Ләкин үзе турында кайгырмый ул. Бөтен семьялары белән күптәннән инде аталарының туган ягына — Казанга кайтырга хыялланалар алар. Хәмзә дә анда студент.

Һәм озакламый бу теләкләрен тормышка ашыралар.

Асия Казан университетының геология факультетына укырга керә.

1936 елда, диплом алганда, профессор Леонид Михайлович Миропольский Асия Дәминовага аспирантурада калырга тәкъдим итә.

Хәмзәнең үз семьясы. Мансур укый. Әнисенә стипендия акчасы белән генә ни рәхәт күрсәтеп була?

Шуларны уйлый да Асия, аспирантурадан баш тартып, эшкә китә. Эшкә, Урта Азиягә...

Әле хәзер дә Алтын-Тапкан дигән җирләрдә аның җитәкчелегендә үткәрелгән эшләрне телгә алалар. Өлкән геолог Асия Дәминова җитәкчелегендә тикшерелгән урыннарны дәүләт комиссиясе бернинди үзгәртү кертмичә кабул итә. Һәм ул соңыннан төсле металлар табу буенча рудник булып әверелә.

Әйе, ул өлкән геолог. Күрсәткән эшләренә тиешенчә бәя дә бирделәр. Хәзер Казанда Хәмзә дә, Мансур да әниләрен карарлар. Аңа да үз омтылышын гамәлгә ашырырга кирәктер бит инде. Яшь чагында, мөмкинлек барында укуны дәвам итәргә кирәк... Менә ул Мәскәүдәге геология-минерология институтына аспирантурага керергә дип гариза бирә...

Асия академик Владимир Иванович Лучницкий хезмәтләрен студент елларында ук белә иде. Ул аның петрография буенча берничә томнан торган хезмәтләрен, дәреслекләрен бик ныгытып өйрәнде. Ләкин бит Лучницкий аны белми. Конкурс зур. Дәрес, керү имтиханнарында биргән җаваплары фәнни эш өчен кызның сәләтле икәнлеген әйтеп торалар. Ләкин нинди профессор үзе белмәгән, сәләтен һәм эшчәнлеген үзе бәяләмәгән, яки, һич югында, үзе ихтирам иткән берәр галимнең характеристикасы да булмаган бер татар кызын аспирантлыкка кабул итсен икән!

Һәм Владимир Иванович бу кандидатны аспирантурага алырга теше-тырнагы белән каршы чыга.

Институтның аспирантура бүлеге мөдире Х. Абдуллаев (хәзер Үзбәкстан Фәннәр Академиясе члены) Асия Дәминованың Алтын-Тапкандагы күрсәткән хезмәтләрен сөйләп биргәннән соң гына аны конкурстан үткәрергә дигән карарга киләләр. Алай гына да түгел, академик Владимир Иванович Лучницкий аны үз группасына ала.

Ләкин соңыннан үкенгәндер ул. Ник дисәң, «шеф»ын ихтирам иткән кинди аспирант, минералларны аерып күрсәтергә кушкач, житәкчесе язган инструкцияне өстәлдә калдырып, башка бер галимнең — профессор Владимир Никитич Лодочниковның инструкциясен алырга йөгерсен. Петрография фәнендәге бу ике «туз»ның кайбер мәсьәләләргә карата фикерләр аерымлыгын белмәсен дә ди инде, ләкин олы кешенең хәтерен сакларга да тиештер ләбаса ул. Хәер, аспирант кыз бу инструкция белән дә өч меңгә якын минерал арасыннан академик сораганын аерып бирә алды. Ләкин бит...

Бу вакыйгадан соң, аның белән бергә укучы аспирантлар гына түгел, фәннәр кандидаты дәрәҗәсе алган институт хезмәткәрләре дә Асияга кул селтәделәр. Янәсе, бу институтта калуың инеле, кызый. Академик хәзер каныгып, теңкәңә тиеп бетәр.

Чыннан да шулай булды. Кырыс җитәкче, тырнак астыннан кер эзләгәндәй, аның һәр эшен үзе күзәтергә тырышты. Хәер, академикның бу каныгуы аспирант кызның булдыксызлыгын исбатлау өчен түгел иде инде. Ул бу кыю кызның һәрнәрсәгә карата үз фикере барлыгына ышанган иде. Ничектер, һәрвакыт, һәркемгә ачыктан-ачык дөресен ярып әйтә белә торган бу татар кызы академик өчен башка аспирантларга караганда да якынрак булып тоела башлады. Теоретик яктан да ул әзерлекле, практика буенча да бик күпләрдән өстен. Мәгаен, бу өлкән геолог сыйфатында Урта Азия далаларын кичү нәтиҗәседер.

Асияга фәнни конференцияләрнең берсендә петрография буенча В. Н. Лодочниковның яңа чыккан хезмәтенә карата чыгыш ясарга куштылар. Бу хезмәтне бик җентекләп өйрәнде ул. Һәм рефератында В. И. Лучницкий карашларына да тел тидермәде, В. Н. Лодочников хезмәтен дә артык тәнкыйтьләмәде. Бу ике зур галимнең аерым мәсьәләләрне чишүдәге уртаклыкларын тапты һәм аларны үзенең фикерләре белән нигезләде.

Бу конференциядән соң, Асия Дәминовага карата академикның игътибары бермәбер артты. Бу татар кызының чын галим булачагына тәмам ышанган иде инде ул.

Кандидатлык диссертациясе өчен яңа гына акфиннардан азат ителгән Ладога күленең төньяк яры тирәләрен, Питкярант районының петрографиясен өйрәнергә, бу райондагы казылма байлыкларны картага төшерергә куштылар аңа.

Ике студентны үзе белән коллектор итеп алып, 1940 елның җәендә ул шунда юнәлде.

Һәр җирдә әле күптән түгел, март аенда гына тәмамланган сугыш эзләре беленеп ята иде. Мондагы тау токымнарын картага төшерү белән бергә сугышның рәхимсез чынбарлыгын да якыннан күрделәр алар.

Геологларны башта ук кисәттеләр: һәр адымыңны бик сак атларга кирәк, кая карама — анда мина. Монда әле маетләрне җыйнарга да, миналарны зарарсызландырырга да өлгермәгәннәр. Агач башларына көтүе белән үләксә козгыннары, ала каргалар кунган, алар шомлы итеп кычкырышалар.

Җир өстенә һәркайда диярлек буш гильзалар, патроннар, винтовкалар чәчелгән. Җимерек туплар, пулеметлар еш очрый, ара-тирә җиргә бәрелеп шартлаган самолет калдыклары күренә. Якынгарак барып, җентекләбрәк карасаң, кайсын Америкадан китертелгән, кайсы Германиядә, кайсы Англиядә яки Франциядә ясалган икәнлеген күрәсең.

Ләкин Асияның эше аларны тамаша кылу түгел. Ул мондагы тау токымнарын өйрәнә. Петрографик яктан, ягъни тау токымнарының составы, төзелеше, барлыкка килүе ягыннан гаҗәп кызыклы икән бу район. Магматик тау токымнары биредә аккургаш рудасы ятмалары барлыгын күрсәтәләр. Ә безнең промышленность өчен бик кирәк бу металл...

Руда чыганакларын эзләү өчен никадәр хезмәт куела. Кеше аягы басмаган урманнар, сазлыклар, аланнар аша никадәр юл йөрелә, никадәр җир казыла! Күп очракта уңышсызлыкка очрыйсың. Дөрес, биредә бу тикшерүләрнең нәтиҗәсез булуы мөмкин түгел. Чөнки революциягә кадәр үк Ладога күленең төньягында аккургаш рудасы ятмалары барлыгы билгеле булган. Тик бу көнгә кадәр эзләнүләр генә алып барылмаган. Ә аккургаш промышленностьның һәр тармагы өчен кирәк. Эш бер анда гына да түгел, фән өчен бу җирләрнең геологик картасы да бик кирәк бит. Табылган тау токымнары, минераллар биредә йөз миллион еллар элек гыйар таулар атып торганын

курсәтәләр. Аккургаш рудалары, тирә-яктагы гранит ташлары — гранитоидлар да шул вулканнар эшчәнлегенең нәтиҗәсе. Җир асты хәзинәләрен шулар арасыннан эзләргә кирәк тә инде.

Көн артыннан көн үтте. Геологлар, лагерьны берничә урынга күчереп, йөзләрчә гектар мәйданны картага төшерделәр, анда очраган минералларның, тау токымнарының үрнәкләрен җыйдылар...

Бер көнне кинәт килеп яуган яңгыр туктаганын геологлар каен агачына ышыкланып көттеләр. Каен яфракларының файдасы аз булды, су хәтта өскә киган кожан аркылы да үтте. Хәер, яңгыр тиз явып үтте, ялтырап кояш чыкты, кошлар сайрарга кереште, геологлар өс киемнәрен кибәргә элделәр дә, юеш уланнарне ера-ера, якындагы калкулык янына юнәлделәр.

Яңгыр суы калкулык түбәсеннән үзәнлеккә юл салган, ерганак буйлап шаулап, күбекләнеп ага. Болытлар тиздән каядыр, диңгез ягына китеп юк булдылар. Күк йөзе ачык, зәп-зәңгәр булып калды. Кояш үзенең эсселеген бермә-бер арттырды кебек, ашыгып килгән геологлар тамам тиргә баттылар. Геологларның теңкәгә тигеч юлдашлары — озынборыннар, черкиләр яңгырдан соң тагын да күбәйделәр, баш өстендә болыт кебек булып арттан иярәп йөриләр. Битләр дә, муеннар да, куллар да инде тоташ күперәп чыкты.

Кинәт алар өчесе дә озынборын-черкиләрне дә, эссе кояшны да оныттылар. Күптән түгел генә яңгыр суы аккан ерганак төбендә гранит бертекләре арасындагы кара нокталарга игътибар иттеләр алар. Асия Дәминова бу бертекләрне учлап алды да ак кәгазь өстенә салды. Лупа аша күзәтергә кереште.

— Озынча кристалл, — дип күргәннәрен әйтте ул. Асия лупасын чыгарганда, коллектор сумкасыннан кыр дәфтәрен һәм карандашын алган иде инде. Дәминованың сүзләрен ул ашыгып язарга керешге. — Кристаллның һәр ике ягы дүрт почмаклы пирамида сыман булып бетә. Төсе — соры... Бирегез әле пыяла! — Ул пыяла өстеннән кристаллны йөртеп алды. — Пыялада эз калдыра. Бу кургаш ташы — касситерит!..

Тагын нәрсәләр әйтмәкче иде Асия, кинәт таныш булмаган ирләр тавышы ишетеп, тукталып калды.

— Кулларыгызны күтәрегез!

Барысы да тавыш килгән якка борылып карадылар. Яннарында фуражкаларына кызыл йолдыз кадаган егетләрне күргәч, Асия тәзләнгән килеш, ике кулын да югары күтәрде. Бер кулында лупа тырпаеп тора, икенче кулында кәгазьгә төрелгән минерал иде аның. Коллекторлар да кулларын күтәрделәр.

— Коралларыгызны куегыз! — дип кычкырды фуражкалыларның берсе.

Коллектор көндәлек белән карандашын, Асия лупасы белән минералны сумкаларына тыгарга теләделәр. Ләкин шул вакыт икенчесе:

— Отставить, — дип боерды.

«Сумкада граната-мазар булыр дип шикләнде инде ул», — дип уйлап алды Асия.

Аларга кибәргә эленгән киемнәрен дә алырга ирек бирмәделәр. Аяк өстенә торырга куштылар, сөйләшмәскә боердылар, аркаларына винтовкалар төбәп кояш батышы ягына алып киттеләр.

«Бик әйбәт булды әле бу, — дип уйлады Асия. — Мәскәүдә үк чик сакчылары белән бәйләнешкә керергә кушканнар иде. Үзләре безне табып яхшы иттеләр».

Заставага шактый озак барырга туры килде. Дәминованың уеннан һаман әлеге кургаш ташы китмәде.

Аккургашны күпләп табу-чыгаруга безнең гасыр башында гына керешәләр. Моның белән аеруча Англия компанияләре файда күрәләр. «Лондон тин корпорейшн», «Патиньи майнс энд энтерпрайзис» компанияләре Малайя, Нигерия, Таиланд, Боливия һ. б. илләрдәге рудникларны биләп, егерменче елларда деньяга чыгарыла торган аккургашның 70 процентын үз кулларына туплыйлар.

Барлык капиталистик илләрдә дә промышленность киң колач алган вакытта аккургашның башлыча бер Англия кулы астында булуы нәтиҗәсендә инглиз промышленниклары кесәләрен бик нык калынайталар. Мәсәлән, Америка Кушма Штатлары бу вакытта деньяда чыгарыла торган аккургаш рудасының яртысын промышленностьта

файдаланалар. Ә үзләрендә бер генә дә рудник булмый. Англиядән сатып алырга мәҗбүр булалар.

Ә безгә, Советлар Союзына, илебезнең киләчәген тәэмин итү өчен һәр тиенне бик кысып тоткан бер чорда, алтын түләп чит илләрдән аккургаш сатып алыргамы? Империалистлар тирәнне терелатә тунарга әзерләр. Бездә дә бит аккургаш аз түгел. Барысын бергә кушсаң, запасы аның күп. Ләкин чыганаклар илнең төрле почмакларында. Ә аккургаш хәзер кирәк. Руда тирән дә ятмасын, аның металл проценты да күп булсын, промышленность үзәкләреннән, тимер юл, су магистральләреннән дә ерак булмасын!

Геолог әнә шундый шартлардан да чыгып эш итәргә тиеш. Ә Асия Дәминова, инде тәҗрибәле геолог, хәтта бүген-иртәгә галим, фәннәр кандидаты буласы кеше, болар турында уйламый булдыра аламы соң?.. Әйе, бу тирәләрдә аккургаш бар, ләкин аның запасы күпме? Кандидатлык диссертациясендә, бу районның петрографиясен тикшерү белән бергә, ул әнә шуңарга да җавап бирергә тиеш...

...Застава начальнигы, зур зәңгәр күзле, ләкин куе кара кашлы, кара мыеклы капитан, геологларның документларын карап чыкканнан соң:

— Без сезне күптән көтәбез инде. Моңа кадәр кайда булдыгыз? — дип, бик кырыс кына сорау бирде.

Асия Дәминова аңа үзләре йөргән маршрутны картасы буенча күрсәтергә кереште. Капитан бу маршрутны стенадагы карта буенча тикшерде. Геологның беренче сүзләреннән соң ук аның кашлары җыерылды.

— Кем кушты сезгә ул участокка керергә,— дип кычкырды ул кинәт, Дәминова сүзен бүлеп. — Миналар тулып ята. Хәтта хәрби кешеләргә дә рөхсәт ителми анда йөрергә. Саперлар әле барып җитмәгән. Сезнең башбаштаклыгыгыз өчен мин җавап бирергә тиешме? Менә хәзергә сезгә тикшерергә тиешле район! — һәм ул кызыл сызык белән бүленеп алынган зур бер районның тирә-ягын картадан күрсәтте.

— Гафу итегез, сез ярамый дигән районны без йөреп чыктык инде. Анда да, монда да материаллар бик кызыклы, — диде Дәминова...

* * *

Казан. Җәй көне аның матурлыгы җитәрлек: Маркиз утравы бар, Швейцария бакчасы — паркы бар, Кабан күле бар. Зәңгәр күл, Аккош күле якларына чыксаң, әллә кайдагы Кара диңгез буйларың бер якта торсын. Ә кыш көне нәрсәсе бар? Шәһәр читендәге урамнар турында әйтәсе дә юк инде, шәһәр уртасында да машиналар чак-чак йөрерлек. Яуган карны көрәп тә, ташып та бетерерлек түгел. Әмма студент елларын монда үткәргән кеше өчен бик кадерле бу шәһәр. Университеты инде аның бик таныш, бүтән уку йортларының да һәрберсендә диярлек булынган. Татар шагыйрьләре, язучылары сөйләгәннәрне дә тыңламаган түгел, ләкин кабат-кабат шул шәһәрдә буласы, шул шәһәрнең урамнарыннан йөрисе килә. Юк, әнисе, абыйсы бу шәһәрдә торганга, әтисе бу шәһәрдән 60—70 чакрымдагы Әрә авылы кешесе булганга гына түгелдер инде ул, мөгаен, студент булып килүнең беренче еллары, кыскасы, ваемсыз яшь вакытлар бирегә тарта торгандыр.

Канәгать бу кышкы каникулдан Асия. Ул Мәскәүгә соңарыбрак кайтты, ләкин яңа дәрт, яңа омтылышлар белән кайтты. Аның инде диссертация материаллары туплаңган, кайбер анализларны кабат карап чыгып, классификациялисе калган иде.

Соңга калып кайтуы өчен академиктан бик нык шелтә алды ул. Сәбәбе шул: икенче семестрда аны икенче укытучы итеп группага беркеткәннәр икән. Ә ул беренче лекцияләргә кайтып өлгермәгән. Хәер, Владимир Иванович никадәр кырыс, никадәр җитди булып күренергә тырышмасын, аның аталарча кайгыртучан, йомшак күңелле «картлач» икәнен барыбер белә инде Асия. Педагог буларак та үзенең сынатмаячагын белә ул. Ләкин беренче лекциядә үк аның педагогик язмышы «кыл өстендә» калды.

Үзсүзлеге, бик тиз бәхәскә кереп китәргә яратуы сәбәп булды моңа. Бәхәскә кереп киттеме инде, бөтен дөньясын оныта. Лекциянең беренче сәгатеннән чыгып, кафедра бүлмәсенә килеп кергән иде, аспирантлар, дәрестән буш укытучылар белән петрографиянең аерым мәсьәләләренә карата бәхәскә кушылып китте. Төрле авторитетларны ярдәмгә дә чакырып тормастан, дәртләнеп үз фикерләрен исбатларга керәште. Бер-

заман, һушына килеп, стенадагы сәгатькә күз төшерсә, ун минутлык тәнәфес урынына егерме биш минут узган...

Йөгереп, сулуы кабып, аудиториягә барып керде. Ни күрсен: лекцияне академик Владимир Иванович Лучницкий үзе дәвам итә... Бу «җилбәзәк татар кызы»ның лекцияне ничек үткәрүен карап утырырга дип килгән булган икән ул. Утыз ел буена ничәмә-ничә галим тәрбияләп чыгарган академикның мондый тәртипсезлекне беренче мәртәбә күрүе иде.

Һәм аспирант Асия Дәминованың «үз эшенә салкын каравы» кафедра утырышында тикшерелде...

* * *

Бөек Ватан сугышы. Диссертацияне әзер дип әйтергә яраса да, мондый вакытта аның кайгысымыни! Илгә бәреп кергән дошманны җиңү өчен җир куенында моңа кадәр дөнья күрми яткан казылма байлыкларны тизрәк табарга, аларны бердәм максатка юнәлдерергә кирәк. Ил өчен хәзерге моментта геологның укытуыннан да, хәтта кулга корал тотып турыдан-туры дошманга каршы чыгуыннан да бу эш әһәмиятлерәк.

— Әйе, Асия, үз язмышына геолог һәрвакыт ил язмышы күзлегеннән карарга тиеш, — ди Владимир Иванович, аспирантының фикерләрен тыңлагач. — Безнең урын — алгы сызыкта.

Шулай итеп, Асия Дәминова, сугыш башлануга бер атна дигәндә, үзе теләп Урта Азиядәге Кургаш, цинк рудникларында практик эшкә керешә. Озакламый аны бөтен Союз күләмендә зур, әһәмиятле эшкә күчерәләр: 1943 елдан башлап Асия Дәминова, Главканың өлкән геологы сыйфатында, халык хуҗалыгы өчен гаять әһәмиятле булган эшләр: төсле металларны эзләү, рудниклар эшкәртү һ. б. лар белән җитәкчелек итә...

Сугыш аның галим булырга омтылышын гамәлгә ашыруны биш елга кичектерде. Алай гына да түгел, абыйсы Хәмзә белән энесе Мансур җиңү көнен күрә алмадылар...

Ниһаять, 1946 елның гыйнварында аның «Карело-Фин ССРның Питкярант районы петрографиясе» дигән хезмәте бертавыштан геология-минералогия фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә өчен лаеклы дип табылды.

Менә ул Мәскәүдәге төсле металлар һәм алтын институтының өлкән фәнни сотрудникгы. Институт үзе дә, аның минералогия һәм петрография кафедрасы да сугыштан соң яңа гына оешып килә. Кафедраны оештыру, кадрлар туплау, җиһазландыру — гомуман аның барлык эше Асия Дәминова өстендә. Ул тиздән — кафедра мөдире, доцент. Педагогик, җитәкчелек эше белән бергә, аның фәнни эшчәнлеге Союзның барлык почмакларын диярлек билэп алган: Урта Азиядәге, Карелиядәге, Закарпатьедагы, Енисей елгасы буйлап сузылган таулар тезмәсендәге файдалы казылма чыганакларын картага төшерү, аларны өйрәнү Асия Дәминова җитәкчелегендә башкарылган эшләр.

Таймыр ярым утравын геологик үзләштерү буенча тикшеренүләре Асия Дәминованың гыйльми эшчәнлегендә генә түгел, бөтен совет петрография фәнендә зур урын билэп торалар.

* * *

1952 ел.

Асия Дәминова инде бишенче җәен Таймыр ярым утравында уздыра. Биредә ул Үзәк Таймырдагы магматизм үзенчәлекләрен өйрәнә, ярым утрауның геологик картасын төзи, ә көзен институтка кайта һәм, «Кристалоптика», «Токымнарны барлыкка китерә торган минераллар», «Магматик һәм метоморфик тау токымнары» курслары буенча лекцияләр укы, аспирантларның, студентларның фәнни эшләренә җитәкчелек итү һ. б. бик күп эшләр белән бергә, җәен тупланган материалларны тәртипкә китерә, классификацияли.



Таймырда.

Мена быел да ул Таймырга ашкынып, башта кайнаган мең төрле фикерләрен раслау өчен материаллар табарга өметләнеп, инде юнәлешләре билгеләнгән, хәл ителеп килә торган проблемаларга өстәмә җаваплар эзләп килде.

Нәрсә ул Таймыр?

Поляр түгәрәктән дә төньякка табарак шактый еракка урнашкан ярым утрау ул. Таймыр — арктик сахара иле. Аңа бары тик XVIII гасырда гына Европа кешесе аягы баса.

Петр патша, Россия бөек диңгез державасы булып әверелгәч, Мурманскидан, Төньяк Боз океаны буйлап, Тын океанга кадәр сәяхәт оештырырга уйлый. Максаты: Азия Америка белән тоташканмы икән — шуны белү. 1733 елдан 1743 елга кадәр дәвам иткән Бөек Төньяк экспедициясе бу якларны өйрәнүнең башлангычы була. Бу экспедициянең штурманы Семен Челюскин 1742 елның 7 маенда Таймыр утравының төньяк-көнчыгыш ярына аяк баса. Бу урын хәзер Челюскин борыны дип атала. Азия материгының иң төньяктагы ноктасы ул. Аннан Төньяк Котыпка бары 12 градус кала.

Кыргый тундра, тау тезмәләре. Тау тезмәләре аша упкыннар төбеннән елгалар ага. Тундрада тигезлек урыннарда күлләр күп. Таймырны кисеп ага торган бик күп елгалар арасында иң зурысы — озынлыгы мең километрдан артык сузылган Пясина елгасы.

Таймырның табигате гаять кырыс. Үзенең каты салкыннары, кара бураннары, поляр төне белән кыш бик озак дәвам итә анда. Ә яз җиткәч инде, кояш, кышын күренмәгәнгә оялгандай, айлар буе күктән төшми. Тундра өстендә исәпсез-хисапсыз күлләр, күлләвекләр күзгедәй ялтырап ята, чөнки кар суы беркая да китә алмый, мәңгелек туң җир аны үзенә кабул итми.

Агачлар да үсә биредә. Ләкин нинди агачлар!.. Алтмыш-җитмеш яшьлек каен агачы синең беләгеңнән генә. Туң җир тамырларны тирән җәяргә ирек бирми, каты җилләр ботакларны җиргә сыга. Шуңа күрә йөз яшьлек агачлар да җиргә сыенып үсәләр.

Таймырның төньяк тундраларында исә үлән һәм мүк та үсә алмый, анда, күз күреме дәвамында, эреле-ваклы ташлар түшәлгән очсыз-кырыйсыз бушлык сузыла...

Шулай да кешеләр яши анда. Болан асрыйлар, сунарчылык белән шөгыльләнәләр, балык тоталар. Ә көньяктарак, Норильск тирәсендә (көньяк төшенчәсе биредә чагыштырмача, чөнки Норильск — дөньяда иң төньякка урнашкан шәһәр), күмер чыгаралар, металл коялар...

...Аларның лагере Мамонт елгасының сул ягына урнашкан. Лагерьдан төньяктарак күк йөзендәге йолдызлар торышын хатерләткәнгәдер инде, Астрономик дип исемләнгән күлләр тәркемә җәелеп ята.

Тира-яктагы җир өсте ямь-яшел мүк белән капланган. Мүк карлыганы пешкән чак, алар әнҗе кебек ялтырап күренәләр. Мамыкбаш үләннәре чачакта утыра. Түбәнлекләр, аксыл томан җәелгәндәй булып, болан мүге үләне белән капланган. Әйе, кырыс кыштан соң, кыска поляр җәендә барлык нәрсә яшәп калырга ашыга.

Әйтерең дә юк, лагерьның урыны тундра өчен бик матур җирдә.

Әминова бүген үзенең ярдәмчеләренә ял бирде. Шуннан файдаланып, аспирант Борис Тихомиров күлгә балык тотарга китте.

Табәнәк буйлы булса да, нык гәүдәле, җитез хәрәкәтле егет ул Борис. Бирегә килгән саен (Борис инде өченче экспедициягә катнаша), ул Мәскәүгә «Шмидт бабай булып», сакал үстереп кайта. Шулхәтле иүнегеп бетәсең сакаллы Бориска, институтка кайтып, сакалын кыргач, бөтенләй үзгәреп китә, башта танымый торасың. Балык дигәндә инде, бөтен нәрсәсен оныта. Азрак буш вакыт булса, кармакларын күтәрә дә, балык каптырырга чаба. «Туйдырды инде консерв ашы», — ди.

Ә ярдәмчеләренең икенчесе Идрис Мозаффаров — үзенең озын буеннан оялгандай, бөкрәебрәк йөри торган, салмак хәрәкәтле, аз сүзле, оялчан, шул ук вакытта беркатлы һәм уйчан егет. Еш кына бер читкә китә дә, кешегә күрсәтми генә, блокнотынаниләрдер сызгалый. Шигырь яза торгандыр. Алар яшендә кем генә шигырь язмаган...

Әнә хәзер дә ул палаткалардан бер читтә, карлә каен куаклыгы янына утырган да, тезенә блокнотын куйган килеш, бер ноктага текәлеп уйга баткан...

* * *

Тырышсаң була икән...

Идриснең күңеле балачактан ук ерак җирләр күрергә омтыла иде. Ә омтылышны тормышка ашыру бик җиңел булып чыкмады. Урта мәктәпне тәмамлады, өлгергәнлек аттестаты алды, укырга китәргә, паспорт алырга рөхсәт сорап колхоз идарәсенә баргач иде, председатель кырт кисте:

— Колхозда да сиңа эш җитәрлек, — диде. — Бетенесе укымаччы...

Идрис председательнең болай тискәре җавап бирүен көтмәгән иде. Дөрес, урта мәктәпне бик ук яхшыга бетермәде ул, «3» ләре дә бар. Ләкин җиңел булмады аңа урта мәктәпне бетерү. Әтисе юк, 1943 елда Орел шәһәреннән үлгән хәбәре килде. Бер сеңелесе, ике апасы, әнисе белән — семьяда бер ир кеше — ул калды. Әнисе аны ничек кенә булмасын, укытырга тырышты. Ә тырышлык Идриснең үзендә дә җитәрлек иде. Иртән тора да сыер абзарын чистарта, кичен мәктәптән кайта да утын кисә, терлекләргә азык сала. Ә дәресләрен мич башында әзерли—анда тыныч. Шешәгә керосин салып үзе ясаган «тычкан күзе» бик ук әйбәт яктыртмаса да, ул шуңа да канәгать иде. Җитмәсә, көн саен биш километрдагы район үзәгенә йөреп укыды. Җәяүләп.

Әнисе дә, ике апасы да фермада эшли. Нигә каршы килә икән инде ул председатель.

Әнисенә идарәгә кабат барырга рөхсәт итмәде, туу турында таныклыгын, аттестатын кагазьгә төреп кесәсенә тыкты, капчыкка ике бөтен икмәк, бер банка сары май салып, аркасына асты да җәяүләп Уруссу станциясенә юлга чыкты.

Уфа — Мәскәү поездына билетсыз утырды. Шулай да барып җитте Мәскәүгә.

Әтисе ягыннан чыбык очы туган тиешле абыйсы Мәскәүдә тора иде, аны эзләп тапты.

Аның теләге геолог булу иде. Университетның кабул итү кабинетында аңардан паспорт сорадылар. Димәк, паспорттан башка чыннан да мөмкин түгел икән. Инде ни эшләргә?

Коридор стенасына сөялгән килеш, шулай уйланып озак басып торды ул. Битләреннән тәгәрәп мөлдер-мөлдер яшьләр акканын да сизмәде. Ә моны коридордан узып торган кешеләр күргәннәр икән.

— Нигә борыныңны салындырдың, егет — дигән хатын-кыз тавышына Идрис сискәнеп китте.

Аның каршында очлы борынлы, сары чәчле, нечкә иренле бер хатын басып тора иде. Үзе бик гади киенгән, бер дә Мәскәүдә яшәүче димәссең. Күзлек астыннан соргылт күзләре дә бик игътибарлы карый, йөзе дә бик мөлаем күренә. Мөгаен, шуңаргадыр инде, бер дә оялып-нитеп тормастан, Идрис эчендә ни бар — барысын да ачып салды. Аттестатын, туу турында таныклыкны караганнан соң:

— Геолог буласың килә инде синең алайса, — диде әлеге хатын, чеп-чи татарча итеп.

Идриснең күзләре шарланды, ул монда, Мәскәү университетында, татар кешеләрен очрату турында башына да китермәгән иде.

— Ие, ие, апа. Бары тик геолог булырга гына исәп, —дип тиз-тиз сөйләргә керешге ул. — Безнең якларда бит нефть...

Ләкин апа аның сүзен бүлде.

— Әйдә киттек, барысы да рәтләнер...

Шулай итеп, бу апасы Идрискә Мәскәү паспорты алырга да, тулай торакка урнашырга да, институтка керергә дә булышты.

Хәтта институтның ике курсын тәмамлагач, моңа кадәр Советлар Союзының геологик картасында ак тап булып кала биргән Таймыр ярым утравының үзәк өлешен үзләштерү, өйрәнү экспедициясенә дә кертте ул аны.

Бу экспедиция материаллары нигезендә ясалган доклады өчен институт күләмендә үткәрелгән фәнни конференциядә Идрис диплом белән бүләкләнде.

...Менә инде ул икенче экспедициядә. Хәзер Идриснең дә максаты ачык инде: ул гади геолог-инженер булып кына калмаячак, чын-чынлап Асия апа Дәминованың шәкерте — петрография буенча галим булачак. Диссертация темасы да аның инде билгеле. Тик шунысы бар: институтны бетергәч, Асия апа аны бер-ике елга иң ерак почмакка практик эшкә «куачак». «Шунсыз геология галиме булу мөмкин түгел», ди ул. Әйдә, шулай булсын! Ул барыбер үзенекен итәчәк...

Әйе, Таймырда кеше аягы басмаган урыннар күп. Бигрәк тә аның үзәк өлешендә. Аның чикләре: төньяктан — Карски диңгезе, көнбатыштан — Пясина елгасы, көнчыгыштан — Таймыр елгасы, көньяктан — Пясино-Хатанга тигезлеге. Гаять зур мәйданны били ул — 125 мең квадрат километр. Бу мәйдан Татарстан республикасы территориясеннән ике мәртәбәгә якын зуррак.

Үзәк Таймырның геологик төзелеше бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Хәтта Днепр хәтле диярлек булган Пясина елгасын да соңгы ун-егерме елга кадәр картага төрле кеше төрлечә төшергән.

Идрис боларның барысын да белә. Шулай ук ул Төньяк диңгез юлының Баш идарәсе каршындагы Бөтенсоюз «Арктикразведка» трестының эш нәтиҗәләре белән дә таныш. Алар чыгарган нәтиҗә буенча, Таймырда магматизм проблемаларын өйрәнү беренче чиратта тора.

Бу дөрес тә. Мондагы тау токымнарына геологик, петрографик һәм петрогрохимик характеристика бирүне юкка гына максат итеп куймаган аларның җитәкчесе. Алай гына да түгел, алар бу токымнарның барлыкка килү шартларын да, магматик катламнарның яшен дә, бу җирдә барлыкка килгән руда ятмаларының үзенчәлекләрен дә өйрәнергә тиешләр. Ә моның өчен нәрсә кирәк? Моның өчен факт кирәк, бик күп фактлар кирәк. Атаклы француз натуралисты Бюффон унтугызынчы гасыр урталарында ук: «Фактлар туплагыз, алардан фикер туар», — дип юкка гына әйтмәгән. Бу сүзләр геологлар өчен матур фраза гына түгел, лозунг.

...Бүгенге кичке аш озакка сузылды. Борис тотып кайткан балыктан шулпа пешерделәр, калганын кыздырдылар да. Бик тәмен белеп ашадылар.

Аш вакытында сүз күбрәк петрография фәненең әһәмияте турында барды. Әлбәттә, Идрис бу фәнне яхшы белә. Бу фән буенча аның зачет кенәгәсендә «отлично» билгесе. Шулай ук ул экспедициянең максаты белән дә һәрьяклап таныш. Аларның беренче бурычы — Таймырның үзәк өлешендәге магматик тау токымнарын тикшерү, өйрәнү.

Миллион еллар элек биредә мәхшәр булган. 30—40 километр җир астыннан зур басым астында ут сыман матдә — магма бәреп чыккан. Аның составындагы төрле

газлар, су парлары очып беткән. Ә суынган, каты таш халена килгән җир асты матдәләре гасырлар, мең еллар дәвамында, һава һәм үзендәге төрле элементлар белән химик реакциягә кереп, минералларга әверелгән. Шуңа күрә мондый төр тау токымнарын магматик тау токымнары дип йөртәләр дә. Магматик тау токымнары җир шарының геологик үткәнен чагылдыра торган көзге генә түгел, кыйммәтле казылма байлыкларына юл күрсәтә торган маяк та.

Юкка гына Асия Мисбахетдиновна петрографиянең бу тармагын үзенең фәнни эше өчен максат итеп алмаган.

Бүген дә сүз нәкъ шул турыда барды. Сүз артыннан сүз чыгып, Якутия алмазы да телгә алынды. Телгә алынып кына калмады, Асия Мисбахетдиновна үзенең таныш геологы Александр Петрович Буровның бу «ару-талуны белми торган таш» чыганагын ничек итеп эзләп табуын да сөйләп бирде.

Ташлар арасында иң кыйммәтлесе — салават күперендәге барлык төсләрне үзеннән нур итеп чәчә торган, табигатьтәге иң каты матдә — алмаз. Ул бернинди сыеклыкта да эреми, утта янмый. Гади углеродтан гыйбарәт булган бу кыйммәтле таш — шулай ук магматик тау токымы. Морҗадагы корымнан яки без яза торган карандаш эчендәге графиттан ул бары тик атомнарының бүтәнчә төзелеше белән генә аерылып тора. Шул ук графит ул, билгеле бер басым астында, аерым бер температурада магма составындагы углеродның атомнары үзгәргән дә шундый каты, кыйммәтле ташка — алмазга әверелгән.

...1867 елда Көньяк Африкада, Кемберли дигән шәһәрдән ерак түгел урында, алмаз чыганагы табыла. Моны ишетү белән, матрослар корабльләрен ташлап качалар, солдатлар хәрби эштән ваз кичәләр. Полицейскийлар коралларын ташлап, тоткыннарны язмыш иркенә калдыралар. Сәүдәгәрләр кибетләрен, фермерлар үзләренең җирләрен, терлекләрен оныталар. Барысы да алмаз эзләргә ашыгалар...

Капиталистлар, үзара берләшеп, бөтен дөнья алмаз синдикаты оештыралар. Синдикат кемгә, кайсы дәүләткә күпме алмаз сатасын, аның бәясен билгели. Синдикатта эшләүчеләр аерым режимда: аларны һәр көнне берничә тапкыр тентеп торалар. Яши торган урыннары да чәнечкеле тимер чыбык эчендә.

Алмаз чыганакларын эзләү, разведка ысуллары, алмаз барлыгын күрсәтә торган үзенчәлекләр турындагы кәгазьләр метр калынлыгындагы бетон стеналар, корыч сейфлар эчендә саклана.

Ләкин Көньяк Африканың геологик төзелеш картасы беркем өчен дә сер түгел. Ленинградның яшь галиме Владимир Степанович Соболев Советлар Союзы территориясендә шуңа охшаш урынны эзләргә керешә.

Миллионнарча еллар элек, геологик үзгәрешләр нәтиҗәсендә, җир астындагы авыр токымнар җир өстенә бәреп чыга. Җир астында тупланган газлар бик каты шартлап өскә ыргылалар. Шушы шартлау вакытында алмазлы тау токымнары (кимберлит) да җир өстенә ыргытыла.

Тирәндәге авыр токымнар җир өстенә бәреп чыккан урыннар Советлар Союзында да табыла. Мондый урын — Якутия территориясе икән. Ә геолог А. П. Буров ныклы логикага нигезләнгән теориянең дәреслеген иң беренче башлап практикада исбатлый.

Тау токымнарының төзелеше, барлыкка килү тарихы өйрәнелмәсә, ул урыннар геологик картага төшерелмәгән булса, әлбәттә, бу ачыш мөмкин булмас иде.

— Әйе,— дип куйды Борис, үз-үзенә сөйләнгәндәй,— Петрография — геологиянең тактикасы да, стратегиясе дә.

— Синең сүзеңдә хаклык юк түгел, — диде аңа каршы Даминова. — Ләкин алай дип фәннәрнең һәрберсенә карата әйтергә була. Табигать, шулай ук җир катламнары — гигант бер лаборатория. Андагы барлык процесслар очраклы рәвештә түгел, нинди дә булса законга буйсынган хәлдә бара. Безнең бурыч шул законнарны, ягъни геологиянең бер үк вакытта стратегиясен дә, тактикасын да өйрәнү...

Аннары Асия Мисбахетдиновна төньякка күз төшерде. Зур кызыл шар — кояш офыкка терәлеп туктап калгандай күренә иде.

— Сүз күпкә китте. Марш палаткаларга, — диде ул, бүгенге эшләргә чик куеп, — инде арты төн җиткән...

— Әйе, геология кызыклы фән, — дип уйлады Идрис, йокы капчыгына кереп уңайлап яткач. — Бөтен фәннәргә фән...

* * *

Асия Дәминованың докторлык диссертациясе «Үзәк Таймырның магматик формацияләре» дип исемләнгән иде. Бу хезмәт өстендә Асия Дәминовага ун елдан артык эшләргә туры килде. 1947—53 елларда ул, һәр җәй саен Таймырга барып, турыдан-туры кыр эшләренә җитәкчелек итте. Ә 1954 елдан алып 1958 елга кадәр тупланган материалларны өйрәнү, алардан нәтиҗәләр ясау өстендә утырды.

Ниһаять, 1959 ел башында моңа кадәр тикшерелмәгән гаять зур районда — Таймыр ярым утравының үзәк өлешендә — магматизм үсеше закончалыклары сурәтләнгән бу хезмәте өчен Асия Дәминовага М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү университетының Гыйльми Советы геология-минералогия фәннәре докторы исемен бирде.

Асия Дәминова хезмәтенең теоретик һәм практик әһәмияте турында тулы фикерне, әлбәттә, бу өлкәдә эшләүче белгечләр генә әйтә ала. Ә бу диссертациягә карата белгечләрнең фикере күп булды. Советлар Союзындагы геология буенча учреждениеләрнең, күренекле белгечләр — галимнәрнең барысы да диярлек диссертациягә карата үзләренең отзывларын җибәрделәр.

«...Совет Арктикасының кырыс, үтеп керергә авыр бу районы 1945 елда әле асылда ак тап иде, — дип яза экономик ярдәмләшү Советы Секретариятының Геология буенча Советнигы А. Голов. — Геология-минералогия фәннәре кандидаты А. М. Дәминова бу районны геологик картага төшерү, эзләнү эшләренә, экспедиция материалларын эшкәртүгә үзе турыдан-туры катнашты. А. М. Дәминованы мин, «Арктикразведка» трестының начальнигы (1947—50 е.е.), Тау-Геология идарәсе начальнигы, Төньяк диңгез юлы начальнигы урынбасары (1950—53 е.е.) буларак, яхшы беләм сәбәпле, кырдагы һәм лабораториядәге эшләрен зур җитдилек һәм намус белән башкаруын, геологик күренешләргә чын фәнни һәм объектив бәя бирүен, алынган фактларны системалаштыра, анализлый белүен, тыйнаклыгын һәм шул ук вакытта үз карашын туптуры әйтеп бирә алуын, үз-үзенә таләпчәнлеген һәм бергә эшләүче иптәшләренә карата гаять игътибарлы булуын билгеләп үтәргә тиешмен».

Отзывлар күп. Алар йөздән артык. Аларның һәммәсендә диярлек илебезнең зур дәрәҗәле геология белгечләре — галимнәр безнең якташыбыз, бик гади һәм кешелекле, шул ук вакытта җитди һәм аналарча кайгыртучан Асия Дәминованың фәнни эшчәнлегенә, шәхси батырлыгына, ул иҗат иткән хезмәтләрнең әһәмиятенә соклану белдерәләр.

СССР геология һәм җир асты байлыкларын саклау Министрлыгының коллегия члены, СССР Фәннәр Академиясе член-корреспонденты А. Амирасланов болай дип яза:

«...А. М. Дәминова диссертациясе югары фәнни дәрәҗәдә башкарылган, анда Үзәк Таймыр геологиясен аңлау өчен кирәк булган мәсьәләләр комплексы җентекләп тикшерелгән һәм ул иң югары бәягә лаек.

А. М. Дәминова хезмәтен СССР геология һәм җир асты байлыкларын саклау Министрлыгы оешмалары, практик максатлардан чыгып, киләчәктә Үзәк Таймыр районында казылма байлыкларны эзләү, геология-разведка эшләрендә эффектив юнәлешне билгеләү буенча киң файдаланачак».

Әйе, фән әһелләренең, практик геологларның Асия Дәминованың үзенә дә, аның хезмәтләренә дә карашлары яхшы, хөрмәтләре зур. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Ул, беренчедән, үзе практик геолог, икенчедән, фәнгә өлеш керткән һәм халык хуҗалыгына файда китергән башка фәнни хезмәтләре дә күп. Ул — дөнья күргән, басылып чыккан иллегә якын фәнни хезмәтнең авторы. Шул ук вакытта Асия Дәминова тәҗрибәле, игътибарлы педагог та. Аның «Высшая школа» нәшрияты басып чыгарган «Токым барлыкка китерә торган минераллар», «Микроскоп белән токым барлыкка китерә торган минералларны, структураларны һәм магматик тау токымнарын билгеләү таблицалары», «Недра» нәшриятында чыккан «Магматик формацияләрнең төп типлары» һәм башка дәреслекләр буенча меңнәрчә студентлар белем алалар. Аның шәкерт-

ләре — йөзләрчә геологоразведчиклар — илебезнең төрле почмакларында, моңа кадәр кеше аягы басмаган сукмаклар буйлап, файдалы казылмалар эзлиләр. Хәзер, аның шәкертләре бер безнең илебездә генә түгел...

1961 елда профессор Асия Даминованы Патрис Лумумба исемендәге халыклар дуслыгы университетына чакырып алалар һәм аңа инженерлык факультеты каршында минералогия, петрография һәм кристаллография кафедрасын оештырырга, бу кафедраның мөдире булырга тәкъдим итәләр. Бирадә дә ул гаҗәеп эш сөючәнлеге, гыйльми омтылышларының киңлеге, гүзәл рухи һәм кешелек сыйфатлары белән тиз арада барлык студентларның да, педагогларның да ихтирамын казанып өлгерә.

Бу университет быел инде үзенең өченче чыгарылышын ясады. Асия Даминова тәрбияләп чыгарган уннарча чит ил белгечләре хәзер Африка, Латин Америкасы, Азия илләрендә үз халыкларының экономик бәйсезлекләре өчен көрәшәләр.

Ә профессор Даминова үзенең фәнни эшчәнлеген дә, педагогик, оештыру-иҗтимагый эшчәнлеген дә дәвам итә. Ул Лондонда һәм Делида үткәрелгән халыкара минералогия конгресслары, шулай ук Бөтенсоюз петрография киңәшмәләре делегаты. Алардан тыш КПССның Мәскәү шәһәре Октябрь районы комитеты каршындагы фән эшләре советын, университетта тау, геология эшләре буенча методология комиссиясен, студентларның фәнни җәмгыятен җитәкләп, зур иҗтимагый эшләр алып бара.

Әйе, аның вакыты гаять тыгыз. Шулай да ул театр-киноларга йөрергә дә, культура, әдәбият яңалыклары белән танышып барырга да вакыт таба. Татар язучыларының, шагыйрьләренең әсәрләрен даими укып бара. Ә ял көннәрендә Мәскәү тирәләренең кышкы табигате кочагында чаңгыда йөрергә ярата.

Бу көннәрдә якташыбыз, татар хатын-кызларыннан беренче геология докторы, күренекле профессор Асия Даминова я Кавказда, яисә Урта Азиядә, я булмаса Себер киңлекләрендә үзенең студентлары белән практикададыр, күпмилләтле шәкертләренә җир асты хәзинәләрен табу серләрен өйрәтә торгандыр. Ләкин кайда гына булмасын, аның омтылышы бер — туктаусыз эзләнү, хәрәкәт...

*Мәскәү — Казан.*

Шамил Рәкыйпов

# УПКЫННАР КОЧАГЫНДА

Кузган җәйдә мин Киев тирәсендәге ял йортларының берсендә булдым. Коеныйм дисәң, суы, кызыныйм дисәң, комы — менә дигән. Шуның өстенә һавага хуш ис тарата торган нарат урманы да янәшә генә. Урын шәп, теләгән чакта шәһәргә бер сәгатьтә кайтып килергә мөмкин булганга, ял йортына, күбесенчә, язучылар, артистлар, композиторлар җыела икән. Аларның да нинди әле — утны-суны кичкән өлкән буын вәкилләре. Бу төр халыкның кызык бер үзенчәлеге бар: сөйләшергә яраталар. Кояш әле урман артыннан елтыр маңгаен күрсәтә генә башлаган — алар инде күптән аяк өстендә, азрак бөкрәеп, тамак кыра-кыра һава иснәп йөриләр. Көндез, эссе какмагае дип, ышык урынга — күләгәгә утырып гәп куерталар. Кич җитеп, караңгы күк йөзендә чекерәеп йолдызлар кабынгач та тиз генә йокламыйлар әле. Чәчәк түтәлләре янындагы урындыкларга кырын ятып үткәннәрне искә төшерәләр, кайдан килүең, кем булуың белән кызыксыналар, таныш-белешләрең сорашалар.

Миңа да күңелсезләнергә туры килмәде. Башына зәңгәр берет, өстенә яшькелт киндер тукымадан тегелгән җиңел костюм кигән, ябык, озын гәүдәле, карлыккан тавышлы мөлаем агай — скульптор Кравченко беренче кичне үк үз янына чакырып алды һәм, украин сүзләрен куша-куша, киң күңеллелек күрсәтеп, урын тәкъдим итте.

Казаннан икәнемне белгәч, күпне күргән чал чәчле бу агай аеруча җанланып китте. Якынрак елышты, озын бармаклы кулларын берсе өстенә икенчесен куеп, нечкә камыш таягына таянды. Без халкыбызның горурлыгы Муса Җәлил турында озак сөйләштек. Бүгенге Казан да әңгәмәбез үзәгендә булды. Җир мае чыгару буенча Татарстанның беренчелекне үзендә тотуын, бу эштә безгә төрле милләт вәкилләренең нык булышуын ишеткәч, карт скульптор тирән уйга чумды. Күе кашларын сикерткәләде, тамак кырды. Мин сагаеп калдым. Хикмәт нәрсәдә? Күзләре азрак кысылып бер ноктага текәлгәннәр, иреннәре нәрсәдер пышылдый. Чыраенда тирән кичереш. Багана башыннан төшкән ут яктысында алга таба иелеп утырган гәүдә тәмам мескенәеп, бөрешеп калды шикелле. Нәрсә булды соң? Уйламыйча әйтелгән берәр сүзем белән рәнҗетмәдемдер ич мин аны? Юк кебек...

Бер-беребезгә тыныч йокы теләп аерылыштык. Ул, вак чуер таш сибелгән сукмактан кыштыр-кыштыр атлап, үз алдына нәрсәдер сөйләнә-сөйләнә китеп барды. Миңа моңсу булып китте. Тыныч йокы турында уйларга да мөмкин түгел иде хәзер. Мин, көндез ботагында җитез тиен сикергәләгән юан наратка сөяләп тордым-тордым да, чәчәкләр каршындагы озын урындыкка яңадан килеп утырдым. Моннан ял йортының төп корпусы ап-ачык күренеп тора. Ашханә, клуб, уку залы кебек нәрсәләр һәммәсе шунда урнашкан. Докторга күренергә, ваннасында юынырга, ашаргаэчәргә якын булсын диптер инде, карт скульптор шушы корпустагы бүлмәләрнең берсендә яши иде. Әнә ул, бөжраларын шалтыратып, тәрәзә пәрдәсен тартты, утны кабызды, аннары, язу өстәле тартмасын ачып, актарына башлады. Карт эзләгәнен

тапмады булса кирәк, тынычлана алмыйча әрле-бирле йөренде, утын да сүндермичә вестибюльгә чыгып, телефонга тотынды. Монда да тәрәзәләр ачык, челтәр пәрдәләр төшерелгән. Шуңа күрә эчтәге хәрәкәт күренеп, сөйләшкән тавыш ишетелеп тора.

Скульптор телефон станциясенә Киев белән сөйләшергә теләвен белдерде. Үз квартирасының номерын әйтте. Күп тә үтмәде, аны Киев белән тоташтырдылар. Скульптор ниндидер Марусяның сәламәтлеге белән кызыксынды, хәефен сорады. Үзе бик шәп ял итүе турында сөйләде. Кеше әңгәмәсен тыңлап тору килешмәсә дә, торып китәсем килмәде. Мине хәзер скульптор картның шәхси тормышы түгел, бүген кич ни өчен борчылуы кызыксындыра иде. Бәлки ул бу хакта нәрсә дә булса хатынына әйтер?

Колакларымны торгызып, һәммәсен тыңлап торырга чамалавымны сизгән кебек, алар украинча сөйләшә башладылар. Ә мин украинча белмим. Аңлаганым шул булды: ниндидер Зәйнетдин Әхмәтҗанов исенә төшкән икән, кайдадыр аның адресы язылган булырга тиеш, бик тиз табарга кирәк. Бу бик мөһим...

Мин тәмам аптырап үз бүлмәмә кайттым. Кем ул Зәйнетдин Әхмәтҗанов? Кинәт кенә нигә кирәге чыкты аның? Бүгенге сөйләшүләргә берәр төрле бәйләнеше бармы әллә бу кешенең?

Икенче көнне мин бирегә килгәннән бирле әзерләнеп йөргән сәяхәткә — Киевны азат итү өчен булган каты сугышларның башланып киткән җирләренә юнәлдем. Юллар асфальт, автобуслар шәп йөри. Ике сәгать эчендә йөз чакрымлап юл үттем. Тирә-якта куе урманнар, кукуруз, бодай басулары. Уртасында зур мәктәп, клуб, кибет кебек таш биналары булган җыйнак авыллар, хуторлар. Һәр җирдә яшеллек, матурлык. Әйтерсең, шушы матур җирләрне көйдереп, моннан сугыш афәте бөтенләй үтмәгән. Беләм, бу беренче карашка гына шулай. Сугыш яралары күңелләрдә җөй тартса да, җирдә эзләре бар әле аларның. Бар. Әнә авыл уртасындагы мәйданда кызыл йолдызлы туганнар каберлеге, кабер өстендә — чәчәкләр... Карадан киенгән чал чәчле ана кабер туфрагын тәзәтә... Юк, күңелләрдәге яралар да җөйләнеп бетмәгән әле, бетмәгән.

Бу — Юровка авылы икән. Пионерлар безне елга аръягындагы дотка алып киләләр. Егерме биш елдан артык вакыт үтүгә карамастан, дот стеналарындагы тәтен сөремен җил дә, яңгыр да бетерә алмаган. 205 номерлы бу бетон корылманы лейтенант Ветров җитәкчелегендәге сугышчылар саклаган. Дошман боҗрасында калгач та, уникe тәүлек буе көрәшкәннәр әле алар. Туктаусыз бомбага тотуга, атака ясауга түзеп, олы юлны саклаганнар. Камалыштагыларны үзләре белән алып китү һәм дотны шартлату өчен үтеп кергән 147 нче укчы дивизия сугышчыларына алар: «Дотны актык сулышыбызга чаклы саклыйбыз. Безгә сугыш кирәк-яраклары һәм азык-төлек кенә калдырыгыз», дигәннәр. 737 нче полк сугышчысы А. В. Соболев соңгы патронына чаклы дошманга аткан. Аның комсомол билеты эченнән шушы сүзләр язылган кәгазь кисәге табылган: «Дошман белеп торсын: Кызыл Армия сугышчылары әсирлеккә төшмиләр... Мин егермеләп фашистны дөмектердем инде һәм соңгы тамчы канына чаклы Ватан өчен көрәшәчәкмен. Миңа үләргә туры килә икән, герой булып, фашизмның тар-мар ителәчәгенә һәм җиңү безнең якта булачагына тирәнтен ышанып үләрмен».

Святошино районының Кременище авылы янында да йөрәк тетрәткеч дот каралып тора. Кече лейтенант комсомолец Якунин җитәкчелегендәге сугышчылар саклаган аны. Алар дошманның уннарча һөҗүмен кире кайтарганнар. Дот тирәсендә йөзләрчә мәет аунап яткан, автомашиналар, мотоцикллар сафтан чыгарылган. Бу көрәш дүрт көн буе дәвам иткән. Эчәргә су, ашарга ризык, кирәгенчә тотарга патрон калмаган. Ләкин сугышчылар бирешмәгәннәр. Фашист танклары дотка яндыргыч сыекча сиптергәннәр. Дот сумалалы кисәү таягы кебек дөрли-дөрли, тәтенли-тәтенли янган. Барыбер дот ишеге ачылмаган — унбер каһарман тәтен эчендә үлем кабул иткән... Кемнәр алар — төгәл генә белүче юк. Бәлки, бу батырлар арасында безнең якташлар да бардыр? Бәлки батырлыкларына таң калырлык шушы егетләр хәбәрсез югалучылар рәтендә йөридер? Каһарманлыклары җырларда җырланырлык пәһлеваннар каберләре монда авыл саен. Жулян станциясе районындагы колхоз бакчасына гына да 1941 елда Киевны саклап һәлак булган 800 билгесез сугышчы гәүдәсе күмелгән.

Казаровичи, Староселье авылларында фашистлар дистәләрчә кешеләрне утта яндырганнар, асканнар, терелəй җиргә күм-

гэннэр. Балык тота торган кеймэсен яшерүчене үлем жэзасы көткэн. Шуңа карамастан, илбасарлардан үзен азат итүне көтеп алган халык Кызыл Армия өчен кирэкле хэстэрне күрергэ тырышкан. Өч йөздэн артык көймэ безнең гаскэрлэргэ тапшырылган. Сваромье авылында, мэсэлэн, Галина Тригуб суга батырып куелган көймэлэрнең кайдалыгын аныклагач, безнең солдатларны утыртып, бер төн эчендэ ун тапкыр Днепрны кичкэн. Кызганычка каршы, аны авылда очрата алмадык — Киевка киткэн икэн.

Авыл кырыенда кайчандыр ак каеннар шаулаган. Хэзер аларның янган гарип кэүсэлэре генэ тырпаеп тора. Юк, яшен сукмаган, снарядлар, бомбалар чэрдэклэгэн аларны. Һэр жирдэ ишелгэн окоплар, траншеялар. Аз гына казыдың исэ каралып беткэн гильза, затвор яки автомат дискасы табасың...

Кичен арып-талып ял йортына кайткач, мине көндез скульптор Кравченконың эзлэвен эйттелэр. Сорашып та тормастан, дэү нарат төбендэге озынча урындык ягына юнэлдем.

Кравченко кичэге урынында иде.

— Менэ эшлэр болай, хлопчик, — диде ул, кул кысып күрешкэннэн соң, — Зэйнетдин Эхмэтжановның адресын табып булмады. Аны сиңа табарга туры килер. Кайткач.

— Кем соң ул Эхмэтжанов?

— Аны белмисеңмени? — Кравченконың күзлэрендэ гажэплэнү чагылды. — Үзегезнең татар герое Зэйнетдин Эхмэтжановны белмисеңме? Ай-яй-ай...

— Татар геройлары Союзның һэр өлкэсендэ бардыр, мөгаен. Алар турында бездэ тулы мэгълүмат тупланмаган. Татарстанда туып үскэннэрне генэ белэбез.

Карт скульпторның ачуы йөзенэ чыкты.

— Башка өлкэлэрдэ туып үскэннэрне белеп торсагыз, зыян булырмыни? Алар да татар халкының мактанычы ич! Мэгълүмат тупланмаган, имеш. Кем туплар аны?

Мин кызарып башымны түбэн идем. Бөркү булып китте. Тирэ-юньдэ «энем! энем!» дип үртэгэндэй черкилэр генэ безелдэп оча.

Ниһаять, карт тамак кырып куйды. «Ярар, — диде ул, — мин менэ бер вакыйга сөйлим. Шуннан үзең хэл кылырсың: геройларыгыз турында мэгълүмат тупларгамы, юкмы... Дустым сөйлэгэн иде моны. Ул сүз биргэн иде, аңлыйсыңмы? Киевны азат итэр алдыннан. Эгэр исэн калсам, килэчэк буыннар сокланырлык образыңны мэңгелэштерермен, дип Эхмэтжановка сүз биргэн иде. Ул үз сүзендэ торды. Соңгарак калып булса да вэгъдэсен үтэде... — Аның тавышы калтыранды, кабалана-кабалана тэмэкесен кабызды һэм, тирэн итеп суыргач, азрак тынычлана төшеп дэвам итте.

— Без минем элеге дустым Зэйнетдин Эхмэтжанов белэн бергэ хезмэт иттек. 11 нче гвардия танк корпусының 134 нче аерым сапер батальонында. Ул беренче Украина фронтына, беренче гвардия танклар армиясенэ кирэ иде. Комбатыбыз капитан Бирюков, э 11 нче гвардия танк корпусы командиры генерал-лейтенант Гетман иде.

1943 ел. Август башларында Совет Армиясенең Генеральный штабы частьлэргэ «Елгаларны кичү турында кулланма» жибэрде. Аны ныклап өйрэндек. Кул астындагы һэм жирле материалларны файдалана белергэ, елганы кичеп чыккач теге як ярда яулап алынган плацдармны саклап сугышуга аеруча игътибар иттек. Командирлар, политорганнар, партия һэм комсомол оешмалары сугышчылар арасында зур аңлату эшлэре алып бардылар. Һэркем дулкынланып сигнал көтте, үз бурычын булдыра алган кадэр яхшы иттереп үтэү дэрте белэн янды.

«Ватан-анабыз! — дип ант иттелэр совет сугышчылары, — Украинаның азатлыгы өчен барган сугышларда данлыклы Запорожье рыцарьлары, Богдан Хмельницкийның дэһшэтле халык гаскэре, курку белмэс Щорсның кыю полклары көрэшкэн чал Днепр ярларына басып, без сиңа улларың антын бирэбез; Советлар Украинасы өчен, азатлыгыбыз өчен булган каты көрэштэ чын ирлэрчэ нык торып сугышырбыз. Бэдбэхет гитлерчыларны жиңү өчен каныбызны да, жаныбызны да кызганмабыз!»

Гитлерчы башкисэрлэр, Курск янында танауларын жимергэннэн соң, сугышны сузып отарга план кордылар. Велиж-Дорогобуж — Брянск — Сумы — Төньяк Донец һэм Молочная елгалары арасында эзерлэнгэн оборона рубежлары Кызыл Армиянең һөжүмен туктатыр дип өметлэнделэр. Бер үк вакытта дошман Десна, Сож, Днепр ярларында да оборона эшлэрен киң жэелдерде. Немец командованиесе «Көнчыгыш вал» дип исемлэнгэн бу линиягэ аеруча зур өмет баглады. Алар исэплэгэнчэ, рус гас-

кәрләренең атакасы шунда бөтенләй тукталачак, оборона сугышларында хәлдән таячак һәм Гитлер үзенең тимер дивизияләрен яңа һөҗүмгә күтәрәчәк. Киң сулы, текә ярлы Днепрның теге ягы дошманга һичкем алалмаслык крепость булып тоелды.

Бер заман Днепрга килеп төртелдек. Фашистлар теге якка чыгып сызганнар. Безгә бернәрсә калдырмаганнар. Авыллар гына төтенләп ята. Каска белән чумырып Днепрның суын эчтек, битләрне юдык. Без, саперлар, сизенәбез: кичекмәстән эшкә керешергә кирәк. Әллә кая артта калган паром, понтоннарны көтеп ятып булмый бит.

Комбат чакырып алды. Кәефне сораша. Рус шәһәрләренең анасы булган Киевны азат итәргә җыенасызмы, ди. Ажгырып торабыз, ди дустым. Алайса, ди комбат, сезгә задание шул: төнге уникегә Днепрны кичә башлау өчен урта кул сал әзерләгез!

Нәрсәдән әзерләргә ул салны? Үз мөмкинлеген чамалый ич инде кеше. Андый эшкә бер дә сәләте юк моның. Аңа син җир казыт яки утын кистер — дөньяңны актарыр. Әмма инде юкны таптырма... Серне Әхмәтҗановка ачты бу. «Төнге уникегә» сүзен ишеткәч, Әхмәтҗанов та уйга калды. Аннары сикереп торып: «Киттек халыкка. Фашист барлык көймәләрне дә үзе белән алып китмәгәндер әле», — ди...

Ялгышмасам, 1897 елгы иде бугай ул. Яшь чагында укырга туры килмәгән. Ә туган илне икенче тапкыр азат итәргә туры килде үзенә. 1919 елда нәкъ шушы юллар буйлап Петлюра, Махно бандаларын куган ул.

Шулай итеп, Әхмәтҗанов тәкъдиме буенча, яр буйлап кузгалдык. Яр буенда ник бер ярык тагарак булсын! Авыллар яндырылган, халык — урманда, партизаннар янынннан кайтып җитмәгән. Яр буйлап килә-килә балчыкка, ләмгә буялып беттек. Ниһаять, Сваромье авылына килеп җиттек. Зур авыл булган. Янган. Фашист яндырган. Халык землянкаларда. Карт-коры да бала-чага. Сорашабыз. Көймәләр кирәк, дибез. Юк, диләр, теге якка алып китеп бетерделәр, дип әйтәләр.

Бер яшь җилкенчәк килеп чыкмасынмы шул вакыт!

— Да це же наши! [1] — ди бу.

Халык безнең өскә ябырылды. Шатлыктан елыйлар хәтта.

[1] Болар бәзнекеләр ич!

Чыннан да көймәләрне яшереп куйганнар икән. Киттек, караңгы төшкән булса да елгага киттек. Немец ерак инде дип ут кабызган идек, тотынды атарга! Кичү башлана дип уйлады булса кирәк.

Теге яшь җилкенчәк куркаклардан түгел икән. Алып китте безне камышлар эченә. Фашист ата, без аны бар дип тә белмибез.

— Болай ярамый бит, — ди Әхмәтҗанов, әлеге яшь хатын көймәләр яшерелгән урынны күрсәткәч. — Көймәләрне әрәм итүе бар. Иләк кирәкми безгә, көймә кирәк, — ди.

Нәрсә эшләргә? Нигә безгә атасың дип немецка шелтә ясап буламыни?

Өлкән сержант Әхмәтҗановның чәчә кыска булса да, акылы озын иде шул. Теге яшь хатынга нәрсәдер пышылдады гына. Яр буенда берничә урынга ут кабызырга кушкан икән. Фашистлар шул утларга ата башладылар. Шуннан файдаланып, без суга батырылган көймәләрне күтәрәбез. Ишкәкләрне теге яшь хатын табып китерде.

Менә кичү... Монысы — коточкыч төш кебек, дустым. Аны искә төшерсәң, һаман әле тәнгә салкын йөгерә. Ну, искә төшерергә кирәк. Якташың Зәйнетдин Әхмәтҗановка шушы төндәге батырлыгы өчен Герой исеме бирелде бит... Хәер, болай әйтү дөрес үк булмас. Сан, Висла елгаларын кичкәндәге егетлекләре дә аның таң атканчы сөйләрлек. Әмма беренче мәхәббәт онытылмый, дигәндәй, Днепрны кичү тамашасы хәтергә мәңгегә береккән.

Менә украин төне күз алдыгызда: күк йөзе сумала кебек. Черкиләр дә әллә кая юкка чыккан иде ул төнне... Соң, андый мәхшәргә черки түземе?! Фашистлар безнең якны прицельдә тоталар. Яр кырыена өзлексез мина ява, күк йөзен ракеталар телгәли. Бернәрсәгә карамыйча, паром ясыйбыз. Тисә — егыласың, санитарлар алып китә. Тими икән, мина чинавына, өстеңә су фонтаны ыргылуга игътибар бирмисең. Балтаң кулыңда.

Паромны Әхмәтҗанов эшләтә. Көймәләрне янәшә куеп, өскә бүрәнә-такталар салабыз, аларны бер-берсенә ныгытабыз. Паром утыз-кырык кеше, пушка, миномет кебек нәрсәләрне күтәрергә тиеш. Аларга урын түрдән. Сугышчылар, ишкәк тотып, ике кырыйга басачак.

Әхмәтҗанов, тирләп-пешеп, руль кебек нәрсә әзерли.

Унике тулыр алдыннан комбат безнең янга килде. Паромыбызны ошатты бу. Алтын иде шул Әхмәтҗановның куллары. Куллары гынамы соң! Үзе дә алтын кеше ул.

Комбат моның белән сөйләште. Рулевой итеп билгеләде. Беренче рейска автоматчыларны һәм пулеметчыларны алырга кушты. Икенчесендә җиңел пушкалар, минометлар китәргә тиеш.

Озакламыйча автоматчылар килде. Пулеметларны кулдан-кулга күчереп, урта бер җиргә бәйләделәр.

Ниһаять, комбат: «Вакыт, егетләр!» — диде.

Чүпрәк чолгаган ишкәкләр хәрәкәткә килделәр һәм бәләкәй паром тавышсыз-тынсыз кузгалып китте. Әхмәтҗанов аякларын киң аерып койрыкка баскан, куллар — рульдә. Күзләр Днепрның уң ягына төбәлгән. Паромны нәрсәгә карап алып баргандыр — шайтан белсен. Ну юл озын тоелмады. Яшь таллар үскән тыныч култыкка килеп төртелдек. Дошман сизмәде. Безнең сугышчылар төн караңгылыгына чумдылар, окоп казырга керештеләр.

Үзебезнең якка да хәвеф-хәтәрсез кайтып җиттек. Бу юлы салга пушка керттеләр. Расчеты, снарядлары белән. Бик куркыныч йөк. Бер читенә генә миңа эләксә дә, һавага очасың. Көлең дә калмаячак.

Әхмәтҗанов рульдә. Пышылдап кына команда бирә. Салда өлкән лейтенант та бар. Ләкин ул да рулевойга буйсынып, ишкәкчеләргә булыша.

Днепрны өченче тапкыр кичкәндә фашистлар сизенеп, бик яман ут ачтылар.

Рулевой Әхмәтҗанов: «Кызурак ишегез, егетләр!» — дип кычкырып җибәрде. Артиллеристлар пушкаларын кочаклап ятканнар, ишкәкчеләр ярым бөгелеп ишәләр. Бер Әхмәтҗанов таш сын кебек басып тора. Кулында руль. Пулялар сызгырыша, колакны тондырып миналар ярыла. Су фонтаны аны вакыт-вакыт бөтенләй күмеп китә, паром йомычка шикелле дулкынга күмелә, тагын күтәрелә, тагын төшә... Ишкәкчеләр каерып-каерып ишәләр, артиллеристлар, кырмыскалар кебек, бергә өймәкләшеп, пушканы упкынга тәгәрәүдән саклыйлар. Сал бата-чума юлын дәвам итә.

Елга уртасына җиткәч, паромдагыларны мина миңгерәтте. Янәшәдә генә ярылды ул. Күзләр күрми, колаклар ишетми. Бу — бәланең яртысы гына икән әле. Көтмәгәндә паром янтая башлады: көймәне мина кыйпылчыгы тишкән. Беттек, дигән уй йөрәкне «жу» иттерде.

— Суны түгәргә! Живо!

Әхмәтҗанов тавышы иде бу.

Без каскаларны, котелокларны эшкә җиктек. Көймәнең корсагыннан ургылып су керә. Нишләргә? Аптырашып торганда, Әхмәтҗанов килеп җитте. Күз ачып йомганчы гимнастеркасын салды һәм йомарлап тишекне томалап та куйды.

— Алга! — дип боерды рулевой, һәм без, ут, су туфанын җиңә-җиңә, юлны дәвам иттек. Агачларны тамырлары белән йолкый, өй түбәләрен кубарып ата торган давылларны кинода гына булса да күргәнегез бардыр. Шушы афәткә охшый иде бу төн.

Пушканы исән-сау илтеп җиткердек. Яраланучылар санчасткә барудан баш тарттылар. Тәнендә җаны бар сугышчыларның һәрберсе уңъяк ярга төште. Безнекеләрне Днепрга куып төшерергә чамалап дошман атакага килә иде.

Без кайтырга чыктык. Анда кичүгә хәзерләнгән сугышчылар паром көтә. Тизрәк, тизрәк. Ишәбез дә ишәбез. Эчке ак күлмәге тәненә ябышкан Зәйнетдин Низаметдинович паромны турылап бора. Җидешәрләп-тугызарлап фашист самолетлары килә. Нәкъ чеби алырга төшкән тилгән кебек түбәнгә атылалар һәм дистәләрчә бомба ташлап, үкереп өскә күтәреләләр. Ничек безгә тимәгәндер — башыма сыймый.

Таң атып килгәндә батальонның соңгы сугышчыларын паромга алдык. Күп барырга туры килмәде, яңадан көймәләрнең берсенә мина кыйпылчыгы тиде. Әхмәтҗанов рульне янындагы сугышчыга тоттырды да, өстеннән эчке күлмәген дә салып, тишекне томалады. Аннары яңадан койрыкка барып басты. Ракеталар яктыртканда аңа күз ташлап алабыз. Ул исән. Ялангач ябык гәүдә, кабарып торган мускуллар, кыска чәчле баш, чыланган мыек... Шартлауларга да, су фонтаннарына да исе китми. Аңа карап без дә иркенрәк сулыйбыз, беләкләрдә көч арткандай була.

Днепрны ничә тапкыр кичеп чыкканбыздыр — беребез дә төгәл генә хәтерләми. Тәүлек ярым буе туктаусыз эшләдек. Ашау-эчү юк, ял юк, йокы юк.

Зур паромнар килеп өлгерде, алар танклар, бронетранспортерларны алып киттеләр. Без снарядлар, миналар, патроннар ташыдык. Зәйнетдин һаман рульдә булды. Ничек түзгәндер, каян шулкадәр көч алгандыр ул.

Илле яшенә җитеп килгән бу куркусыз солдатның чын батырлыгын командование тиешенчә бәяләде. Аңа СССР Верховный Советы Президиумының 1944 ел, 23 сентябрь Указы белән Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Без аны күккә чөйдек, тәбрикләдек. Махшарне хәтерләткән кичү төнен һаман күз алдында торган дустым Әхмәтҗановка: «Батырлыгың алдында баш иям, әгәр сугыштан исән кайтсам, киләчәк буыннар сокланырлык образыңны мәңгеләштерермен», дип сүз бирде.

Әйткәнемчә, вәгъдәсен үтәде ул: татар халкының арсланга тиң батыр улына багышланган әсәре Киев дәүләт музеенда саклана...

Карт скульптор тынып калды. Мин аңа үземне тирәнтен дулкынландырган әңгәмәсе өчен рәхмәт әйттем һәм, мөмкин булса, әңгәмәдә телгә алынган рәссамны күрергә теләвемне белдердем.

— Юк-юк, мәшәкатьләнмәгез, — диде скульптор.

— Аңа да рәхмәт әйтәсем килә.

— Ул... ул андый мактауларны яратмый... Тыйнак кеше. Миңа гына әйтегез... Тапшырырмын, һичшиксез, тапшырырмын.

Без бүтән очрашмадык. Карт скульптор төнлә бик җитди авырып киткән һәм аны ашыгыч рәвештә больницага озатканнар иде.

Икенче көнне, ял йортыннан китү алдыннан, бу сәер карт турында уйлана-уйлана Киев дәүләт музеена юл тоттым. Батыр якташыбызның киләчәк буыннар сокланырлык образын күрәсем килде. Музей залларының берсендә таптым мин аны. Советлар Союзы Герое Зәйнетдин Низаметдин улы Әхмәтҗанов бюсты иде ул. Арслан йөрәкле батыр ирнең көчле рухын, тәвәккәллеген, кыюлыгын чагылдырган бу таш сын алдында озак басып тордым мин. Карт солдат үткән давыллы һәм данлы юл күз алдыма килде, кичә скульптор сөйләгән гаҗәеп әңгәмәне хәтерләдем. Махшаргә тиң кичүләргә катнашкан, скульптор дустым дип атаган тыйнак кеше кем соң ул? Постаментка күз салам. Анда: «Скульптор Я. Кравченко» дип язылган иде.

Мәскәүгә баргач, Зәйнетдин абзыйның сугыштан исән-сау әйләнеп кайтуы билгеле булды. Ул Башкортстанның Гафури районы, Ялгыз каен авылында яши икән.

Билгеле, скульптор аманәтен дә тапшырдым мин аңа.

◇◆◇

# ЧИШМӘЛӘР ЕРАКТАН БАШЛАНА

Татар осталарының ука белән күпертеп чигелгән бизәнү әйберләре әле бүген дә алтын бәясенә йөри. Саба районы элек-электән бу күркәм һөнәрнең үзәге саналган. Монда шул эшнең зур осталары булган, үз һөнәрләрен алар, мирас итеп, балаларына, оныкларына калдыра килгәннәр. Хәзер татар халкының ювелирлык сәнгате әкренләп онытылып бара. Хәтта Саба якларында да аның серләрен белүче һәм саклаучы картлар бармак белән генә санарлык. Шуларның берсе — Гыйниятулла Хаҗиәхмәтов.


Совет власте Гыйниятулла абзый балаларына зур мөмкинлекләр ача. Ишле һәм тату гаиләдән югары белемле төрле профессия кешеләре чыга. Шул ук вакытта аларның һәрберсенә әтиләре һөнәреннән дә нидер йоккан шикелле. Барысы да әдәбиятка һәм сәнгатькә һәвәс кешеләр, барысы да матур итеп рәсем ясый беләләр.

Әмма шулар арасыннан бер Тавил генә гомерен сәнгатькә багышлый, профессиональ рәссам булып китә. Тагын шунысы кызык, рәсем ясау белән ул бик яшьтән, үз-үзен хәтерли башлаган көннән алып мавыга икән.

Сугыш алдыннан Хаҗиәхмәтовлар гаиләсе Казанга күчеп килә. Рәсем ясау өчен буяулар кирәк, кәгазе кирәк. Бу авыр, кыен елларда каян табасың аларны? Кечкенә «рәссам» чүп-чар арасыннан буяудан бушаган банкалар җыярга керешә. Банка төпләренә ябышып калган буяуларны кырып запас әзерли, шулар белән рәсем ясый...

Ленинград шәһәре. Нева елгасының гранит ярлары буйлап Сәнгать академиясенең мәһабәт бинасы сузылган. А. Иванов, К. Брюллов, И. Репин, И. Шишкин, В. Суриков, В. Серов, М. Врубель кебек данлары бөтен дөньяга таралган мәшһүр рәссамнар шушында укыган. 1957 елда яңа гына Казан сәнгать училищесын тәмамлап чыккан базык гәүдәле татар малае Тавил дә шушы йортның бусагасын атлап керә. Гомер дигәнең аккан су кебек. Зачет һәм экзаменнарга әзерләнеп, иҗат эше белән мавыгып, алты ел гомер узып та китә. Тавил, диплом эше итеп, дәүләт имтихан комиссиясенә Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романына ясаган иллюстрацияләрен тәкъдим итә. Комиссия яшь рәссамның рәсемнәренә әйбәт бәя бирә. Укучылар хәтерлидер, Хаҗиәхмәтовның юкә агачында пычак белән кисеп эшләнгән ул гравюралары «Казан утлары» журналында басылып та чыкты...

1964 елдан 1967 елга кадәр Тавил «Яшь ленинчы» редакциясендә эшләде, газетаны яхшырту эшенә күп вакытын бирде, зур көч куйды. Елдан елга, саннан санга балалар газетасының сыйфаты күтәрелә, сәнгатьчә бизәлеш дәрәҗәсе камилләшә барды. Шул ук вакытта ул «Ялкын» журналын бизәүдә дә якыннан торып катнашты. Бу



*Тынлык.*

журналның Хаҗиәхмәтов тарафыннан эшләнгән тышлыкларын яшь рәссам иҗатының үзенә бер казанышы итеп карарга мөмкин. Дөресен әйтергә кирәк, художникның бу эше һәртөрле мактауга һәм хуплауга лаек. Нигә яшереп торырга, кайбер рәссамнарыбыз балалар матбугатында эшләүне бик үк яратып бетермиләр, моны хәтта вак эш дип санаучы кешеләр дә очрый бит. Әгәр матурлыкны аңлауның нигезе бала чакта калыплана башлавын исәпкә алсак, Тавилнең балалар матбугатындагы эшчәнлегенең әһәмияте бермәбер ачылып китәр.

Тавилнең иҗат эшчәнлеге әле башланып кына килә. Әмма инде бүген үк үзен ул киң диапазонлы рәссам итеп таныта алды. Ул тормыш матурлыгын бөтен тулылыгы һәм төрлелеге белән аңларга, тоярга тырыша, беркайчан да тегә яки бу аерым жанр кысаларында гына бикләнеп калмый. 1964 елда Хаҗиәхмәтов Казан органик синтез заводына багышланган гравюралар сериясе эшли. Шулардан берсе — «Кранчы Гөлсинә» исемлесе — авторга аеруча зур уңыш китерә. Ул «Зур Идел» күргәзмәсенә куела һәм Мәскәүгә, яшь рәссамнарның бөтенсоюз күргәзмәсенә җибәрелә.

Тавил «Туган як табигате» исемендә пейзажлар сериясе иҗат итәргә хыяллана. Буш вакытларында ул кырларга, яланнарга чыга, этюдлар ясый. Аның инде акварель һәм темпера белән эшләнгән йөзгә якын әзер этюды бар. Яшь рәссам матурлыкны реаль тормыштан эзләргә тырыша. Бу — аның төп иҗат принцибы. Шуңа күрә ул күбрәк табигать кочагында, кешеләр арасында була, дистәләрчә, йөзләрчә эскизлар төшерә, моның өчен вакытын да, көчен дә кызганмый. Аның караваы, авторның һәр рәсеме диярлек фикер ачыклыгы, композиция төзеклеге белән аерылып тора. Игътибарын иң кирәкле детальләргә юнәлтеп, автор реаль тормышта үзе күргән форма һәм төсләрне гомумиләштереп бирергә, табигатьтәге каршылыкларны тирәнрәк, ныграк ачарга омтыла, әмма беркайчан да тышкы матурлык артыннан куммый. Шуңа да аның пейзажлары тирән эмоциональ хисләр уята, табигатьне аңларга, яратырга булыша.

Хаҗиәхмәтов этюдларының төп кыйммәте аларның көчле шигъри тойгыларга, фикергә бай булуларында. Рәссамның агачлары да, куаклары да, хәтта үләннәренә кадәр тере җан иярре кебек кабул ителә. Автор зурлыклары, формалары, төсләре белән бер-берсенә охшамаган, берсе икенчесеннән нык аерылып торган үсемлекләрнең гаҗәеп дус яшәүләренә карап соклана. Әнә кимендә йөзне яшәгән карт чыршы. Чәнечкеле йонлач куллары белән ул юлның аргы ягында үсеп утырган яшь һәм шат каен кызларына үрелеп маташа. Бер этюдта автор көзге салкын кояшка карап ятимнәрчә боегып калган шәрә ботакларның кайгысын уртаклаша кебек («Кар көтә-



*Карт әянкеләр.*



*Күз-күл*

көтә»), икенчесендә урман чытырманлыгының серле караңгылыгын капшап карарга тели («Шүрәлеләр яшәгән җирдә»). Рәсәм табигатьнең иң нечкә авазларын ишетә, иң яшерен серләрен аңлый сыман. («Кичке сюита», «Тынлык», «Ноктюрн»). Табигатьтәге күп күренешләргә ул күчерелмә мәгънә сала. («Усаклар яна», «Яфраклар сөйләшәләр».) Табигать күренешләренең җанын аңлый белү, аларны шигъри фәлсәфи нәрсәләр итеп тою Хаҗиәхмәтов этюдларына сокландыргыч үзенчәлек өсти.

Авторның пейзажларына тагын бер үзенчәлек хас. Ул сызыкларны һәм тапларны сизгер тоя белә. Бу аңа чынбарлыктагы бетмәс-төкәнмәс бизәк вариантларын, ритмик чиратлашуларны һәм төсләр яңгырашын аңларга ярдәм итә. Бу яктан карагында, «Урман бизәкләре» дигән акварель аеруча үзенчәлекле. Бу эшендә рәссам, аерым бер ләззәт белән, гади урман пейзажын гүзәл орнаментлар җыелмасына әверелдергән. Шуңа карамастан, табигатьнең үз йөзенә, үз күренешенә бер дә зыян килмәгән. Әйе, Хаҗиәхмәтов чынбарлыктан аз гына да читләшми, ләкин табигатьнең очраклы һәм чуалчык күренешләрен саклык белән генә художник аңы аша үткәрә; аларны шигъри күңелле кешенең иҗади ихтыярына буйсындыра һәм, образның асылына зыян китермичә генә, пейзажның гүзәллеге турында сокланып сөйли белә.

Хаҗиәхмәтовның соңгы эшләреннән «Халык әйтсә — хак әйтер» дигән халык иҗаты әсәрләре җыентыгына ясаган иллюстрацияләре хакында берничә сүз. Ул рәсемнәрне графика сәнгатебезнең җитди күренеше дип бәяләргә була. Авторның рәсемнәре халыкчан юмор белән сугарылган, алар текстны бизиләр һәм тагын да тулыландырып җибәрәләр. Һәр персонаж сурәтен тәэсирле итеп күрсәтергә тырышу белән бергә, кара гуашьның тонык өслегенә ак буяулар белән гаять нечкә штрихлар ясап, Хаҗиәхмәтов детальләрне эшкәртеп чыккан. Бу эшендә автор кара, ак һәм зәңгәр төсләр генә кулланып, матур декоративлыкка ирешкән. Нәрсә бу? Китап графикасы казанышларын иҗади куллануму? Ата-бабалардан калган ювелирлык нәфислегенә тартылуму? Әллә

аңлы рәвештә татар фольклорына матур һәм эчтәлекле иллюстрация бирергә омтылумы? Бу сорауларга рәссам үзе дә анык кына җавап бирә алмас иде. Чөнки Тавилнең бу эшендә әле генә саналып кителгәннәренең барысы да бар һәм алар берберсенә тыгыз рәвештә бәйләнеп бирелгәннәр. Яшь графиктан без күп нәрсә көтәргә хаклы.

Соңгы елларда Тавил чит илләрдә йөреп кайтты. Ул анда күп нәрсәләр күргән, төрле агымнар белән иҗат итүче рәссамнарның эшләре белән танышкан. Ләкин, кайбер тотнаксыз кешеләр кебек, зәвыксыз агымнарга ияртмәгән, үзе сайлаган юлдан тайпылмаган. Яшь рәссамның халык алдындагы бурычын дөрес аңлавы һәм үзенең иҗади хезмәтенә җитди каравы безне куандыра.

Тавил сәнгать белән яши. Ул рәссамның көн саен, өзлексез рәвештә кулларын матурлык иҗат итәргә күнектерергә тиеш икәнлеген яхшы аңлый. Тавилнең чын мәгънәсендә иҗат итә башлавына нибары дүрт-биш кенә ел. Шулай да без аның сәләтенә, нечкә зәвыгына һәм дөрес юлдан бара алачагына тирән ышанабыз.

Гыйниятулла абзый татар осталарының ювелирлык сәнгате серләрен бүгенге яшьләргә биреп калдырырга хыяллана. Узгандагылар бүгенгегә һәм киләчәккә хезмәт итәргә тиеш. Халкыбызның талантлы бер вәкиле буларак, Гыйниятулла абзый улына халык сәнгатенең бетмәс-төкәнмәс хәзинәләрен оста куллана белергә өйрәткән. Хаҗиәхмәтовлар гаиләсе татар совет сәнгатенең гүзәл үзенчәлеген — узганнарның иң матур традицияләре белән социалистик чорның яңалыкка омтылышы бергә кушылып үсүне — ачык чагылдыра. Әнә шулай, милли сәнгать катлаулы диалектик юл белән яңа биеклекләргә күтәрелә бара.

**А. ФАЙНБЕРГ,**
**сәнгать белгече.**


















Ренат Харисов

# ҖӘЙЛӘР, КӨЗЛӘР НИНДИ БУЛЫР?

*(«Беренче карлыгач» турында уйлану)*

Узган ел «Беренче карлыгач» дигән тартма «канаты» астында үндүрт яшь шагыйрьнең беренче шигырь җыентыклары чыкты. Халык сынамышларын искә төшерә торган бу уңышлы исем безнең шигърият дөньябызга кемнәрне алып килде һәм алар нинди яз китерделәр икән! Моны белү, минемчә, бик кызыклы һәм әһәмиятле. Чөнки ул безнең шигъриятебезнең чәчәкле җәйләрен, җимешле көзләрен һәм торналар канатында илнең-җирнең төрле тарафларына китәчәк казанышларын күзалларга ярдәм итәчәк. «Беренче карлыгач» алып килгән бу язны һәрьяклап үлчәп карау, бәяләү бер мәкаләнең, бер кешенең генә кулыннан килә торган эш түгелдер, әлбәттә. Әмма прогноз өчен күпмедер дәрәҗәдә һәр фикер файдалы, диләр бит әле.

«Беренче карлыгач» вакытлы матбугатта 5—10 еллар дәвамында даими күренеп килгән авторларны туплаган. Димәк, нәшрият шактый иҗади юл, сынаулар үткән кешеләргә әдәбиятның киң мәйданына чыгарга ишек ачкан. Ләкин әдәбият мәйданының киңлеге — әдәбиятның меңләгән укучылар күңелендә һәм йөрәгендә булуы — авторларга да, нәшриятка да гаҗәеп зур җаваплылык йөкли...

Китап арты китап укыйсың, шигырь арты шигырь хәтергә сеңә тора. Шигырьләрдәге фикерләр, образлар, детальләр, алымнар торган саен конкретлаша бара, күңел экранында кайбер авторларның иң алдан бераз томан сарган, аннары шактый ачык булып күренгән лирик сурәтләре хасил була, ә кайберләренеке (ниндидер сәбәпләр аркасындадыр) томаннан арына алмый кала һәм «Беренче карлыгач» турында да, андагы авторлар, аларның китаплары турында да шактый гына фикерләр туа.

Килгән язның нәрсәләр вәгъдә иткәнен бераз гына булса да ачыклау өчен, авторларга, мәкалә чикләре ирек биргәнчә, конкретрак тукталырга кирәктер.

Тематик яктан Гәрәй Рәхимнең «Вәгъдә» исемле китабы «Беренче карлыгач»ның калган җыентыкларыннан әллә ни аерылып тормый кебек. Шул ук мәхәббәт, дуслык хисләре, сугыш һәм тынычлык темасы, җир һәм кеше, хезмәт, бәхет, сагыш, табигать... Ләкин андагы шигырьләрнең, күңелләрне биләп, ниндидер яңа ассоциацияләр тудырулары, йөрәктә я олы мәхәббәт, я кискен нәфрәт хисе уята алулары шагыйрьнең күптән таныш бу темаларга яңача карый белүе турында сөйлиләр.

Шигырь китаплары, гомумән алганда, үзләренең лирик геройлары белән кыйммәтлеләр. «Вәгъдә»нең лирик герое, һичшиксез, кызыклы. Ул дөньяга, тормышка конкрет таләпләрдән чыгып карый һәм, бәхеткә каршы, бу таләпләр яшәешнең күп тармакларын иңлиләр. Алар шагыйрьнең иҗади аңына катгый юнәлеш биргәннәр һәм бу юнәлеш тирәсендә шактый кызыклы шигъри дөнья калкып чыккан. Дөрес, бу дөнья әлегә яралу стадиясендә генә. Ләкин аның кайдан башланганын, кая таба үсүен инде хәзер үк чамалап була. Минемчә, Гәрәй Рәхимнең шигъри дөньясына керү,

теләк-омтылышларын сиземләү өчен, аның «Игеннәр иләнгә», «Миләш төбендә» дигән шигырьләрен укырга кирәктер. Шагыйрьнең эчке монологлары буларак, алар Гәрәй Рәхимнең карашлары, идеаллары, өметләре турында ачыграк сөйлиләр, ә конкрет өметләрдән конкрет таләпләр туа.

«Көзге урман» шигырендә Гәрәй Рәхим башта табигатьнең төсләргә, җимешләргә муллыгын сурәтли, аннары — яфраклар коелганны, кошлар киткәнне... һәм:

Песнәк оча. Ул ашыга
Тизрәк авылга кайтырга.
Көзен киткән кошлар өчен
Авыл ямен баетырга, —

дип, табигатьнең югалтуларын күңеленнән генә булса да тутырырга тели. Бу шигырьдә үткәрелгән фикерләрне: «Тормышны көз кебек мул, күптөсле, бай хисле итеп күрәсем килә һәм мин аның шулай булачагына ышанам!» дигән җөмлә белән дә әйтеп булыр иде кебек. Ләкин шагыйрь идеаллар һәм чынбарлык арасында тарих үтәсе шактый озын һәм көрәшле юл барлыгын да белә. Ул юл бер-берсе белән даими конфликтта торган, бер-берсен җиңеп, чигендереп барган контрастлардан, капма-каршылыклардан гыйбарәт. Ә шагыйрь үз шигырьләренең һәр образы, һәр фикере белән тормышны ямьле иткән, бәхетле, якты иткән якларга көч өстәргә тырыша — алар җиңсен! Аның мәхәббәте һәм нәфрәте, бер бәйгегә җигелеп, кеше күңелен гүзәллекләр иленә таба тарталар. «Вәгъдә»нең күпчелек шигырьләре менә шушы фәлсәфи нигезгә корылып язылганнар да. Дөрес, тормыштагы капма-каршылыкларны үз шигъри дөньяларының нигезе иткән шагыйрьләр безнең әдәбиятыбызда да байтак. Татар совет поэзиясенең шундый гүзәл бер вәкиле итеп Әхмәт Фәйзине күрсәтер идем. Ләкин Гәрәй Рәхим Әхмәт Фәйзинең эпигоны түгел. Әгәр Әхмәт Фәйзи контрастларны сатирик, я юмористик планда алырга ярата, яшь шагыйрь аларны социаль-фәлсәфи планга куерга тырыша һәм үзенчә уңышларга да («Вәгъдә», «Сагыш һәм шатлык», «Рас») ирешә, уңышсызлыкларга да («Буыннан буынга», «Нәфрәт. Рәхмәт») юлыга. Ул уңышсызлыклар нигезендә, минемчә, риторизмга сугылу я булмаса контрастларның образ-фикер буларак тәгалләнеп җитмәве.

Нәфрәт — вокзалларга,
Аерып торган өчен.
Вокзалларга рәхмәт,
Кавыштырган өчен.
*(«Нәфрәт. Рәхмәт»)*

«Вәгъдә», «Сагыш һәм шатлык» шигырьләрен Гәрәй Рәхимнең иҗади вәгъдәсе итеп карарга, антитезаларга корылган фәлсәфи хисләрнең әле үсә, киңәя һәм тирәнәячәгенә ышанырга мөмкинлек бирәләр:

Йөрәкләр турында язасы бар әле —
Сафланган йөрәкләр,
Тапланган йөрәкләр,
Тапталган йөрәкләр турында.
(Бит әле кайдадыр
Сафланган йөрәкләр таптала,
Тапталган йөрәкләр аклана.)
*(«Вәгъдә»)*

Сары төс төяп көз килгән мәлдә
Күңелне сагыш биләргә тиеш.
Ләкин яз төяп кошлар кайтыр дип,
Сагышны шатлык җиңәргә тиеш.
*(«Сагыш һәм шатлык»)*

Бу инде килгән язның Гәрәй Рәхим өлешенә тигән ягы шактый матур җәйгә әверелачәге турында сөйлидер.

Мөхәммәт Садыйковның «Зәңгәр юллар» исемле җыентыгы, бала чагы сугыш елларына туры килеп, сугыштан соңгы елларда буй җиткән, дөньяга карашы формалаш-

кан кеше образын гәүдәләндерә. Илебезнең тарихыбызның бу чоры «Зәңгәр юллар»ның лирик герое аңына шул кадәр тирән сеңгән ки, хәтта безнең бүгенгебезгә булган мөнәсәбәтенә дә үзенең төсен, юнәлешен биреп тора. Һәм шушы юнәлеш Мөхәммәт Садыйковның шигъри дөньясына төзлек, үзенә генә хас колорит китерә. «Зәңгәр юллар»ны, кайбер ташламалар ясап, мөстәкыйль шигырьләрдән үрелгән поэма дип тә атап булыр иде.

Мөхәммәт Садыйковка, шинель киеп, иңенә солдат биштәре асып, канлы сугышлар булган җирләрдә йөрергә туры килә. Ул Польша җирләрендәге концлагерь хәрабәләрен күрә, «җан өрердәй булып», пуля эзләре төшкән мәрмәр сыннарга карап тора. Татарстаннан Радомга сузылган юлларның һәр адымы шагыйрь күңелендә сугышка нәфрәт, сугыш корбаннарына, сугыш батырларына олы ихтирам уята һәм драматизм тулы шигырьгә әверелеп бара. Туган җирләрдән беразга гына булса да аерылып тору шагыйрьгә туган илнең кадерен күңеле белән татырга ярдәм итә. Одер елгасын күрү аның күз алдына магърур Иделне китереп бастыра, постта торган чакта җилләр дә ил ягына исәләрдер кебек тоела...

Тынычлык өчен барган хәрби хезмәт тәмам. Солдат туган якларына кайтып бара. Кинәт аның йөрәгенә гаҗәеп хисләр тула, ул туган иленең юмарт кунакчыллыгын хәтеренә төшерә... һәм аның күңелендә үзеннән-үзе тормыш яме, җир гүзәллеге турындагы шигырьләр таша башлый...

Сулап исерерлек язгы һава,
Хәйран калып торам:
Яңа салган авыл йортлары да
Яфрак ярыр сыман.
(*«Язгы күкрәү»*)

Бер карасаң, алда сөйләнгән сюжет, бу фикерләр һәм хисләр безнең шигъриятебез өчен һич тә яңа түгел. Шуның өстәвенә әле Мөхәммәт Садыйковның «Зәңгәр юллар»дагы шигъри дөньясы киңлек ягыннан да шактый чикле. Ләкин эш бу дөньяның тирәнлегендә һәм төгәллегендә. Чөнки шушы тирәнлек һәм төгәллек шагыйрьнең мөмкинчелекләрен күрергә ярдәм итә, ә чикләр, шагыйрьнең биографиясенә карап, киңәя ала торган нәрсәләр.

Шамил Маннаповның «Яшьтәшләрем» һәм Хәниф Хөснуллинның «Исәнмесез» исемле җыентыкларындагы лирик геройларның сурәтләрен ачык итеп күрү әлегә кыен. Ләкин бу — әлеге шагыйрьләрнең үз йөзләре бөтенләй юк дигән сүз түгел. Авторларның икесе дә җор сүзле, бай хисле, дөньяның җитди күренешләренә дә ничектер олыларча тыныч һәм юмор аша карый белә торган кешеләр. Шамилнең шигырьләре Хәнифнекеннән, билгеле, аерылып тора. Әгәр дә Хәниф шигырьләрендәге драматизм лирик геройларның шушы мизгелдә кичерә торган тойгылары нигезендә туса, Шамилдә ул детальләр янәшәлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә. Икенче төрле итеп әйткәндә, Хәнифнең лирик герое үзе дә драматизмны тудырган вакыйга эчендә була («Институтта», «Көзге төндә», «Рәсемеңне күрдем берәүдә», «Тынгысыз төннәр»), ә Шамилнең лирик герое тормыш детальләрен күбрәк абстракт төшенчә килеш чагыштырырга ярата һәм мондый янәшә куюдан килеп чыккан драматизм гомумирәк төскә ия була («Охшату», «Әйтә халык», «Кеше хисе»). Нәтиҗәдә бу — Шамилгә күргәне генә түгел, ишетеп белгәне турында да язарга мөмкинлек бирә, шагыйрьнең тематик диапазонын киңәйтә.

Моннан чыгып, тойгыларга нигезләнгән шигъри дөнья таррак була икән дип уйлау, билгеле, дөрес булмас иде. Чөнки кеше тойгыларының төсмерләре сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да чиксезләр. Тойгылардан туган шигъри дөньяларның бик әһәмиятле үзенчәлекләре бар: алар логик анализга бик авыр биреләләр һәм шагыйрьнең фикерләр фабуласын күзалларга шактый комачаулыйлар. Шуның өчен дә «Яшьтәшләрем»нең, бигрәк тә «Исәнмесез»нең лирик геройларын ачык итеп сурәтләү артык җиңел эш түгел. Ләкин бу билгесезлек, минемчә, куркыта торган нәрсә түгел. Киресенчә, күңелдә авторлар белән тирәнрәк кызыксыну хисе уяна, аларның иҗатларыннан ниндидер яңалык өмет итәсең. Ике шагыйрьнең дә шигырь техникасын яхшы белүләре, кителмәгән алым белән образлы фикерләүләре, үзләренең биографияләре аларның мөмкинчелекләренә өмет бagларга юл куя.

Алда саналган дүрт авторның, бигрәк тә Гәрәй Рәхимнең, тагын бер күркәм ягы бар. Ул — кешелекнең иң бөек ләззәте — фикер, уй ләззәте! — дигән фәлсәфи тәгълиматка шагыйрьләрчә инану. Шуның өчен дә алар, кешенең акылына мәдхия җырлау белән беррәттән, үзләренең образ-фикерләрен ләззәт бирерлек итәргә тырышалар. Бу инде «Литературная газета», «Литературная Россия» газеталарында күп телгә алынган «интеллектуаль поэзия»гә якынаерга тырышу һәм кайбер нокталарда шактый якынаю дигән сүз.

«Беренче карлыгач»ның калган авторларына да тукталсаң, яхшы булыр иде булуын (башка укучылар, бәлки, тукталырлар да), ләкин, мәкалә чикләрен ихтирам итеп, «Беренче карлыгач»ның башка гомумирәк мәсьәләләренә күз салыйк.

●

Китапханәнең кыйммәте — андагы китапларның күплегендә һәм төрлелегендә. Шигъриятнең көче исә шагыйрьләрнең күплегендә һәм төрлелегендә. 1967 елда ундүрт яшь шагыйрь үзләренең беренче китапчыкларын чыгардылар. 1968 елда да шуның хәтле үк яшь шагыйрь «беренче карлыгач» булырга тора. 1969 һәм 1970 елларда да, бәлки, нәкъ шулайдыр. Чөнки узган декабрь аенда гына уздырылган конференциядә шактый күп шагыйрьләр катнашты. Күрәсең, шигъриятебезнең киләчәге сан ягыннан бик өметле. Ләкин дөньяда, Тукай сүзләрен үзгәртеп әйтсәк, «Өч бертөслегә алмашынмас бер үзенчәлекле шагыйрь» дигән критерий да барлыгын онытмаска кирәк. Бигрәк тә — шагыйрь булырга җыенучылар күп булганда.

Китапчыктагы аннотацияләр белән танышып чыксаң, «Монда үзенчәлекле шагыйрьләр җыелган икән!» дигән фикергә киләсең. Ә шигырьләрне укыганда, өмет тулы бу фикер әкренләп үзгәрә башлый.

...Кулыңа алган туфрагың
Манчылсын кайнар тиргә.
*Д. Сирай.*

Таныш юллар мине алып кайтыр
Тирем тамган колхоз җиренә.
*З. Шәйхуллов.*

Маңгаемнан тирләр тамганда...
*Ә. Гатиуллин.*

Сай буразналар өстенә
Түгелде маңгай тире.
*Р. Закиев.*

Туфракны мин тирем белән ашлап...
*Е. Уткин.*

Тир белән
Сугарып шул
Кысыр далаларны...
*З. Шәйхетдинов.*

Мисаллардан күренгәнчә, тир һәр очракта «Әй, тырышып эшләдек тә соң!» дигән мәгънәгә ия. Утызынчы, кырыгынчы еллардагы шигъриятебезгә хәтер канатында гына булса да барып кайтсак, без бу образның бер мәгънә эчендә инде күптәннән бирле катып калганын күрер идек. Дөрес, сугыш елларында, бик хаклы рәвештә, тир кан сүзе белән алмаштырылган. Бу — образларның тарихи, социаль күренешләргә нык бәйле булулары турында сөйли торган кечкенә генә бер мисал. Утызынчы еллар инде күптән үтте, кулдан урак, кәйлә, көрәк төште, һәм тир сүзе дә үзенең баштагы мәгънәсен яртылаш югалтты. Тырышлык символы буларак, беренчелекне «тән тире» түгел, «акыл тире» алды. Шуңа күрә дә, бу образ, аңга, күңелгә тәэсир итүдән элегрәк, борынга бәрә башлады. Кыскасы, ул шаблонлаштырылган әдәби фальшь булып яңгырый. Кызганычка каршы, күптән таныш булган һәм, әдәбиятыбызда озак еллар яшәп, искергән образларны эпигоннарча куллану бер тир сүзе белән генә чикләнми.

Шигъриятта иң күп кулланыла торган чәчәк образын алыйк. Ул, мәхәббәтнең мәңгелек символы булып, күптән инде образлы фикерләүнең штампланган деталенә әверелгән инде. Әгәр берәр шигырьдә күзгә ялгыш кына чәчәк сүзе чалынса, ул шигырьне уку теләге кинәт сүнә. Чөнки белеп торасың, сүз егет һәм кыз арасындагы (сирәк кенә ир белән хатын арасындагы) мәхәббәт я, киресенчә, бер-берсеннән суыну хисләре турында булачак. Әгәр дә чәчәк шиңгән булса, алдан ук бераз авыр сулап куярга була. Димәк, мәхәббәтләр суынган, беткән, ә чәчәкләр шаулап, нурланып, хуш исләр бөркеп утырсалар — кайгырыр урын юк, эшләр ал да гөл генә.

...Гариф абый алып килгән иде
Зәңгәр чәчәкләрен сиреньнең...

*Е. Уткин.*

Ул чәчәкләр бирде өзеп-өзеп,
Сөйләсеннәр ди-ди хисемне...

*Т. Камалиев.*

Кайдан табыйм икән җир гөлләрен,
Тере гөлләр эзлим кез кенә.

*Ә. Гайнуллин.*

Ал син аны — күңел чәчкәсен.

*Р. Зәкиев.*

Чәчәкләргә кен дә сулар сиптең,
Сөюләрең чиктән ашканга...

*И. Фазлуллин.*

«Сине тештә күрдем, — дип язгансың, —
Чәчәк җыйдык икәү...» — дигәнсең.

*Ш. Маннапов.*

Чәчәк образына яңалык өстәү җиңел эш түгел, билгеле. Аның фәлсәфи асылы дистәләгән гасырлар буе кешелек өчен уртак булган. Ләкин кеше чәчәктән үзе теләгәнчә файдалана, аны үзе теләгән урында үстерә, аны бүләк итә, кабер өстенә куя, күкрәгенә кадый, такыя итеп башына кия, аның белән дәвалана, агулый, хәтта аны политик байрак итә (Белояннис, кызыл канәфер чәчәге) һәм башкалар, һәм башкалар... Күрүебезчә, халык чәчәктә бик күп мәгънә күрә, ә безнең «Беренче карлыгач» авторларының күбесе аны фәкать бер мәгънәдә генә кулланган. Ярар, алар чәчәк образына яңа төсмер кертүне максат итеп куймаганнар, ди. Аларның максаты — мәхәббәт хисләрен оригиналь рәвештә күрсәтү булган, ди (әгәр дә бусы да максат булмаса, иҗат итеп тору мәгънәсезлек була бит!). Тапталган образлар, детальләр белән тапталмаган шигырь иҗат итү, минемчә, мәсьәләгә нииндидер яңа логик алым белән килүне таләп итә, ә андый алым, кызганычка каршы, күренми.

Менә тагын бер штамп.

Синә булса бары унсигез?

*Е. Уткин.*

Ә унсигез — күңелгә.

*Х. Хөснуллин.*

Булырсың гел унсигездә!

*И. Фазлуллин.*

Унсигез яшь кенә дисең дә!..

*Т. Камалиев.*

Дөрес, шигырь тукымасыннан суырып алынган аерым юллар табигый булмаган халәткә килеп эләгәләр һәм мәгънәләренең шактый өлешен югалталар. Шулай булуга да карамастан, аерым юллардагы әдәби алымнар үзләре турында җитәрлек мәгълүмат бирерлек дәрәҗәдә калалар. Алдагы мисаллардагы «унсигез» сүзе белән дә нәкъ шундый хәл. Ул сүз һәр очракта бер үк мәгънәгә ия, бер үк максат белән кулланылган һәм «Беренче карлыгач» авторларының бертөсле образлы фикерләүләре турында сөйли. Туган җир, туган як, йөрәк, чишмә, яз, бәхет, матурлык, каен, ана һәм башка, һәм башка образлар да яшь шагыйрьләрнең күпчелеге тарафыннан бер төсле үк, бер мәгънәдә диярлек үк бирелгән. Алай гына да түгел, бу бертөслелек безнең шигъриятебездә элегрәк булган бертөслелектән дә аерылмый диярлек.

«Беренче карлыгач»лар безгә таныш образларны, күнегелгән детальләрне үстерәп-баетып торуны кирәк тапмыйча, турыдан-туры яңа образ-фикерләр алып килгәннәрдер, бәлки!

Абсолют яңа образ-фикерләр тууы фәннәрдәге яңа ачышларга, социаль үзгәрешләргә, эстетик һәм этик критерийларның хәрәкәтенә, моральнең чикләренә бәйле. Ягъни яңа ачышлар, социаль үзгәрешләр, эстетик һәм этиканың бүгенге казанышлары кешене тормышка яңача карарга мәҗбүр итәләр. Хезмәт процессларының һаман да автоматлаша баруы, кибернетиканың көннән-көн тормышка, аңга ныграк үтүе һәм башка бик күп казанышлар Җир һәм Кеше, Кеше һәм Галәм, ике социаль система (социализм һәм империализм) арасындагы мөнәсәбәтләргә җентекләбрәк карарга боералар һәм мөмкинчелек тә бирәләр. Бу мөнәсәбәтләрне белмичә, аларга конкрет үз карашыңны булдырмыйча бүген сәнгать белән шөгыльләнү дилетантлык булыр иде.

Ә «Беренче карлыгач»ның күпчелек авторларында тормышны фәлсәфи яктан конкрет өйрәнү сизелми һәм яңа образ-фикерләр дә күренми. Тормышны белү ул, минемчә, әйберләрне, профессияләрне, аерым шәхесләрне, аларның ничек яшәгәннәрен, нинди төзелешләрдә я колхозларда эшләгәннәрен генә белү түгел. Болар тормышны өйрәнүдәге бик вак детальләр генә. Менә шул вак детальләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең асылына төшенү, анда зуррак гомумзакончалыклар күрә алу, ул закончалыкларның кайсына киртә куярга, кайсына үсәргә ярдәм итәргә тырышу — бу инде тормышны тирәннән белү. «Беренче карлыгач»ларның кайберләре, кызганычка каршы, әнә шул вак детальләрне генә җентекләп белүдән ерак китә алмаганнар. Һәм, табигый, яңа образ-фикерләр дә тудыра алмаганнар.

Ә хәзер «Беренче карлыгач»ларның форма үзенчәлекләрен алыйк. Моның өчен яңалыкны, оригинальлекне дәгъва итми торган бер мисалга тукталыйк.

## Үкенү хаты

Юлдан олау узды... Шул олаудан
Бер уч печән алып иснәдем.
Яшәртә ул мине, гел яшәртә,
Көчәйтә ул якты хисләрне.

Йөрәгемдә җылы дулкын булып
Ташкынланган чагы хисләрнең...
Тоеп торам бөтен йөрәгем белән:
Сагыну тулы хатлар көтәсең.

Күпме көннәр, күпме еллар үтеп,
Күпме алсу таңнар атмады...
Нәрсә әйтим, нәрсә языйм сиңа,
Агачларда яфрак саргайды.

Кичерсәнә дип тә әйтә алмыйм,
Һай, бу хәлләр бигрәк өрнетте.
Баш ияргә кушты афәт җиле,
Иңбашымнан тотты селкетеп...

Иреннәрем исемең пышылдыйлар,
Белсәң ничек күңелем тулганны!
Эх, хәзерге акыл булса ул чак,
Дисвительни җүләр булганмын.

Чүкеч тотып сәлләнгән сәен
Көчә ерта икән кулларның...
Сизәсеңме, печән иснәдем дә
Сиңа инде хат та юлладым...

Бу шигырьне шушы килеш «Беренче карлыгач»тагы бер китаптан да табып булмый. Ул — җыелма шигырь, ягъни һәр ике юлы конкрет бер авторныкы һәм аларга бернинди үзгәреш тә кертелмәгән. Дөрес, бу мисал — ясалма эксперимент кына. Ләкин ул «Беренче карлыгач»лар турында, минемчә, шактый объектив фикерләр әйтергә ярдәм итә. Күренгәнчә, шигырьнең ритмик агышы шактый шома һәм бу безнең авторларның фикер ягыннан гына түгел, бу очракта образның ритмик төзелеше ягыннан да игезәкләр икәне турында сөйли. Ул чыннан да шулай: китаплардагы барлык шигырьләр диярлек 8—7, 10—9 иҗекле юллар белән язылганнар, әйтерсең лә җир йөзендә башка шигъри калыплар беткән.

«Беренче карлыгач»тагы шигырьләр сурәтләү чараларының гаять ярлы булулары белән дә шаккатыралар. Кая киткән Тукайлар алып үстергән, безнең шигъриятебезгә шәрык колориты биргән моноримнар! Дәрдмәнд шигырьләрен кабатланмас мәгънә белән баетырга ярдәм иткән ассонанслар, аваз язымнары кая югалган! Кая Дәрдмәнднеке кебек катлаулы рифмалашуга корылган оригиналь строфалар!.. Бу сорауларны әле тагы да дәвам итеп булыр иде. Гади чагыштыру, сирәк-мирәк кенә сынландырулар һәм метафоралар куллану авторларны тулаем канәгатьләндерә булса кирәк. Ләкин алар зәвыгы көннән-көн үсә, нечкәрә барган укучыларны канәгатьләндермиләр дип уйлыйм.

Тагын бер әһәмиятле мәсьәлә — шигъри жанрларның бертөрлелеге. «Беренче карлыгач»тагы барлык әсәрләрне бары ике-өч кенә жанр төренә бүлеп була: шигырь, поэма, җыр. Соңгы икесе — бернечә генә. Жанрларга ярлы булу әдәбият өчен бик күңелсез вакыйга. «Беренче карлыгач» алып килгән «язда» пародияләр, бәетләр, элегияләр, романслар, сонетлар, газәлләр, касыйдәләр һәм башка, һәм башка жанрлар һәм шигырь төрләре очратырга теләгән шигъриятебезнең өмете акланмады. Опера, оратория, кантата, музыкаль драма я комедия либретточылары да, кызганычка каршы, «Беренче карлыгач»та күренми.

Шулай итеп, беренче нәтиҗәләргә дә килеп җиттек кебек. «Беренче карлыгач»ның күпчелек авторлары үзләренең образлы фикерләүләре, шигъри алымнары, жанрлары, шигъри формалары, хәтта темалары белән дә бер-берсеннән әллә ни аерылып тормыйлар. Бу инде әлеге нәтиҗәнең сәбәпләре турында уйланырга мәҗбүр итә. Барлык авторларга да хас сәбәпләрнең берсе, минемчә, шигъриятебезнең үткән юлын бизмән итеп (ул юлда ниләр бар һәм ниләр юк икәнен белмичә) үз иҗатыңны бәяләмәү һәм шуның аркасында әдәбият мәйданында үзеңнең кем икәнеңне шәйләп бетермәү, үз максатыңны әдәбият максаты белән бәйләмәү. Ә әдәбиятның максаты һаман да яңа әсәрләр, яңа жанрлар, яңа алымнар, формалар, яңа фикерләр һәм проблемалар белән тулыланып тору һәм укучыны баету.

Яшьләр иҗатына профессиональ тәнкыйтьнең якын килмәве һәм, бәлки, килә алмавы да әлеге игезәкләнү процессының тирәнәя баруына ярдәм итә. Тәнкыйть якын килә алсын өчен, һәр яшь автор даими рәвештә матбугат битләрендә басылып, үзенең үсеш юлын мөмкин кадәр тулырак күрсәтергә тиеш. «Татарстан яшьләре»ндә берәр шигырь, «Казан утлары»нда ике-өч шигырь белән елына бер күренеп алу гына әлеге таләпкә җавап бирә алмый. Мәйдан булмау яшьләрнең шагыйрь булып үсү процессын озынайта һәм «табигый сайланыш» дигән табигать законына үз бурычын булачак әдипләр арасында башкарырга ирек бирми. Нәтиҗәдә — бертөслелек, игезәклек безнең шигъриятебезгә саркып үтә.

●

Хәзер «Беренче карлыгач»ка башка яктан күз салыйк.

Әдәбиятка килгән яшь шагыйрьләр бер-берсенә бик охшаганнар дисәк тә, алар китап тышлыклары кебек үк охшаш түгел. Тартма ундүрт китапка бер кыяфәт биреп ундүрт шагыйрьне тагын да төссезләгән.

Тартмада чыгаруның киләчәге турында уйлансаң, аның тагын бер «хикмәтен» сизәсең. Ул менә нидән башлана: егерме битле бер яки ике брошюраны гына тартмада чыгарып булмый. «Беренче карлыгач»ны кассетада дәвам итәр өчен, шагыйрьләр запасының зур булуы кирәк. Ә ел саен ундүрт я ун шагыйрь (сүзнең чын мәгънәсендә) туып тормый. Шулай булгач, «Беренче карлыгач»ның чираттагы чыгарылы-

шын өч-дүрт ел котәргә, я тартманы һәр ел чиле-пешле шигырь китаплары белән тутырып чыгарырга кирәк. Өч-дүрт ел көтү — берничә талантлы яшьнең иҗади үсешен тоткарлап тору (дөньяга чыккан әсәр, бигрәк тә китап — бик зур иҗади стимул), ә ашыккан очракта — шигърият өстәленә полуфабрикат чыгару, укучыларыбызның үсеп барган зәвыгын аптырашта калдыру.

Перспективадагы ике мөмкинчелекнең икесе дә әдәбиятыбызга файдасыз. Әгәр дә «Беренче карлыгач»ны тартмадан арындырып рубрика рәвешендә генә дәвам иткәндә («Мои первые книжки» рубрикасы сыман), я булмаса аның бераз өлешен генә яхшыртылган тартмада (бүләк өчен) калдырсаң, файдадан гайре бернәрсәсе дә булмас иде, һәм һәр талантлы яшь шагыйрь тулырак килеш әдәбият мәйданына чыга барып, укучыларга да тизрәк ирешер иде.

«Беренче карлыгач»ның эшләнешенә, кыяфәтенә кагылышлы берничә сүз дә әйтәсе килә. Басылып чыккан китапларның эшләнеше турында матбугатта күптән инде бик әйбәтләп сөйләшергә вакыт.

Борис Слуцкий «Литературная Россия» газетасындагы бер мәкаләсен (1967 ел, март, № 10) болай башлый: «Шагыйрьнең беренче китабы өчен өч нәрсә зарури: яхшы фотография, яхшы биография һәм яхшы исем. Болардан тыш — яхшы шигырьләр дә». «Беренче карлыгач»ны шагыйрьләрнең фотографияләре һәм биографияләре белән чыгарып нәшрият бик дөрес иткән. Китапларның исемнәре дә шактый уңышлы сайланган. Ләкин болар гына китапны күркәм итеп бетерә алмый әле.

«Беренче карлыгач»ның тартмасы төрү кәгазе вазифасын үтәргә генә эшләнмәгән, аның бурычы — бу ундүрт китапны еллар дәвамында «давыллардан-яңгырлардан» саклау, аларны берләштереп тору. Шулай булгач, ул нык картоннан я башка материалдан эшләнгән булырга тиеш иде. Икенчедән, кассета гомумән дөрес эшләнмәгән. Кеше, әгәр дә ул сулагай булмаса, тартманы сул кул белән тота да аның эчендәге әйберне уң кулы белән ала. Ә «Беренче карлыгач» кассетасы кирегә эшләнгән, ягъни аның авторы кеше кулының еллар, гасырлар буе алган күнекмәсен истә тотмаган. Бу әйткәннәрне кайберәүләр вакчыллану дип тә кабул итәләр. Ләкин шунысын да онытмаска кирәк — хәзер инде чүкеч сабын да, ишек тоткасын да, станокларны да бүгенге эстетик таләпләргә таянып эшлиләр. Ә китап кешеләргә культура, белем, зәвык алып килә торган әйбер һәм ул һәр яктан да камил булырга тиеш.

Хәзер китаплар хакында. Алар авыл хуҗалыгы культураларын үстерүдә тәҗрибә уртаклашу нияте белән чыгарылган брошюралар сериясен хәтерләтәләр. Шигырь җыентыклары өчен, аларның авторлары өчен бу бик күңелсез хәлдер. Китапны ачкач ук беренче булып күз карашын өткән нәрсә — китапның ике этажлы паспорты. Өске катта «газетная линейка» дигән кайма белән әйләндереп алынганы, аста шул ук паспорт, ләкин каймасыз. Бу шигырь китабына хас нәфисләкне алдан укүтереп куя.

Эчтәлекнең, паспортның я китапның алдында гына, я ахырында гына булырга тиешлеге, заставкаларның һәр китап өчен аерым булырга тиешлеге, шигырь исемнәренең баш шрифттан җыелырга тиешлекләрен, эпиграф һәм багышлау шрифты шигырь шрифтыннан аермалы булырга тиешлеге турында әйтеп китү дә бик җиткәндер.

Әлеге җитешсезлекләргә укучыларның игътибар итмәве дә мөмкин. Ләкин бу әлеге җитешсезлекләрнең җаваплылыгын һич кенә дә киметә алмый. Чөнки, укучыларның эстетик таләпләрен, зәвыкларын тәрбияләүне күз алдында тотканда, ул гафу итмәслек факторга әйләнә.

●

«Беренче карлыгач»ның дөньяга килүе, һичшиксез, күңелле вакыйга. Ул изге максат белән эшләнгән. Аның турында, бәлки, шушы язган хәтле үк мактау сүзләре язып булыр иде. Ләкин эш анда түгел, эш шагыйрьнең беренче китабын беренче тапкыр чыгару принцибында һәм бу принципның әдәбиятыбызга нәрсәләр бирүендә. «Беренче карлыгач»ның беренче чыгарылышына эшнең әлеге әйткән асылы күзлегеннән карасаң, шуны әйтеп була: кассетада килеш ул яшь шагыйрьләрне бик чикләгән һәм аларның мөмкинлекләрен, аларның үзенчәлекләрен тулы итеп күрсәтә алмаган.

Ә үзе турында үзе ул болай әйтә кебек:

«Хөрмәтле иптәшләр! Мин канатларыма төяп килеп шигърият кырыгызга быел бик күп нәрсәләр чәчтем. Арада берәр бөртек солы, арыш, карабодай һәм бодай бар бугай... Алдагы көзләрегез турында үзегез уйлагыз!».

*ЗАРИФ БӘШИРИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ*

## З. Бәшири

# ЗАМАНДАШЛАРЫМ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

*ЗАРИФ БӘШИРИ (1888—1962) — Тукайлар белән бер заманда әдәбиятка килеп, үзенә лаек урынны алган язучыларыбыздан. Ул башлыча шагыйрь буларак танылды, әмма аның иҗатында хикәя, очерк һәм публицистика үрнәкләре дә аз түгел. З. Бәшири аңа замандаш булган күпләгән татар язучыларына хас авыр тормыш мәктәбен үтте. Бу мәктәп татар культурасы өчен янып-көеп йөргән һәм үз халкын чын мәгънәсендә аң-белемле, ирекле итү юлында һәртөрле кыенлыкларны кичергән мәгърифәтче интеллигентны тәрбияләде. Аның бөтен изге максаты ничек тә булса халыкка файдалы хезмәт күрсәтүдән гыйбарәт иде. Шушы максат З. Бәширине дә, аның күпләгән замандашлары кебек үк, социалистик революциягә алып килде.*

*Үзенең кызыклы һәм гыйбрәтле тормыш юлында З. Бәшири татар культурасы дөньясындагы күп төрле кешеләр белән очраша. Болар арасында халыкка танылган эшлеклеләребезнең исемнәрен дә күрергә мөмкин. Бигрәк тә М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Рәмиев, Ш. Камал, Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовлар белән еш кына очрашу һәм аралашулар З. Бәширинең тормыш тәҗрибәләрендә, иҗади ашкынуларында тирән эзләрен калдырганнар. Язучының иң соңгы әсәрләреннән булган истәлекләрендә әнә шул эзләрне бик ачык күрергә мөмкин. Бу әсәр «Замандашларым белән очрашулар» дип аталып, аны Татарстан китап нәшрияты быел бастырып чыгарырга хәзерли. Шушы ук исем белән «Казан утлары»на урнаштырыла торган истәлекләр искә алынган китапның аерым бүлекләреннән гыйбарәт. Боларны матбугатка Г. Халит әзерләде, редакцияләде һәм әдәби яктан эшкәртте.*

**1**

**В**акыт» газетасының чыга башлавына өч ел тулу уңае белән, 1909 нчы ел башларында, кечкенә генә бер җыелыш үткәрелде. Шунда Закир Рәмиев (Дәрдмәнд) мөндыйрак мәгънәдә сөйләгән иде: Үткән елларда «Вакыт» белән «Шура» һәр елны, алтын хисабы белән, ун мең сумга якын зарар күреп килделәр. Бу зарар укучыларның, алдыручыларының аз булуыннан килгән хәл түгел. Безнең укучылар, шактый зур табыш күргән башка газеталарныкына караганда, ике өлеш диярлек күп. Бу зарар безнең газета белән журналның эчтәлеге ягыннан да, техникасы ягыннан да матур иттереп чыгару өчен акчаны кызганмавыбыздан килә.

Закир Рәмиевнең чын мәгънәсе белән аристократ бер шагыйрь, әдәбиятка «сәнгать — сәнгать өчен» ноктасыннан караучылардан булганлыгы билгеле иде. Шулай булуына да карамастан, ул башка язучыларның әсәрләрен үз органнарында бастыруга бер ноктадан гына килми, аларга гонорарны да түбән түләми торган иде. Мәсәлән, ул Тукайны, шигырьләренә юлына 50 тиенгә чаклы гонорар бирү шарты белән, үзлә-

рена эшка чакыра. [Бу чагында бер генә җирдә дә шигырьнең юлына 5 тиеннән артык гонорар түләнми иде.]

Закир Рәмиевнең үзе чыгара торган газета-журнал редакцияләренә килеп-кереп йөргән чагын мин бик аз беләм. Мин шул тирәдә ике елга якын эшләп йөреп тә, аның «Вакыт» редакциясенә килгәнлеген бары бер тапкыр гына күрдем. Шул ике ел эчендә аны нибары өч тапкыр күрергә туры килде.

Закир Рәмиев редакцияләрдә генә түгел, башка җирләрдә дә бик сирәк күренә, үз өеннән рәтләп чыгып йөрми, кеше белән аралашмый торган иде. Әлеге без эшли торган ширкәт членнары еш кына үзара киңәшләр үткәрәләр, ә ул аларга бервакытта да килми, тик аның агасы Шакир Рәмиев кенә килә иде.

Мин Фатих Кәрими һәм Риза Казыйлардан берничә тапкыр аның турында шундый сүзләрне ишеткәнем бар:

— Ул яшьтән үк чиксез дәрәҗәдә өметсезлеккә бирелгән кеше. Шуның өчен дә аның барлык юанычы — үзенең китепханәсендә матур әдәбият укып, язып көнен үткәрүдән тора...

Мин аның белән тик бер тапкыр гына редакциядә очрашып, ун минутлап сөйләшеп утырдым. Ул әкрен, салмак тавыш белән бик аз сөйли, әйтергә теләгән нәрсәсен кыска гына итеп, ике-өч сүз белән генә әйтеп, аңлатып куя торган иде.

Аның сүзләреннән мине беркадәр аптырауда калдырганы: «Шура» журналында басылган шигырьләреңне укып барам», — дигәне булды. Чөнки мин ул чыгара торган журналда эшләгәч һәм шулай ук үзе шагыйрь дә булгач, анда басыла торган шигырьләрне ул үзе карап, үз күзләреннән үткәреп бастыра торгандыр, дип уйлый идем. Шунлыктан мин аңа түбәндәге сорауларны бирергә ашыктым:

— Соң, Закир абзый, сез аларны журналга кермәс борын укымыйсызмыни!

Ул миңа болай дип җавап бирде:

— Журналның җаваплы кешесе бар бит аның! Аңа мин нишләп кысылыйм! Мин дә шулай, башкалар шикелле, аны басылып чыккач кына укыйм...

Ул «Шура» журналының редакцион эшләренә һичбер тыгылмау гына түгел, хәтта үз нәрсәләрен дә Риза Казыйга: «Яраклык итеп тапсагыз, журналга кертерсез», — дип кенә бирә икән.

Шул чорларда «Шура» үзенең укучыларына түбәндәге мөрәҗәгатьне бастырып чыгарган иде:

— Сезнеңчә, иң алдынгы шагыйрьләр кемнәр! Шулардан ике шагыйрьне күрсәтеп язуыгызны үтенәбез.

Моңа каршы Габдрахман Сәгъди:

— Габдулла Тукаев белән Зариф Бәшири, — дип яза.

Закир Рәмиев шул турыда миңа сорау бирде:

— Моңа сез ничек карыйсыз! — диде.

Ләкин мин аның бу соравын аңлап җиткерә алмадым: «Г. Сәгъдинең җавабына ничек карыйсыз!» дип әйтүеме, әллә «Үзегез кемнәрне алдынгы шагыйрьләрдән саныйсыз!» диюе идеме.

Шунлыктан мин, тисә тиенгә, тимәсә ботакка дигәндәй, боларның икесенә дә җавап була алырдайрак иттереп:

— Мин булсам, Тукай белән Дәрдменд дип җавап бирер идем,— дидем.

Ул бераз гына сүзсез торды да:

— Минемчә, Сагыйть Рәмиев булса кирәк! — диде.

Ул Сагыйть Рәмиевне Тукай урынына куеп әйтәме, әллә үз урынына, ягъни Дәрдменд урынына куеп әйтәме! — Мин төшенә алмыйм. Ләкин, һәрхәлдә, шунысы ачык: ул Сагыйть Рәмиевкә зур бәя бирә иде.

Закир Рәмиев белән сөйләшеп утырудан соң берничә көн үткәч, Риза Казый мине үз өенә чакырды. [«Шура» журналының аерым редакциясе юк, аның бөтен эшләрен Риза Казый үзенең өендә алып бара торган иде.]

Ул миңа болай диде:

— Редакциядә бик күп шигырьләр җыелды. Аларның барысын да журналга кертеп бетереп булмый, әлбәттә. Шуның өчен дә, без Закир әфәнде белән сөйләштек тә, аларның яхшыракларын сайлап, аерым бер җыентык чыгарырга булдык. Син, менә шуларның барын да карап чыгып, журнал өчен муафикъ булганнарын сайлап ал әле.

Шуннан мин аңа да Закирга биргән сорауны бирдем:

— Нигә Закир абзый үзе карап, сайлап алмыйммыни! — дидем.— Ул сайласа, белебрәк тә сайлар иде, шуның белән бергә — журналның хуҗасы да ул бит!

Риза Казый үзе дә уңайсызланган рәвештәрәк итеп:

— Закир әфәндедең гадәте дә, карашы да кызык аның, — дип куйды. — Закир әфәнде болай ди ул: «һәрбер әдипнең, һәрбер шагыйрьнең үзенә бер өслүбе, тоткан юлы була. Ә мин, аларның шигырьләрен төзәтәм дип, үземә таба борып җибәрермен дә аларда икеләнү тудырырмын». Менә шуның өчен дә ул кеше иҗатына тыгылмауны артыграк күрә.

Аннан соң Риза Казый, үзеннән өстәп, шуны да әйтеп куйды:

— Ул үз өслүбенә, үз мәсләгенә артык бирелгән мөтәгассип[1] булса да, башкаларга аны йөкләү ягында түгел. «һәрбер шагыйрь, һәрбер әдип бу мәсьәләдә ирекле булырга тиеш!» — ди ул.

Шушы чорларда мин Рәмиевләр белән Фатих Кәриминең бер әдәби журнал чыгару фикерендә булуларын да аңлаган идем. Бу турыда Галиәсгар абзыйдан сорагач, ул:

— Минем белүемә караганда, шулайрак аңлашыла, ләкин аңа муафикъ кешесен таба алмыйлар икән. Шәриф Камал белән Галимҗан Ибраһимовны чакырырга уйлыйлар, имеш, — диде.

Бу чагында мин Галимҗанга чын ихлас, өмет белән карау дәрәҗәсенә килгән булсам да, Шәриф Камалның «Шура» журналында чыккан һәм миңа бик ошаган «Уяну» дигән хикәясеннән башка нәрсәсен күрмәгәнлегемнән, аның турында бертөрле дә төпле карашка ия түгел идем.

— Нинди кеше соң ул Шәриф Камал! Шундый бер журналны алып барырлык өмет күрсәткәне юк ич әле аның, — дидем.

Башта Галиәсгар абзый шаяруга тартып:

— Кем булсын, Пенза мишәрләреннән берәү, — диде. Аннан соң җитди бер төс алып:

— Мишәрен мишәр дә бит, — диде, — ул кеше шул беренче хикәясе белән үк үзенең буш бер мишәр булмаганлыгын күрсәтә. Аның «Вакыт»ка вә «Шура»га тагын да берничә нәрсәсе килгән. Шуларны укыгач, Закир Рәмиев тә аңа зур өмет баглаган. Үз тирәбезгә тартырга, үстерергә кирәк бу егетне, диган. Аның бер кульязмасын мин дә укып чыктым...

Шул соңгы сүзләрне әйткәндә, Галиәсгар абзый канәгатьләнгән төстә башын да чайкап куйды.

## 2

Уфага барып төшкәч тә, мин элекке танышларымнан берсен эзләп таптым да, аның белән Гафуриларга киттек.

Гафуриның ул чакта кайсы урамда, ничәнче номерлы йортта торганлыгын бүген ачык кына хәтерли алмыйм. Тик шунысы гына күз алдымда калган: алар шәһәрнең шактый читендә һәм кечкенә генә бер агач өйдә торалар иде. Аның караңгы, тар гына коридор кебек нәрсәсен үткәннән соң, ишегеннән туп-туры басып-атлап керә алмадык. Башны иеп, бөгелеп керергә туры килде.

Без барып кергәндә, күп булса 7—8 квадрат метрлык бер бүлмәдә, икәвесе бик шәп киенгән, бриллиант кашлы алтын колак алкалар, йөзекләр белән зиннәтләнгән, берсе гади, искерәк кенә күлмәктән булган өч хатын сөйләшеп утыра иде. Мине алып барган танышым гади киемле хатын белән исәнләште дә:

— Мәҗит әфәнде өйдәме! — дип сорады. Әлеге хатын ачык чырай, җиңел хәрәкәт белән урыныннан торды да, үзе утырган утыргычны бушатып, безгә тәкъдим итте:

— Чит кунакны шунда утыртыйк инде!

Аннан соң ул минем танышыма карап көлде:

---

[1] Мөтәгассип — фанатик.

— Сезгә, Мәҗит баеп, яңа урындыклар алгач, утырырга тәкъдим итәрбез: хәзергә гаепкә алмагыз инде.

Шундый тәкәллефсез, садә, шат күңелле, ачык чырайлы бу хатын миңа шулчаклы ошады, хәтта мин, үземнең өйләнү нияте белән йөрүемне искә алып, эчемнән генә: «Иптәшең менә шундый булса, дөньяда яшәвең дә урынсыз булмас иде», — дип куйдым.

Без кергән кечкенә бүлмәнең уң ягында әлеге коридордан тар гына, тәбәнәк кенә тагын да бер ишек урыны бар иде. Ләкин ишек үзе юк, аның урынына шактый искереп, сизрәгән бер чаршау кебек нәрсә эленеп куелган. Әлеге садә киемле хатын шул якка табан карады да:

— Гафури! — дип кычкырды. — Сиңа тагын да кунаклар. Ләкин болары ир затыннан. Багажлары булмаса да, чит шәһәрдән!

Күп тә үтмәде, тар ишеккә корылган чаршау сымак нәрсә күтәрелде дә тәбәнәгрәк буйлы,ябык, чандыр, ләкин җитди чырайлы, сирәк кенә, нечкә кара мыеклы берәү күренде. Аның өстендә, искерәк кенә булса да, ак яка белән кара галстук һәм соры костюм, башында кара хәтфә түбәтәй иде. Мин, аны күргәч тә, Хәбиб Исхакыйның тасвир итүенә таянып, бу кешенең Мәҗит Гафури булуына ышандым һәм шунда ук урынымнан тордым да, «безне син таныштыр инде» дигәндәй итеп, мич янында басып торган әлеге иптәшемә карадым. Ләкин тар ишек арасында күренгән кеше без торган бүлмә ягына чыкмастан туктады да иң элек үткен күзләре белән бер миңа, бер минем иптәшемә сынаган, танырга теләгән рәвештә карап алды. Аннан соң бераз гына елмайды да:

— Әһлән вә сәһлә! [1] — дип куйды.

Мине ияртеп алып килгән танышым көлемсерәп, миңа карата ишарә ясады да:

— Менә кунак алып килдем сиңа, — диде. — Зариф әфәнде Бәшири!

Теге кеше дә матур гына елмаеп, бер аягын без торган бүлмәгә чыгарды да миңа табан кулын сузды:

— Алайса, танышып алыйк инде, мин Мәҗит Гафури булам!

Мин аңарга үзебез торган бүлмәгә бөтенләй чыгып җитәргә ирек бирмәдем, зур гына бер адым ясадым да кулыннан кысып тоттым:

— Мәҗит!..

Мин, шатлыклы тойгылар белән дерелдәп каушаганлыгымнан булса кирәк, «Мәҗит!» дип кычкырып җибәргәнлегемне үзем дә сизми калдым. Хәтта «агай» дигән сүзне өстәүне дә исемә китерә алмаганмын.

Мин бүген үзенең иҗаты белән башлап кулыма каләм тотуыма көч, батырлык биргән остазымның кулын кысам!

Исемен әйтү белән генә булса да, аңа булган бетмәс-төкәнмәс хөрмәтемне белдерәм! Мин шулай, йөрәгемнең иң тирән җирләрендә аңа карата сакланган бөек ихтирам аркасында, әлегә чаклы аның гадәтен, табигатен сынап белмәгән булуымнан каушап, тагын нинди дә булса бер сүз әйтергә белми аптырап калдым.

Ләкин Мәҗит абзый мине шушы аптыранып торудан үзе коткарды. Ул мине әлеге гади хатын белән:

— Танышыгыз, менә бу минем иптәшем — Зөһрә була! — дип тәкъдим итте дә көлеп куйды: — Безгә кияү булачак шагыйрь. Уфаның кызлары тартмаса, кем белә, бәлки, Уфага әйләнеп тә карамас иде! [Уфага килүемнең бер серен кайбер танышларым Гафурига да әйтеп куйганнар булса кирәк.]

— Кем белә инде аны — кызлар тартканмы, сезләрме!..

Татар һәм башкорт язучыларының иҗатларыннан иң элек минем кулыма килеп кергәне Гафури әсәрләре булса да, аларның үзләре белән күрешеп, танышуда иң соңга калганы да ул булды дияргә мөмкин. Гафури белән күрешүдән элек мин, Шәриф Камалдан башка, Сәгыйть Рәмиев, Габдулла Тукай, Нәҗип Думави, Миргазиз Укмасый, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдмәнд һәм Фатих Әмирханнар белән танышкан идем инде. Шунлыктан мин, Мәҗит белән күрешкәч тә, иң элек шул турыда әйтеп алдым.

Ул күңелле генә итеп елмайды да: «Кыргыз, казакъларда «арткы төянең йөге авыр

[1] Гарәпләрдә хуплап каршы алынган кешегә әйтелә торган сүзләр; «Хуш килдегез!» мәгънәсендәрәк.

була» диган бер мәкаль бар. Шуның шикелле, соңга калып көрәшүебезнең дә нәтиҗәсе, мәгънәсе тирәнрәк булыр», — диде.

Шул вакытында чаршау корылган тар ишек арасында тагын да бер гәүдә күренде. Озын буйлы, тыгыз, таза бәдәнле, тулы, ак чырайлы бу кеше, ишеккә кысыла-кысыла, азап белән генә чыккандай булып, без торган бүлмә ягына атлады да әллә кайчангы таныш сыман миңа карап елмайды:

— Исәнмесез, Бәшири әфәнде!

Аннан соң ул өстәл янында утырган хатыннарга күз кырые белән генә карап алды да:

— Без инде сине күптән Уфа кияве хисабына теркәп куйганбыз, — диде. — Чөнки безнең Уфа кызлары салкын инәдән бармакларына суык тидерүче кызлар түгел, тормыш кызлары!..

Мәҗит Гафури да ханымнарга күз ташлап алды да аз гына көлеп куйды.

— Тукта әле син, Хәлим әфәнде, мин бит сезне таныштырганым да юк! — диде, теге таза гәүдәле кешегә карап, һәм аны миңа тәкъдим итте.

— Зыялыларыбыздан Хәлим әфәнде Искәндәров. Галимҗан Ибраһимовның якын дусларыннан булган Галия шәкерте!

Боларның шулай тәкәллефсез сөйләшүләре миңа да үземне тартынмыйчарак тоту батырлыгын бирде. Шунлыктан мин:

— Менә кызык тагын, — дидем. — Сез мине бердән Уфа кызлары белән атаковать итеп алдыгыз. Бәлки, сезнең кызларга өйләнеп баҗа булуга караганда, каләм аркылы әдәбият дөньясында баҗа булу теләге ныграк тарткандыр!

Минем шул сүзләремнән соң Зөһрә ханым, аз гына авызын турсайтып, шелтәле рәвештә Мәҗиткә карады:

— Кызык син, Мәҗит, — диде ул. — Берәүнең табигатен, әхвәле рухиясен белмәс, аңламас борын, танышыр-танышмас, бозга-тузга язмаган сүзләрне сөйлисең!

Зөһрәнең бу сүзләре бер яктан караганда — Мәҗиткә, икенче яктан караганда — миңа тартым аңлашыла иде.

— Зарар юк, — диде Мәҗит. — Без монда шагыйрь дә, хикәя дә язмыйбыз. Кешене әнисеннән-җебенә кадәр өйрәнү әнә шунда гына бик кирәк ул! Ә инде дусларча танышканда, «җырның җыртыгы юк» дигәндәй, уен-көлкенең һәммәсе дә бата...

Өстәл янындагы урындыкларга утырган әлеге ике хатыннан тыш, аягүрә басып торучы без биш кеше белән бүлмәнең эче бөтенләйгә тулып киткән иде. Мәҗит Гафури бер безгә, бер Зөһрәгә карап алды да:

— Кунакларга урын тәкъдим итәргә иде, — диде. Аннан соң, кәефсезләнгән рәвештә, әлеге хатыннарга карады:

— Гафу итегез, ханымнар! — диде ул аларга. — Без мөһим бер эш белән мәшгуль булганлыктан, сезнең янга тиз генә чыга алмадык, сезне бераз көтәргә мәҗбүр иттек. Йомышыгыз миндә булса кирәк!..

Ләкин Зөһрә ханым теге хатыннарга бердән сүз ачарга ирек бирмәде:

— Шулай инде ул, безнең Гафури артыграк мәшгуль кеше, — диде. — Әле менә бүген үзенең имениесеннән доверенный килгән дә, иртәдән бирле аңардан исәп-хисап алып, имение хәлләрен сорашып утыра, — дип, шаярулы һәм кинаяле сүзләр ташлады.

Миңа билгесез хатыннарның берсе, пудралы яңакларында аз гына алсулык билгесе күрсәтеп, урынында утырган килеш кенә:

— Сезгә зур гына бер йомыш белән килгән идек шул, Мәҗит әфәнде, — диде. — Уфадагы мөслимәләр җәмгыяте исеменнән мөфти хәзрәтне котлап, аңа бүләк һәм адрес тәкъдим итәргә булган идек. Җәмгыятьнең рәисәсе Мәрьям ханым Солтанова, котлау сүзләрен шигырь белән язып бирүне сорар өчен, безне сезгә җибәргән иде!

Икенче ханым аңа ялгады:

— Язу хакын тулы итеп түләрбез, Мәҗит әфәнде!

Мәҗит, башта әллә ничек хурланган, кимсетелгән төс белән, аска карап торды да, аннан соң безгә бераз елмаеп, ә тегеләргә иронияле тон белән:

— Йомышыгыз да, шулай ук хезмәтегез дә шактый зур икән шул, — диде. — Ләкин, хезмәт хакын тулы итеп түләргә вәгъдә бирүегезгә дә карамастан, мин бу «бөек хезмәт»не үти алмавымны белдерергә мәҗбүрмен, чөнки миндә андый «зур кешеләргә» карата шигырь язарлык талант та, илһам да, сәләт тә юк!..

Аның бу соңгы сүзләрне әйткән чагындагы тавышы аерата мыскыллы булып яңгырады. Ләкин теге хатыннар моны аңлап җиткерә алмадылар булса кирәк, чөнки аларның берсе тагын да кабатлады:

— «Илһам» дип ни, аңа әллә нинди озын шигырьләр кирәкми инде.., 10—15 юл җитә... Язу хакына килгәндә, без анысын кызганмабыз...

Бу сүзләрдән соң инде Мәҗит Гафури үзенең хурланулы ачуын яшереп тора алмады. Үткен күзләрен ялтыратып, тегеләр өстенә ташлады да:

— Шигырь базарда сатыла торган чабата түгел ул! — диде, коры гына иттереп. — Аны заказ буенча гына тукып булмый!

Шуннан соң теге ханымнар да инде, эшнең барып чыкмаячагын аңлап булса кирәк, пошынган рәвештә урыннарыннан кузгалдылар.

— Алай булгач, яза алмыйсыз була инде!..

— Юк! — диде Мәҗит, тагын да катырак итеп.

Тегеләр ишектән чыгып барган чагында, тагын да әйтеп куйды:

— Илһамсызлыгым аркасында зурларның кадерләрен белә алмавым өчен, мөхтәрәмә хатыннар мине гафу итсеннәр!..

Мәҗит Гафуриның бу сүзләре миңа һич көтелмәгәнчә нык тәэсир итте...

Юбилей хакында фикер алышулар шактый озакка барды. Кыскасы, Мәҗит тә, Галиәсгар абзый шикелле үк, аннан халык өчен берәр файдалы эш чыгуына һич тә ышанмый иде.

— Мөфти бит ул тәхет чүпрәге, патша лакее,— диде.— Аннан Россия мөселманнарына зарар гына килде. Үзе шундый булдыксыз тагын, шундый булдыксызлыгы аркасында, үз намусын саклауның да нәрсә икәнлеген аңламый...

Мөфти Мөхәммәдъяровның шушы юбилее башланганнан алып, аның азагына кадәр Мәҗит Гафури аңа багышланган бер генә җыелышка да бармады һәм бер генә сүз дә язмады. Хәтта үзара сөйләшеп утырган чакта, юбилей турында сүз чыкканда да, ул кулын селтәп:

— Ташлагыз әле шул юк-бар нәрсә турында вакыт әрәм итеп лыгырдавыгызны! — дип кенә куя иде...

Мәҗит Гафуриның тормышы материаль яктан шактый начар булганлыгын мин беренче күрүдән үк аңлап алдым.

Аның зал урынын тоткан 7—8 квадрат метрлык бүлмәсендә, иске, хәтта буялмаган бер өстәл белән өч урындыктан башка, күзгә күренерлек бер генә нәрсә дә юк.

Икенче кабат баруымда мин моны тагын да ныграк сиздем. Алар, Зөһрә белән икәү, аркылысы-буе күп булса өч-дүрт метрдан торган аш бүлмәсендә ашап утыралар иде. Шунлыктан мин туп-туры әлеге зал урынын тоткан бүлмәгә үттем дә аларның ашап бетерүләрен көтеп утырдым. Бераздан Мәҗит уенлы-чынлы сүзләр белән минем яныма чыкты:

— Ун көннән бирле шулпалы аш ашаганым юк иде. Бүген токмачлы ит шулпасы чөмердем, малай!

Аның артыннан, кечкенә Әнвәрен күтәреп, ачык чырай, шат йөз белән Зөһрә ханым да килеп керде.

— Ярый әле, син булып чыктың. Ишек каккач, галияләләр килеп калдымы әллә дип шөбһәләнгән идем...

Мәҗит мәдрәсәи Галия шәкертләре белән нык аралаша. Алар Мәҗиткә зур хөрмәт күрсәтәләр, һәрвакыт аның янына киләләр, төрле мәсьәләләр турында фикер алышалар.

— Галия мәдрәсәсенә, — ди Мәҗит, — Россиянең бөтен җиреннән иске тормыштан, иске мәдрәсә тәртипләреннән риза булмаган шәкертләр җыела.

Менә шуңа күрә дә Гафури Галия шәкертләре белән аралашудан, алар белән фикер алышулардан үзе өчен зур ләззәт һәм җан азыгы таба икән.

— Анысы шулаен шулай, бик әйбәт эш тә бит, — ди Зөһрә, — ләкин атна-ун көнгә бер тапкыр пешерелгән аш өстенә туры килсәләр, һичбер тартынып-нитеп тормыйлар инде алар. Табакның төбенә кадәр ялтыраталар!

Ләкин Мәҗит моңа да, һич пошынмастан, көлә генә:

— Нишлисең бит, — ди, — татар шәкерте һаман да ач инде ул... Шәкерт чагымда

мин үзем дә шулай идем. Менә шуңа күрә дә татар шәкерте тынгысыз: ул яңалыкка юл эзли, шуңа омтыла, ач торып булса да, файдалы белем алырга тырыша!

Зөһрә дә үртәнеп көлә:

— Мәҗит шәкерт чагында ач булган да, ә хәзерендә бик шәп, шундый тук инде, тәмам артып, ташып тора, — ди.

Сүз бара-тора аларның нинди килер хисабына яшәүләренә күчте. Мәҗит әйтә:

— Нинди килер, шул гонорар инде, — ди.

Елына ике яисә өч китабың басылып чыга икән, алардан бик күп булса 25—30 сум гонорар аласың. Ул заманда китапны договор белән бастыру һәм табак яисә юл башыннан гонорар бирү дигән нәрсә юк иде. Китапны бастыручы бай-сәүдәгәр китапка хакны үзе теләгәнчә билгели.

— Ярый инде, сигез сум бирермен, — ди. Тарткалаша торгач, бер китапка ун сум биргән чаклары да була. Янәсе:

— Ярый инде, монысы синең хакка гына!

Шуннан ул моны да өстәп куя:

— Без синең китапны бастырабыз икән, сиңа шөһрәт бит, әфәндем, шөһрәт! — ди.

Аңа риза булмыйсың икән, нашир әфәнде китабыңны алдыңа гына төртә:

— Ярый инде алайса, башка нәшриятларга биреп кара! — ди. Ә аның башкалары да бер чыбыктан сөрелгәннәр. Газета-журналларның күбесендә гонорар бөтенләй бирелми.

Шуңа да карамастан, Мәҗит бервакытта да тормышыннан зарланмый, рухын төшерми, иҗат эшенә кимчелек китерми, үзенең намусын җуеп, байлар алдында ялагайлык итми. Бу турыда ул шундый бер хәлне дә сөйләп алды.

Бервакытны аптырауда калгач, Мәҗит Уфаның шактый зур байларыннан саналган һәм үзен һәрвакыт мәгърифәтчел, прогрессчы итеп күрсәтергә тырышкан Шәмигуловка бурычка ун сум акча сорап бара. Ләкин Шәмигулов ни өчендер шул көнне бирми һәм «бирмим» дип тә әйтми., Ул бераз гына уйланып тора да:

— Ярый, Мәҗит әфәнде, карап карарбыз, иртәгә сәгать уннарда килерсез, — ди. Икенче көнне баргач, байтак кына көттереп, арлы-бирле йөри дә Мәҗит алдына ун сум акчаны китереп куя.

— Ярый, Мәҗит әфәнде, моны бурычтан санамабыз инде, һибәдән[1] булыр! Сез дә минем милләт хадимнәренә[2] булган ярдәмнәремне онытмассыз инде, — ди.

— Анысы инде сезнең үз эшегез!

Шуннан соң Мәҗит әлеге ун сумны Шәмигуловның алдына куя да сүзсез генә чыгып китә һәм шушы вакыйгадан соң, ачка үләрлек хәлгә килгәндә дә, байлар алдына бармас була.

Тормыш турында Мәҗит болай ди:

— Алай бик үк аптырап калганыбыз юк әле. Үзем язгалыйм, Зөһрә дә эшләштергәли. Шулай итеп, үз көчебез белән матур, тыныч тормыш алып барабыз. Элеккеләр «мал гарипкә тансык» дигәннәр. Үз көчең белән көн итүнең шунысы әйбәт икән: берәү дә синнән зарланмый, эш хакымны тулы бирмисең, дими. Син дә: «Ай, болар хыянәт итмиләр микән, мине дошман күреп, зарар итәргә йөрмиләр микән!» — дип хафаланмыйсың. Дөрт ягың кыйбла, мин сиңа әйтим!

Мәҗит үзенең иптәше Зөһрәдән риза булганлыгын да белдереп куя:

— Тормышның авырлыгын күбрәк ул күтәрә: кешегә кер юып, тегү тегеп булса да, тормышның ертык-сүтекләрен каплый. Ул бервакытта да: «Тегене китер, моны ал, тегесе юк та бусы юк!» — дими. Кайвакыт юклык сәбәпле күңелсезләнгән чакларда да уен-көлке, әллә нинди өметле карашлар белән сине юатып, күңелне күтәреп куя!

Мин Мәҗит Гафуриның Зөһрәдән чиксез риза булганлыгын аның үз сүзләреннән генә түгел, Зөһрәнең Мәҗиткә булган мөнәсәбәтеннән дә аңладым. Шулай ук моны башка чакларда да нык сиздем. Зөһрә — Мәҗит Гафури өчен чын бер иптәш, аның рухын, әдәби зәвыгын күтәрүче һәм аның иҗади хезмәтен аңлый торган ихлас ярдәмчесе иде. Ул Мәҗитне тормыш юлдашы иттереп кенә түгел, иҗат кешесе буларак та хөрмәт итә, аны тәрбияли, юк-бар сораулар белән борчымый, аның уен-фикерен әдә-

---

[1] Һибә — бүләк.

[2] Милләт хадимнәре — милләт файдасына тырышучылар.

биаттан башка якка юнәлдермәс өчен, юкны бар итәргә, барны тота белергә тырыша иде.

Уфага шушы беренче килүемдә мин Мәҗит Гафури һәм Зөһрәләр белән нык аралашып, тәмам үзләшеп беткәннән соң, шундый авыр тормышта булып та, Зөһрәнең һаман шат, күтәренке күңелле, уен-көлке сүзле булуы турысында аның үзенә дә әйтми кала алмадым. Ул шаркылдап бер көлде дә:

— Нигә күңелне төшереп торырга! — диде. — «Өметсез шайтан!» дигәннәр. Без бит әле өметсез шайтаннар түгел...

## 3

Мөфти юбилее тәмам булгач, берничә көн Уфада тордым да Казанга кайтып киттем.

Казанга кайтканның өченче көнендә миңа көтмәгән җирдән агасы Шакирҗан белән Галимҗан Ибраһимов килеп керде.

Бу юлы Галимҗан, беренче танышкан чактагыга караганда, өс-башы, төсе-чырае ягыннан да беркадәр үзгәргән иде. Чыраенда яхшы гына тулылану күренә, җилкәсенә әлеге кара тужуркасы өстенә кара накидка салган, шома гына күн итек кигән. Кулында да кыскарак кына калын таяк. (Бу заманда интеллигенция арасында кулга таяк тотып йөрү модага кергән иде.)

Ул, килеп кергәч тә, әллә кайчангы таныш кешедәй:

— Я, ниһәл, исән-сау йөреп килдегезме! — диде дә, кул биреп-нитеп тормастан, өстәл янындагы урындыкка утырды.

— «Болгар» номерларының ишеге алдыннан үтеп бара идек, швейцар кычкырып туктатты да: «Сорап йөргән Бәшириең килде әнә!» — диде. Шул сүзне ишетүгә, тоттык та баскычтан үрмәләдек.

Шуларны әйтте дә ул бердән сораша башлады:

— Уфа ничек, ошадымы үзеңә, анда барудан берәр файдалы эш чыктымы, Мәҗит Гафури ниһәлдә!..

— Уфа ошадымы дип, аны кайсы ягыннан тотып әйтергә соң! Табигать матурлыгы ягыннан дисәң, аның мактап телгә алырлык урыннары күп инде, әлбәттә. Агыйделнең текә ярлары өстенә тезелгән, һәр яктан диярлек агым су белән чорналган Уфа шәһәренең һавасы җиңел, саф, тирә-ягы шикелле, шәһәрнең эче дә яшеллеккә бай...

— Ә халкы, бигрәк тә зыялылары!

— Халкы дип, бер җирдә дә халык бертөрле булмый инде ул, төрлесе була — яхшысы да, яманы да. Тулаем әйткәндә, Уфа интеллигенциясе арасында садәлек, ихлас күңеллелек, эчкерсезлек күренеп тора. Барыннан да бигрәк, интрига дигән нәрсә юк, шунлыктан алар белән бик тиз аңлашып, үзләшеп, дуслашып була.

Шуңа мисал итеп, мин берничә хәлне дә сөйләп алдым:

— Уфага барып төшкән көндә үк мин үзем туктаган «Нур» номерларының аш-чәй залында Галия шәкертләреннән берничәсе белән очрашып калдым. Шулар арасында Фәхри Әхмәдиев белән Әмин Зөбәеров та бар иде. Шул көнне Уфада Галия шәкертләре, приказчиклардан Мохтар Мутин һәм Фәттах Латыйповлар тарафыннан оештырылган театр уйналачак икән. Кич якынлашуга әлеге Галия шәкертләре, театрга билет алып килеп, син безнең шәһәрнең кунагы дип, мине култыклап та киттеләр.

Мин шуларны сөйләгән чагында, ризалык белдереп, кәефләнгән төс белән тыңлап утырган Галимҗан:

— Әйе, «интрига юк» дисең... Иң мөһиме дә әнә шул инде аның, — диде. — Әнә шул яклары белән Уфа миңа ошый да!

— Ә Казан!

— Ул яктан Казан зыялылары арасында мохит шактый күңелсез. Интригалар да җитәрлек...

— Хәзер сез даими рәвештә кайда торасыз!

— Күптән түгел генә Казанга килеп урнаштым һәм берничә еллар шунда булырмын дип уйлыйм.

— Үзегез Казанның мөхитеннән зарланасыз, Уфаны мактыйсыз. Шулай булгач, тормыш өчен нигә Казанны сайладыгыз!

— Мин үзем дә бу турыда байтак кына баш ваттым. Уфа миңа, әнә шул син әйткәнчә, табигый садәлеге, халкының эчкерсезлеге белән никадәр ошаса, ул миңа ватаны асли [1] булу ягыннан да бик якын... Ләкин, ничә әйтсәң дә, Казан Казан бит инде ул!.. Ул тарихи бер шәһәр, Казанда мәдәният мәйданы киң, аның университеты, аның меңләгән студентлары, профессорлары, гыйлем, фән әһелләре бар. Казан — татар матбугаты һәм әдәбиятының үскән, киңәйгән мәркәзе. Казанда эшләр өчен дә, матбугат вә әдәбият дөньясында тәҗрибә алу өчен дә мәйдан киң!.. Мин бит әле үземнең җиң сызганып, бил бәйләп эшли торган дәверемә килеп җитмәгәнмен. Берничә тапкыр миңа Рәмиевләрнең матбугат ширкәте дә Оренбургта бер әдәби журнал оештыру турында тәклиф ясады. Ләкин мин аны да кабул итмәдем. Казанны сайладым. Шуның белән бергә мин Агыйдел, Урал буйларын, үземнең Урал баласы булуымны да онытмыйм һәм аны онытачак та, истән дә чыгарачак түгелмен. Килер бер көн, һәрхәлдә, мин Уфага кайтып эшләрмен...

Мин аларга, Уфага барып, анда төрле кешеләр, бигрәк тә Мәҗит Гафури белән танышуымны, яшьлек хатирәләремне яңадан тергезүемне сөйләдем. Мәҗит Гафуриның материаль яктан авыр хәлдә яшәвен, шулай булуына да карамастан, бернәрсәгә дә исе китмәвен, рухын төшермәвен, зарланмавын, үзен нык саклавын сөйләгәч:

— Мәҗит бер ягына суксаң — икенчесен куярга тора, — диде Галимҗан. — Үзенең шәхси тормышына килгәндә, һичбер төрле дә әрсезлек юк аңарда. Әле ярый, бәхетенә Зөһрә шикелле хатын туры килгән үзенә. Күпләр көндезен шәм яндырып эзләсәләр дә таба алмаслар иде андый хатынны. Әнә бит Тукай да, шуннан куркып, өйләнү дигән нәрсәдән ваз кичкән. Ярый ла хатының атыңа охшаган булса; әгәр инде морҗадан чыгып качарлык шайтанны да койрыгыннан элэктереп ала торганы туры килсә, каләмеңне кабереңдә кочаклап ятырга гына кала!

Сөйләшә торгач, Галимҗан әле һаман да кулында тотып торган таягын стенага сөяп куйды. Аннан соң накидкасы белән эшләпәсен салып элде дә, озын кара чәчләрен тарап, артка әйләндереп сала-сала:

— Без кунакка килдек, ә син безне һаман да коры сүз белән сыйлыйсың, — диде.— Кайда, берәр самовар чәй әйтергә исәбең бармы!..

Чәй хәзерләнгәнче дә, чәй эчкәч тә, безнең арада гел уен-көлке сүзләр барды.

Мин ике ел буенча Галимҗан белән аралашып та (бер кроватьта йоклаган чаклар да аз булмады), аның шаркылдап, кычкырып көлгәнен күрмәдем.

Ул кыргыз, казакълар тормышыннан байтак кына кызыклы мәзәкләрне сөйләде дә:

— Бу халык шулкадәр үткән, зирәк вә сүзгә тапкыр, — диде, — аларның гади генә бер көтүчесе дә гади генә бернәрсәне сөйләгән чагында да аны шигырь-бәет иттереп сөйли ала...

Шушы беренче утырышудан соң Галимҗан, көн саен диярлек, миңа керә торган булды. Күп вакытта ул үзе белән бергә Шәһит Әхмәдиевне дә алып килә иде. Аны минем белән:

— Бу кеше Оренбургта Вәли хәзрәт мәдрәсәсендә бергә укыган һәм шундагы ихтилалларны [2] кузгатып йөргән «Зәки шәкерт»нең берсе, минем ахирәтем, — дип таныштырган иде. — Чыгышын сорасагыз — Чистай хәерчесе!

Мин алар белән ике елдан артык аралашып йөргән дәвердә, чынлап та, аларның ихлас дуслыкларын һәм моның нигезендә яткан сәбәп — аларның карашлары бертөрле булуы икәнлеген аңладым. (Алар Октябрь революциясенә дә әнә шулай килделәр.) Бик күп мәсьәләләрдә Галимҗан Ибраһимовлар белән килешә алмаган Фәхрелислам Агиев кебекләр, алар турында сүз чыккан чагында:

— Ике саяк-сандырак! — дип кенә куя торганнар иде. Ләкин алар икәү генә түгел, мондый «саяк-сандырак»лар Галимҗан тирәсендә шактый гына булды.

Ул чорларда Казан татар яшьләре-укымышлылары арасында берничә төркем барлыгы бик сизелә иде.

---

[1] Ватаны асли — төп туган-үскән җир.
[2] Ихтилалларны — революцион хәрәкәтләрне.

Бу төркемнәр, болай тыштан карaганда, ниндидер бер политик нигезгә корылган кебек күренмиләр. Алар ачыктан-ачык бер-берсенә каршы гайбәт сату кебек нәрсәләрне дә күрсәтмиләр, үзара барышып-килешеп йөриләр, утырышалар, сөйләшәләр, әйтерсең лә, алар стихияле рәвештә генә бер-берсе белән танышып киткән гади дуслар!.. Мин шулайрак аңлый идем аларның үзара мөнәсәбәтләрен.

## 4

1911 елның август башларында шикелле, мин беренче тапкыр Галимҗанның квартирасына бардым. Квартира дип, квартира да түгел инде аның торган җире. 7—8 квадрат метрлык кечкенә генә бер бүлмә шунда.

Ул чагында Казанның Болак һәм Кабан күленең Кремль ягы бөтенләе белән «руслар ягы» дип йөртелә иде. Анда өй яисә квартира тотып, гаилә белән яшәүче татарлар бөтенләй юк диярлек. Тик чит шәһәрләрдән килеп, вакытлы торган берлеярымлы яшьләр генә шундагы руслардан аерым бүлмә алалар. Галимҗан да Кабан күленә якын гына бер рус өендә бер бүлмәгә урнашкан иде. Мин, барып кергәч тә, иң элек:

— Күпме түлисең бу бүлмәгә! — дип сорадым.

— Алты сум, — диде Галимҗан. — Татарлар торган якта мондый бүлмәне дүрт сумнарга да табып була булуын да, ләкин мин, кесәмә авырлык килсә дә, рус арасында торып, русчамны үткерләтү өчен, шунда яшәргә булдым.

Аның бүлмәсендә искерәк кенә одеал белән бер мендәрле тимер кровать, буялмаган агач өстәл белән ике урындыктан башка нәрсә юк иде.

Аның өстәле өстендә бармак төртерлек тә ачык-буш җир күренми. Өстәлнең ике башына китаплар, кульязмалар өелгән. Урталыкта эреле-ваклы төрле кәгазьләр чәчелеп ята. Мин өстәл янындагы урындыкка барып утыргач та, әнә шул кульязмаларга күз ташладым.

Нинди кәгазь туры килсә, шуңа язылган кульязмаларны күргәч, минем исемә бер хәл килеп төште.

Бервакыт мин Оренбургта чагымда, «Шура»да бастыру өчен, Риза Казыйга бернәрсә биргән идем. Ул аны кулына алгач көлеп куйды:

— Үзең, Америка язучылары шикелле, нинди кәгазь туры килсә — шуңа язгансың икән.

Шуны исемә алдым да, эчемнән генә:

— Әллә чынлап бөтен Америка язучылары да шулаймы икән, Галимҗан да шуларга охшарга телиме икән! — дип уйладым. — Кем белә, бәлки шулай да булыр...

Мин Риза Казыйның әлеге сүзләрен әйттем дә:

— Чынлап та, әллә син дә шуларга нярәсеңме! — дидем.

Галимҗан башта, моңа җавап бирмәстән, түбәндәгечә сөйләп китте:

— Берәр хикәя кебек нәрсәне язар алдыннан, мин иң элек үземнең күз алдымнан үткән вакыйгалардан, фактлардан чыгып, шул язачак нәрсәмнең эчтәлеген планлаштырам. Аннан соң аның склетын эшләргә башлыйм. Шул ук вакытта яңадан искә төшкән яисә шул чагында күзгә күренгән һәм кемнән дә булса ишеткән яраклы-кирәкле, ләекле булган вак кына нәрсәләрне, материалларны аерым кәгазь кисәкләренә яза барам. Склет тәмам булгач, аны шул кәгазь кисәкләренә язып барган нәрсәләр белән тулыландырып, сиплап, яңадан эшләп чыгам. Әнә шулай кечкенә генә бер скелеттан зур, тулы, бөтен бер нәрсә пәйда була!

Иҗат эше гаҗәп бер нәрсә бит ул, — ди Галимҗан. — Син башта үзең ясаганүйлаган план белән берәр нәрсәне яза башлыйсың. Ләкин, яза торгач, синең әлеге планың белән андагы фактлар, вакыйгалар башлангыч юл яисә беренче маяк булып кына калалар. Ә кайчагында бөтенләй әһәмиятләрен дә югалталар. Чөнки язган саен, синең күз алдыңда әллә кайчангы истәлекләрдән калган тәэсирләр бер-бер артлы яңадан җанлана башлыйлар. Менә шулар өстенә күз алдыннан үтеп торган бүтән хәлләр дә килеп кушылалар, синең дикъкатеңне чорнап алалар. Шулай итеп, синең аның кинәя, тармаклана, тормыш эченә яңадан кереп китеп, эзләнергә мәҗбүр була. Әнә шул рәвешчә синең иҗади эшең үзенә көч җыя, синең эшеңә тулы бер нәтиҗә

бирә. Менә мин хәзер «Яшь йөрәкләр» дигән бернәрсә язып ятам. Минем планым буенча, ул күп булса 40—50 битлек хикәя сыман нәрсә булырга тиеш иде. Ләкин инде ул зур бер повесть яки роман төсен алып бара. Әнә шул чәчелеп яткан вак кулъязмалар, кәгазь кисәкләре аның мөндәриҗәсенә кереп бетәчәкләр.

Шуннан соң ул әлеге Риза Казый сүзләренә бәйләп сөйли башлады:

— Мин Америка язучыларының нинди кәгазь туры килсә, шуңа язулары турында бернәрсә дә белмим. Әмма мин шуны әйтергә телим: төрле язучыда төрле гадәт бар. Мәсәлән, Көнчыгыш сарай шагыйрьләренең берсендә шундый гадәт булган, диләр: ул, бераз язган саен, иягендәге сакалының бөртекләрен йолкып ала икән. Хан моның белән кызыксына да аңа боерык бирә: «Менә шул турыда бер шигырь яз, ләкин сакалыңа кагылма!» — ди. Шагыйрь утыра да утыра, ләкин барып чыкмый, баш эшләми. Бармакларны сакалга табан суза башлады исә, хан боерыгы җибәрми.

Иң азагында шагыйрь ханның алдына тезләнә:

— Юк, ханым-солтаным, — ди, — башымны киссәң дә, мин сакалымны йолкымый торып, иҗатымны башкара алмыйм!..

Галимҗан тагын да үзенә таныш бер язучының гадәтләре турында сөйләп китте:

— Иҗат эшенә утырган чагында, ул язучының язу өстәлендә җыйнаклык, пөхтәлек булса да, язу эшеннән тукталганда инде аның өстәл өстен дуңгыз аунагандай бер хәлдә күрәсең. Хәтта аның язылган кәгазь кисәкләре дә төрлесе төрле җирдә чәчелеп, буталып беткән була. Ул аларны соңыннан көч-хәл белән җыеп алып тәртипкә сала. Бу нидән шулай!.. Чөнки ул, үзенең бөтен күңелен, уен, дикъкатен салып, артык бирелеп язганлыктан, күп вакытта каләмен, кара савытына манам дип, шап иттереп өстәлгә китереп тә кадый яисә кара савытын төртеп аударып та җибәрә. Каләмен чамалап мануга игътибар итмәгәнлектән, каләмгә артык күп сыланган кара өстәл өстенә дә тама. Яза торгач, шулчаклы мавыгып, кызып китә, язылып туктаган кәгазьне бер кырыйга этеп кенә җибәрә дә тиз генә икенче кәгазьне — нинди туры килсә, шуны эләктереп-тартып ала, ә теге этеп җибәргән кәгазь бер читкә очып китә.

Бервакытны шундый бер хәл була: ул бер журнал өчен очерк яза һәм язып бетергәч тә, аны яңадан карап, укып-нитеп тормастан, редакциягә җибәрә, аннан типографиягә китә. Типографиядә җыелып, корректурасын укый башлагач, корректорлар очеркның урта бер җирендә аптырап калалар: сүзләр дә, җөмләләр дә, әйтергә теләгән фикерләр дә бер-берсенә ябышмый. Аптырагач, редакторга күтәреп киталәр. Ул да укып карый:

— Юк, ябышмый, бернәрсә дә аңлашылмый! — ди.

Иң азагында язучының үзенә баралар. Ул үзе дә, укып карагач, хәйран була:

— Арадан берәр кәгазь кайда да булса төшеп калгандыр яисә берәр җирдә буталып ята торгандыр, — ди ул. — Эзләргә, табарга кирәк!

Эзлиләр, редакциядән дә, типографиядән дә, язучының өстәл өстендәге кәгазьләр арасыннан да эзлиләр, ләкин табылмый.

Шуннан берничә вакыт үткәч, теге әдип язу өстәленә җәелгән кәгазь урынына башка бер кәгазь җәеп куярга була. Шул чагында аның күзләре өстәлгә җәелгән кәгазьдәге язуларга төшә. Я хода, үз язуы икән! Әлеге очеркны язган чагында, ул һичнәрсәгә игътибар итмәстән, кызып китеп, өстәлдәге кәгазьгә яза биргән...

Шуннан бер ел элек мин, «Гасыр» көтепханәсенең тапшыруы буенча, әлеге Галимҗан сөйләгән язучының зур гына бер нәрсәсен күчереп чыккан идем. Аны күчерү шулчаклы авыр булды миңа, җан тирләрем чыкты. Дөрес, ул әнбер канәгатьләнерлек дәрәҗәдә тәртипле, аңлаешлы язылган. Сүз төзелешләре матур, җайлы: вакыйгалар, җепкә тезелгәндәй, бер-берсенә тигез, шома булып бәйләнеп баралар. Ләкин, язу мәсьәләсенә килгәндә, ничек итеп әйтим инде, ирекле-ирексез, бер гарәп шагыйренең: «Яр буендагы каз аягы эзләренә охшаган хатыгызны алдым. Ләкин укыр өчен үзегезне чакырырга кирәк булыр», — дигән сүзләрен хәтерләргә туры килә.

«Гасыр» көтепханәсенең хуҗасы Әхмәтгәрәй Хәсәни дә әйтә:

— Шуның өчен дә без аның әсәрләрен матбугатка яңадан күчертеп җибәрәбез, чөнки хәреф җыючылар танымыйлар, — ди.

Шул турыда Галимҗанга сөйләсәм, бу юлы да ул язучыны яклый:

— Ул артык бирелеп китеп, тирән уйлап язуы аркасында, башына килгән фикер-

ләрне, күз алдында җанланган сурәтләрне тасвир итүгә чумып, язуының матурлыгына булган игътибарын да югалта, — ди.

Мин китәр алдыннан Галимҗан сорап куйды:

— Син Нәҗип Думавины күрдеңме!

— Юк... Нигә, ул мондамыни!..

— Мин аны моннан биш-алты көн элек урамда гына күреп калдым. Өстендә иске генә киемнәр, аркасына кечкенә генә бер биштәр дә аскан иде. Эндәшергә уйлаган идем дә, әллә ни яхшысынмадым.

— Гаҗәп, кая бара икән соң ул!.. Шахтага түгелдер лә!

Үзем торган «Болгар» номерларына кайткач, аның конторасыннан миңа бер ачык хат китереп бирделәр. Бу хат Нәҗип Думавидан иде:

— Бубидан ашыгыч рәвештә Казанга хәрби идарәгә чакырып алдылар да, килеп төшүгә, солдатлар лагерена озаттылар. Бер тиен дә акчам юк, бер сум гына булса да җибәрә күр!

Нәҗип Думави набор вакытында тиешле процентган артып калган таза егетләрнең берсе — запас солдат икән. Шуның өчен дә аны бер айга «уен»га озатканнар. (Бу чагында ул Габдулла Бубилар мәктәбендә укыта иде.) Галимҗан да аны шунда китеп барганда күреп калган икән.

Бу чагында мин үзем дә акча мәсьәләсендә шактый кыйнала идем. Икенче көнне иртә белән, шул турыда уйланып торганда, Галимҗан Ибраһимов килеп керде:

— Я, нихәл, тыныч йокладыңмы!

— Йокысы качмас иде әле аның, менә шунысы күңелсезрәк...

Мин Нәҗипнең ачык хатын аның алдына куйдым.

— Алай булса, миндә өч сум акча бар әле, мә, шуны җибәр!

Ул башта миңа бер сумлык кәгазь акча бирде дә аннан соң:

— Тукта әле, — диде, — ул бит тоткын хәлендә, тагын да бер илле тиен кушарга кирәк. Без монда ничек тә рәтләрбез, һич булмаганда, Һади абзыйның җил ягына сәлам кыстырырга туры килер!

Шуннан тагын үкенгәнрәк рәвештә:

— Шул чагында Нәҗипкә эндәшәсем калган икән, кулына ук тоттырып җибәргән булыр идем, — дип өстәде.

Мин почтага барырга җыенган гына идем, Нәҗипнең хатыны килеп керде:

— Мин кичәгенәк Нәҗип янында булдым. Сезгә сәлам әйтте, — диде ул. — Нәҗип сездән акча сорап язган булган икән. Инде җибәрмәскә кушты...

Нәҗип лагерьдан кайткач та, аның белән без икәүләп Галимҗанга бардык. Галимҗан үзендә туры килде. Ул Нәҗипне кочаклап каршы алды да:

— Я, лагерь бик ватмадымы үзеңне! — диде.

— Вату кайда! — диде Нәҗип, күңелле генә итеп. — Саф һава, вакытлы ашау-эчү, хәрәкәт. Мин үземне яхшы хис итә башладым әле.

Нәҗипнең бит һәм куллары җил-кояш астында тимердәй каралып киткән иде. Без өчәүләп, Думавига җибәрелгән акча исәбенә, ресторанга сыйланырга киттек. Башта сүз вак-төякләр турындарак барды. Болар арасында яхшы ук күңелсезлекләр дә бар иде. Шуңа күрә булса кирәк, Галимҗан сүзне икенче бер җитди мәсьәләгә борды:

— Бәшири, минем сиңа әйткәнем юк шикелле әле, — диде ул. — Мин бит татар теленең сарыф вә нәхуын[1] тәмам эшләп бетердем. Киләсе уку елына басылып чыкса кирәк.

Галимҗанның шушы сүзләре Нәҗипне дә җанландырып җибәрде:

— Синең аны язуың турында Бәшири миңа сөйләгән иде, — диде ул Галимҗанга. — Хәтта мин синең квартирыңа барып, язган нәрсәләрең белән ныклап танышырга һәм үземнең кайбер фикерләремне, киңәшләремне әйтергә дә уйлаган идем. Мөһим вә җитди бер эш бит бу. Тирәннәнрәк уйлап эшләргә кирәк аны.

— Ярдәм итәсез икән — бик әйбәт булыр иде, — диде Галимҗан да, үзенең теләгәнен һәм канәгатьләнүен белдереп.

Шуннан соң Нәҗип Галимҗанга байтак кына сораулар бирде һәм үзенең кайбер киңәшләрен әйтеп алды.

---

[1] Морфологиясен һәм синтаксисын.

— Зур эш бу, Галимҗан, зур эш, — дип кабатлады. — Татар мәдәнияте тарихында татар теленең сарыф вә нәхуын беренче тапкыр эшләп чыгару — мәңге онытылмаслык бер хезмәт!..

Нәҗип Думави чын мәгънәсе белән педагог һәм педагогияне тирәннән аңлап, аңа нык бирелгән бер кеше дә иде. Ул үзенең табигате, яратылышы белән үк педагог иде. Мин моны аның педагогия турында сөйләгән фикерләренә карап кына әйтмим, ә берничә тапкыр аның укыткан җирләрендә, класста дәрес биргән чакларында булганнарымны да күз алдында тотам. Нәҗип Думави укучы балаларны ничаклы яратса, укучылар да аны шулчаклы ригая итәләр, тыңлыйлар иде. Мин, Вәрәки авылында ике ел укытканнан соң, аннан киткән чагымда, үз урыныма Нәҗип Думавины тәкъдим иткән идем. Нәҗип анда дүрт ел укытты. Укучылар да, аларның ата-аналары да миңа гел хат язып, Нәҗиптән бик риза булганлыкларын, аны тәкъдим иткәнлегем өчен, миңа рәхмәтләрен белдерделәр.

Менә шуңа күрә дә мин Нәҗип Думави белән утырышкан чакларда, әдәбият турында сөйләшүдән дә бигрәк, педагогия хакында гәпләшүне артыграк, файдалырак саный идем.

Сөйләшә торгач, Нәҗип тагын да әрнү, сыкрану белән кызып китте:

— «Мәдәният мәйданында үсәбез!» дип лаф орган булабыз. Дөрес, матбугат вә әдәбият дөньясында күзгә күренерлек уңышларыбыз да юк түгел. Ләкин уку-укыту тәртипләренә, педагогия мәсьәләләренә килгәндә, бездә әле һаман да шул иске мунча, иске таш!..

Галимҗан да аның сүзләрен куәтләп җибәрде:

— Бу өлкәдәге үсешебез әле бака ботыннан гына!

— Бака ботыннан булса — бер хәл әле... Бака бәкәленнән диген.

Нәҗип тагын да кызып сөйләп китте:

— «Ысулы җәдит» дигән булабыз. Без бит яңа тәртип белән дә балаларны, искечә укытуга караганда, укырга-язарга тизрәк өйрәтүдән узганыбыз юк. Балаларны укырга-язарга өйрәткәннән соң, һаман да шул гарәп теленең сарыф-нәхуын укыта башлыйбыз. Укудан туктагач та, сука башына ябышачак яисә шахтага күмер чукырга китәчәк татар малаена ни пычагыма кирәк ул гарәп сарыф-нәхуы!! Телгә алып әйтүе дә оят бит, үз ана теленнең сарыф-нәхуы юк!.. Ел саен мәктәпләр өчен кырык-иллеләп уку китаплары бастырып чыгаралар. Якуб Хәлили төсле мәзин дә уку китабы яза, Хәбибрахман Зәбири кебек сәүдәгәр дә дәреслек яза, Фоад Туктаров шикелле, гимназия белән университет арасында калган «галим»нәр «педагог» булып китәләр дә китап язарга керешәләр!..

...Сөйләшә торгач, сүз әдәбият мәсьәләсенә дә барып җитте. Ул да шул Нәҗипнең мәктәпләрдә укыту өчен әдәбият дәреслекләре булмавыннан зарлануы аркасында килеп чыкты. Шуннан кайбер әдипләрнең иҗатларына бәя бирү мәсьәләсенә дә килеп терәлдек.

Галимҗанның татар шагыйрьләре турындагы карашларына бер генә төрле дә сүз катмастан, тыныч кына утырган Нәҗип Думави Дәрдмәндкә караган сүзләрдән соң:

— Куй әле, зинһар, Галимҗан! — диде. — Безнең тормышта аңардан башка да, өметсезлеккә тартып, йөрәкләрне әрнетә торган хәлләр аз түгел!..

## 5

Быел, 1911 елда, мин Мәкәрҗә ярминкәсенә барып, бер атнадай гына торып кайттым да үткән кышта укыткан Вәрәки авылына киттем.

Рузаевка станциясендә минем Байбиков дигән танышларым бар иде. Юл уңае белән шунда туктап, берәр көн кунак булырга уйладым. Элек мин ул турыда бернәрсә дә белми идем: Шәриф Камаллар авылы Пешлә Рузаевкага терәлеп кенә тора икән. Мин әлеге Байбиковлардан: «Шәриф Камалны беләсезме?» — дип сорадым.

— Нигә белмәскә! — диделәр алар. — Шәриф Камаллар белән без барышып-килешеп йөрибез. Әле кичә генә ул энесе Габдулла белән бездә булды.

— Ул хәзер дә авылындамыни?

— Әйе!

Шуны белеп алгач, шатлыгымнан нишләргә дә белмәдем һәм Шәриф Камалны эзләп киттем.

Мин аны урамда очраттым.

Өстенә кара тужурка, башына тар кырпылы каракүл бүрек кигән, сөйкемле, ак чырайлы, сакал-мыексыз берәү минем алдыма килеп басты да иң элек тәсмерләп карап торды. Аннан соң, тартынып-нитеп тормастан, үзенең ялгышмавына ышанган рәвештә:

— Исәнмесез, Зариф әфәнде! — диде.

Мин гаҗәпләнеп:

— Сез кем буласыз соң! — дидем. — Мине кайдан беләсез!

— Мин — Шәриф Камал булам! — диде ул, күрешү өчен кулын сузып. — Сезне сорашып белүемә, бәян итүләренә карап таныдым. Кичә генә Байбиковлар да: «Ул шушы көннәрдә килергә тиеш», — дигәннәр иде. Шунлыктан, бу башка кеше булмас, дип уйладым.

Икәүләп аларның өйләренә киттек. Капка төпләренә барып җиткәч, Шәриф Камал мине туктатты:

— Әнә минем бабай — әтинең әтисе кайтып килә, аның белән таныштырыйм әле сине. Бик кунакчыл карт, матбугат, әдәбиятны да яратып укый.

Озын буйлы, шактый таза гәүдәле, күз карашлары да җанлы гына, тере генә, күрер күзгә 60—65 яшьләр чамасында булыр, ак сакаллы карт, безнең янга килеп җиткәч, Шәриф Камал:

— Менә, бабай, кадерле кунак! — диде. — Казаннан килгән Зариф Бәшири дигән шагыйрь, әдип. Бәлки, шигырьләрен укып та хәтерли торгансыңдыр!

Карт ике кулымны бердән үзенең куллары арасына алып кысты да:

— Беләм, беләм, бик беләм! — диде. — Кадерле мосафир икәнсең!

Шуннан соң ул зарлы тавыш белән:

— Изге көнгә — җомга көненә туры килгәнсең икән, балам, кадерле мосафир, — диде.— Мин сездән миңа тизрәк үлем теләп дога кылуыгызны сорыйм. Изге көндә килгән мосафирларның догалары кабул була торган иде...

Мин, дөньяда тизрәк үлем килүне теләүчеләр дә бар икән, дип гаҗәпләндем дә:

— Нигә, бабай, дөньядан шулчаклы туйдыгызмыни, тормышта зур авырлыклар күрдегезме әллә! — дидем.

— Юк, балам, юк! — диде бабай.— Тормышымда зарланырлык авырлыклар күрмәдем, ил имамы булып, кадер-хөрмәт белән гомер кичердем. Ул яктан бик ризамын. Аннан әйтүем түгел. Хәзер миңа йөз дә биш яшь. Шул озын гомер эчендә күпме гөнаһы кичергәнмен. Инде тагын да яшәп, тагын да күпме гөнаһы кичерергә кирәк. Аллаһы тәгалә үзенең яратмаган бәндәсен, озын гомер биреп, күп гөнаһларга дучар итү белән ләгънәтли, дигәннәр борынгы китаплар.

— Әй, бабай, нигә алай өметсезләнергә! — дидем мин. — Кеше бит гомере буена гөнаһы кылып кына яшәми. Бәлки, синең яхшы эшләрең гөнаһыңа караганда да күбрәктер. Менә бит халыкка нинди файдалы хезмәт итүче балалар, балаларыңның балаларын үстергәнсең, тәрбия иткәнсең. Менә улыгыз Шәриф халыкка аң бирү, аларны тәрбия итү юлында нинди яхшы китаплар яза, безнең шикелле мосафирлар, аны күрү өчен, ерак җирләрдән киләләр. Менә шуның үзе генә дә бөтен гөнаһыңны җуярлык бит әле, бабай... Тазалыгың җирендә булырга охшый, син шуңа куанып, аларның кадер-хөрмәтләре астында рәхәтләнеп яшәүне телә!

— Анысы шөкер, балаларым кадер-хөрмәт итәләр! — диде бабай. — Ләкин үзем кырысрак, тынгысыз, ярсурак табигатьле булдым. Балаларымны да, киленнәрне дә рәнҗетергә, хәтерләрен калдырырга туры килде. Ярый ла алар бәхилләп гүргә озатсалар!

Шуннан соң ул, якын һәм үз күргәндәй итеп, Шәриф Камалга карап алды да:

— Әле менә улым Шәриф тә минем шушы начар якларымны әкият итеп язды! — диде.

Мин Шәриф Камалдан:

— Нинди хикәя соң ул! — дип сорадым.

— «Кычкырыш» дигән хикәяне әйтә, — диде Шәриф.

Шуннан соң бабайга:

— Ул хикәяне язганы өчен хәтерең калмагандыр бит!.. — дидем.

— Юк, балам, юк! — диде карт. — Шуны укыган кешеләр андый табигатьле булуның начар нәрсә икәнлеген күрсеннәр дә, үз-үзләрен төзәтсеннәр, тәрбия итсеннәр. Бәлкем, шуның да савабы тияр миңа!

— Бик дөрес әйтәсең, бабай, әнә шундый улларың булуына шатланып яшәргә кирәк. Үзең әйтмешли, хода гомер биреп ләгънәтләсә, аңа каршы менә шундый балалар белән шәрәфәтле кылгандыр үзеңне.

Бабайның күңеле ачылып киткәндәй булып, тагын да сөйкемле рәвештә Шәриф Камалга карап алды:

— Мосафир кунакны өйгә алып кер, балам, кунак ит!

— Юк, бабай, — диде Шәриф Камал. — Мин аны өйгә алып кермим, энем Габдулла янына алып барам. Анда күңеллерәк булыр!

— Бик әйбәт, балам, анысы да әйбәт!

Карт белән Шәриф өйләренә кереп киттеләр.

— Мин өс-башымны алмаштырып чыгыйм әле, — диде Шәриф Камал.

Ул кара пальто киеп, газета белән чорналган галошны култыгына кыстырып чыкты.

— Көннәр аяз, коры булса да, «запаслы ат арымый» дигәндәй, андый-мондый яңгыр явып калса дип, резинка галошны да алдым әле.

Шәриф Камалның энесе Габдулла авылдан бер чакрымдай гына ераклыкта булган, уйсу-үзән бер җирдәге куаклыкта өч-дүрт бия бәйләп, шуларның сөтләреннән кымыз әчетә икән. Тимер юл станциясендә торучылар, кичләрен килеп, кымыз эчәләр. Шәриф Камал мине шунда алып китте. Шул җирдә кечкенәрәк кенә, искерәк кенә бер өй дә бар. Габдулла җәй көне семьясы белән монда тора икән. Ул безне егетләрчә, ачык чырай, якты йөз белән каршы алды:

— Минем аңлавыма караганда, бу кеше — Зариф әфәнде булса кирәк, — диде ул да.

Мин шунда ук чамалап алдым: Шәриф Камал белән Габдулла төс ягыннан да, табигатьләре ягыннан да бер-берсенә бер генә бөртек тә охшамаганнар. Шәриф Камалның хәрәкәте әкрен, табигате басынкы, аз сүзле, шуның белән бергә аның күз карашлары тирән уйчанлыгын күрсәтә. Габдулла исә сүзгә юмарт, сөйләгәндә өздереп сөйли, ярып сала. Хәрәкәте җитез, җилләнеп йөри. Шунлыктан мин байтак вакытка чаклы Шәриф Камал белән сүз башлап, сөйләшә алмый утырдым, чөнки Шәриф Камалга төбәп бирәр сорау ташласам, аңа җавапны Габдулла бирә.

Өйнең ике тәрәзә арасындагы стенасында бер скрипка эленеп тора. Мин Шәриф Камалга карап:

— Бу кайсыгызныкы! — дип сорадым. Аңа да җавапны Габдулла бирде:

— Ул Шәриф агайныкы, — диде. — Шәриф агай һәр көнне менә шунда килә дә, алдына берәр бутылка кымыз куеп, скрипкасын сыздырып җибәрә. Үзе уйный, үзе нәрсәдер уйлый. Аннары соң идән буенда арлы-бирле атлап йөри. Кайчагында үз-үзенә сөйләнеп тә куя!

Бәлки, Габдулла Шәриф Камал гадәтләре турында тагын да күбрәк сөйләр, мин дә рәхәтләнеп тыңлаган булыр идем, ләкин Шәриф Камал аны туктатты:

— Син тагын хатыным белән ничек авыз үлчәшкәнне дә сөйләргә уйламыйсыңмы!!.

Шуннан соң Шәриф Камал, энесенә күп сөйләргә юл куймаска теләгәндәй, минем белән бабасының әңгәмәсе турында сөйләп алды.

— Кызык карт, — диде ул, — Зариф әфәндедән дә, тизрәк үлүен теләп, дога кылуны сорый. Үзенең гайрәте һаман да җирендә әле: юк кына бернәрсә өчен дә бөтен өй эчен зир-зәбәр китереп ала. Үзе болай саф күңелле ул, соңыннан үкенеп тә куя.

— Әлеге хикәяң чынлап та аның турындамы!

— Бөтенләе белән, — диде Шәриф Камал. — Хикәядә аны азарлаган икенче карт — аның энесе, анысы басынкы табигатьле, әхлаклы карт. Ул да исән әле.

Менә шуннан соң гына без Шәриф Камал белән сүзгә керешеп китә алдык.

— Минем һәрбер хикәям үз күз алдымнан, үз җилкәмнән үткән хәлләрдән, ва-

кыйгалардан алынып языла, үз әйләнә-тирәмдәге кешеләр сурәтләнә, — ди ул. — Яшь булсам да, шактый күпне күрергә туры килде.

Шәриф Камал ниндидер бер сатучыга малай булып йөри. Каспий диңгезе буенда балык промыселларында эшли. Шул промыселларның берсендә бер кыз белән ярата, аны оныта алмый. «Аның турында бер хикәя дә язам әле», — ди ул.

Шуларны сөйләгәннән соң ул стенага элеңгән әлеге скрипканы алды да уйнап җибәрде. Үзе уйный, үзе җырлый, уйнаган, җырлаган саен, моңы көчәя, тавышы калтырана. Аның калтыранып чыккан тавышы, алай артык көчле яңгыравыклы булмаса да, үзенең йөрәктән чыгуы белән синең дә йөрәгеңне калтырата иде. Син шунда йөрәгеңдә тирән, югалмаслык эз калдырган Әнисәләрне, Мәдинәләрне күз алдында җанландырасың. Кем белә, бәлки, Шәриф Камал да шулай мәхәббәт белән янып-көеп калган промысел кызын күз алдына бастырып, аны кызганып моңая торгандыр!

Ул, уйнаудан тукталып, скрипкасын яңадан элеп куйгач, минем йөрәгемнең нәрсә өчен борчылганын сизенгәндәй иттереп:

— Мәхәббәтеңне исеңә төшердеме скрипка! — дип куйды. Мин авыр гына бер көрсенү белән җавап бирдем.

Габдулла өстәл өстенә өч шешә кымыз китереп куйды да:

— Киленегез менә дигән мишәр пәрәмәче әзерли, шул өлгергәнче, кымыз эчә торыйк, — диде. — Ләкин пәрәмәч ат итеннән түгел, яшь, симез бозау итеннән!

— Алай булгач, мишәр пәрәмәче булмый инде ул, — дидем мин. Шәриф тә көлеп җибәрде:

— Мөселман пәрәмәче дә түгел!

Әкрен генә кымыз эчә-эчә, Шәриф Камал белән байтак сөйләшеп алдык.

— Казан матбугаты белән бер дә бәйләнеш тотмыйсың, ахры, син! — дидем мин.

— Юк шул, — диде Шәриф Камал, — ләкин бу нинди дә булса бер исәп, план белән түгел. Үз-үзеннән шулай килеп чыкты. Беренче хикәямне татар дөньясында бердәнбер журнал булган «Шура»га җибәргән идем. Риза Казый, аны бастырып чыгаргач та, үземә хат язды. Ул хатын үз исеменнән генә түгел, Закир Рәмиев һәм Фатих Кәримиләр исеменнән дә язганлыгын әйтә дә, азагында: «Каләмегез көчле, языгыз, җибәрегез, тоткарсыз рәвештә бастырып торырбыз!» — ди. Беренче тапкыр шундый сүзләр белән минем рухымны, дәртемне күтәрүчеләр шулар булгач, язган нәрсәләремне аларга җибәреп торуны үземә бурыч итеп санадым.

Ул үзенең бөтенләйгә Оренбургка күчеп барырга, шунда җирләшергә җыенганлыгын да әйтеп алды.

Казан матбугаты белән бәйләнештә булмаса да, Шәриф Камал Казандагы кайбер күренеклерәк татар язучылары, шул җөмләдән Галимҗан Ибраһимов белән дә бәйләнеш тота, хатлашып тора икән.

Шәриф Камал белән безнең утырыш, юк кына бер сәбәп аркасында, көтелмәгәнчәрәк тәмамланды. Габдулла кыр ягына чыга торган тәрәзәгә карады да:

— Әнә мулла килә, ул, мөгаен, Зариф әфәнденең монда булуын ишеткәндер, аны эзләп килә торгандыр, — диде.

Без дә тәрәзә аркылы күз салдык. Зур гына арбага матур кара туры ат җиккән берәү әлеге без утырган өйгә якынлашып килә иде. Арбадагы кешене күргәч тә, танып алдым:

— Яңа Аллаголның Харис мулла мәктәбе мөгаллиме ич ул! — дидем мин.— Кайдан килеп чыккан ул монда!

Мин 1909—1910 нчы елларда Пенза губернасы Яңа Аллагол (Устрахманка) авылында укыткан чагында, шул авылның Харис мулла мәктәбендә ярыйсы гына ачык фикерле, аңлы бер укытучы бар иде. (Аның исем-фамилиясен хәзер хәтерли алмыйм). Ул минем белән нык аралаша, аш мәҗлесләрендә, муллалар белән сүз көрәштергән чакларда, аларга каршы төшә торган иде. Менә шушы кеше, Шәриф Камаллар авылындагы бер карт мулла үлгәч, аның урынына мулла була да шуның кызына йортка керә. Шәриф Камал шуны миңа сөйләгәннән соң:

— Ул безнең белән аралаша, сезне гел сагынып, искә алып сөйли, — диде.

Әлеге мулла ахылдап килеп керде дә:

— Мин сине станциядә күреп калдым. Ләкин, «ай күрде, кояш алды» дигәндәй, син халык арасында буталып, күздән югалдың! — диде. — Шуннан соң мин өйгә кайтып,

ат җиктем дә, сезне эзләп киттем. Байбиковларда, Шәриф Камалларда булдым, аза-гында мене эзләп таптым. Әйдәгез, Шәриф абый, һәммәгез дә безгә!.. Остабикә тавык тутыра калган иде...

Бу кешенең мулла булу хәбәрен ишетү һәм аны мулла хәлендә күрү миңа сәер дә, авыр да булып тоелды. Шунлыктан мин аңа турыдан-туры:

— Мин синнән моны көтмәгән идем, — дидем. — Шундый аңлы башың белән мулла булу гына да җитмәгән тагын, аксак суфилар төсле, мулла кызына йортка да кергәнсең!

— Нишлисең бит, тормыш, Зариф әфәнде! — ди ул, авыр гына көрсенеп.— Татар мәдрәсәсе биргән белем шуннан артыкка ярамагач, теләсәң-теләмәсәң дә, шуңа риза булырга мәҗбүр инде... Коры аң белән генә әллә кайда барып булмый икән шул ул. Аң буенча йөрерлек белемең булмагач, — нишлисең!

— Нәҗип Думавиның «Мулла булам, мулла!»сы, — дип куйды Шәриф Камал да.

Габдулланың иптәше әзерләгән пәрәмәч әле яңа гына өстәлгә куелган, аны зур бер иштиһа белән ашый гына башлаган идек. Шундый тәмле пәрәмәчне ташлап китүе дә кызганыч, тутырган тавык та үзенә тарта!.. Пәрәмәчне ныклабрак ашасаң — тавыкка урын калмый. Шәриф Камалга да шуны әйтеп алдым:

— Итәктән тартсаң — җиңгә, җиңнән тартсаң — итәккә!

Шәриф Камал да көлеп:

— Пәрәмәч — безнең мишәр халкында мөселман азыгы, — диде, — аны ашау мөселманлык билгесе санала; тутырылган тавык булса — милли татар азыгы. Шулай булгач, әйдә, ни булса — шул булыр, мөселман булганчы, татар булыйк!..

Шулай көләшә-көлешә, арбага чыгып утырдык.

## 6

Борынгылар әйтмешли:

— Дурт ягым кыйбла!

Бу юлы Уфага килгәч, туп-туры элеге «Нур» номерларына төштем:

— Рәхим итегез, менә паспорт, менә ак билет!

Ашап-эчеп, бераз гына ял иткәч тә, Гафуриларга «паспортлы кеше» булып барырга җыенган идем. Ләкин, көтелмәгән ике кеше килеп, юлымны бүлделәр.

Бәрәки авылында миннән укыган шәкертләр-кызлар арасында Хава исемле искиткеч зирәк, үткен табигатьле бер ятимә кыз бар иде. Бәрәки халкы әнә шул кызны Уфага мөгаллимәләр курсына укырга җибәргән икән. Минем Уфада булуымны ишетеп, ул номерыма килеп керде. Мин гаҗәпсенеп:

— Хава, кайдан җил ташлады сине! Ә минем килгәнлегемне кайдан ишетеп өлгердең! — дидем. Хава моны бик очраклы гына белгәнлеген аңлатты.

Аның белән бергә озын буйлы, чандыр йөзле, ләкин гаҗәп уйчан карашлы, ярым европача киенгән бер егет тә килгән иде. Ләкин, беренче тапкыр күзгә ташлану белән, ул әллә ничек күңелгә бик үк якын булмаган кешедәй тәэсир калдырды. Хәтта мин: «Тапкан икән Хава да үзенә «тәти» бер егет!» — дигән кебек уйга да килә яздым.

Бердән, әнә шундый тәэсир аркасында, икенчедән, Хава белән мавыгып китүемнән булса кирәк, мин бу егетнең үзен кем дип таныштыруына да артык игътибар итмәгәнмен. Тик «Галия шәкерте» дигән сүзләре генә колакка чалынып калган. Хава белән беркадәр сөйләшеп утырганнан соң гына, мин әлеге егеткә карап:

— «Галиядә укыйм» дидең шикелле син! — дидем.

— Әйе, шулай, — диде ул да, кырыс кына итеп.

— Куптәнме, ничәнче сыйныфта!

— Дөресен генә әйткәндә, мин хәзер укымыйм. Мәдрәсәне быел бетереп чыктым.

— Шәп! — дим мин.

— Нәрсәсе «шәп» инде аның! — ди егет.

— Галия мәдрәсәсеннән күбесенчә шәп кенә кешеләр чыга бит! — дидем мин. — Син менә шул мәдрәсәдә иң кимендә 5—6 ел укыгансыңдыр әле. Шулай булгач, син дә зыялы[1] буласыңдыр инде!

— Кем белә инде аны! Эшли башлагач, эш юлындагы сәләт күрсәтер!

— Нинди юл белән, нинди эштә эшләргә уйлыйсың соң?..

— Бераз гына матбугат, әдәбият тирәсендә маташырга дәрт бар.

— Матбугат, әдәбият эшеннән хәбәрең бармы соң!

— Бераз гына!

— Алай булгач, әйт әле, егет, — дидем мин, — менә шушы шигырьне кем язган, аңа син ничек карыйсың!

Шуннан соң мин Шәйхзадә Бабичның түбәндәге шигырен укыдым:

Күктә алла,
Җирдә иблис,
 Мин — малай!
Берсе «дин!» дип,
Берсе «мин!» дип
 тарткалай!
Белмимен:
Әллә алла,
Әллә иблис
 алдалай!

Әлеге егет, җилкәсен кысып, бер миңа, бер Хавага табан карады да:

— Әйтә алмыйм шул! — диде.

Хава аңа:

— Я, әйт инде, әйт! Нигә әйтмисең! — ди.

— Белмәгәч, нәрсәсен әйтсен ул! — дип, кисәтеп куйдым мин дә. — Алай булгач, егет, мин сиңа Галиягә яңадан кереп укырга тәкъдим итәр идем. Шушы шигырьнең дә кемнеке икәнен белмәгәч...

Ләкин егет югалып калмады. Ул: «Син мине сынасаң, мин дә сине имтиханлап карыйм әле!» — дигәндәй:

— Алай булгач, — диде, — миңа да бер шигырь укырга рөхсәт итегез! — Шуны әйтегез әле: менә бу шигырьне кем язган икән!

Дүниедән өметем жок минем, деймен,
Өмергә үткән шеттәй үкенбеймен.
Азаттык пән тыныштык коксәгәнем,
«Ойктамак пән омытпак» деп әздеймен[2].

— Ә, бу казакъча икән шул. Мин казакъчаны аңламыйм шул! — дигән булдым.

Ләкин мин казакъчаны аңлыйм гына түгел, казакъ телен шактый яхшы беләм. Өч ел буена казакълар арасында бер шәһәрдә яшәп тә, казакъчаны аңлый алмаслык булсаң, аннары, казакълар әйтмешли, үзеңне ишәкнең арт тоягы итеп санарга гына кала! Шулай ук мин Капал мәктәбендә казакъ балаларын да укыттым бит. Аларга казакъ шагыйрьләренең матур шигырьләрен дә ятлата идем. Күп кенә казакъча шигырьләр дә беләм. Ләкин, гонаһыма каршы, менә бу шигырьнең кемнеке икәнлеген белми идем. Шунлыктан мин, әнә шул белмәвемне яшерү өчен, казакъ телен аңламаганга салыштым. Әмма мин моның белән генә ота алмадым, әлеге үткен, кыю егет:

— Алай булгач, Зариф агай, өч ел шул якта яшәп тә, казакъ телен белмәгәч, аны, Уфага кайтып, бездән өйрәнергә туры килер! — диде, елмаеп кына.

---

[1] Зыялы — интеллигент.

[2] Дөньядан өметем юк минем димен.
Гомерем үтүенә үкенмимен.
Азатлык һәм тынычлык теләгәнем,
Йокламак һәм онтылмакны мин эзлимен.

Шулай итеп мин кимсетергә уйлаган егет үземнең борыныма чиртте! Шунлыктан мин бу шигырьнең кемнеке булуын белү кирәклеген бервакытта да исемнән чыгармадым.

Тик байтак еллар үткәч, Октябрь революциясеннән соң гына, бу шигырьнең Лермонтовныкы икәнлеген белдем. Аны атаклы казакъ шагыйре Абай Кунанбаев тәрҗемә иткән булган икән...

Хава белән егет ашыгып чыгып киттеләр. Ул көнне мөгаллимәләр курсында укучы кызлар үзара гына бер әдәби кичә үткәрәләр икән. Шуны белдергәннән соң:

— Сезнең белән танышуыбыздан мин бик шатмын, Зариф агай, — диде уйчан карашлы какча егет. — Ләкин мин, әгәр дә сез рөхсәт итсәгез, сезнең белән иркенләбрәк бер утырышырга теләр идем.

Бу кыска гына утырыштан мин, әлбәттә, бөтенләй тәэсирсез калмадым. Беренче тапкыр күз ташлауда әллә ничек сөйкемсез төсле күренгән бу егет үзенә карата миндә җылы, якын бер тойгы калдырды. Мин уйландым:

— Бу егет алай буш куык булырга охшамый. Хава да аңламый гына сайламаган, күрәсең, аны!

Шушы көннәрдә ураза бәйрәме килеп җитте. Шул уңай белән мине «Тормыш» газетасы редакциясенә чакырганнар иде. Мин барган чагында, редактор Закир Кадыйридан башка, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думави һәм Сәгыйть Сүнчәләйләр, шулар белән бергә үк Хава белән миңа килгән әлеге егет тә бар иде. Алар кемнеңдер, Сәгыйть Сүнчәләйнеке иде шикелле, шигырен тикшереп утыралар икән. Теге егет миңа карап елмайды да ияк кагып исәнләште, мин дә шулай җавап кайтардым. Бу чагында минем барлык игътибарымны, бер дә көтелмәгәнчә, уйланмаганча, Нәҗип Думавиның да шунда булуы үзенә җәлеп итте. Өч елдан артык күрмәгән Нәҗипне кочаклап алырга теләсәм дә, аларның сүзләрен бүләргә кыймадым. Алар шигырь турында бер фикергә килгәннән соң гына, мин утырган урынымнан торып:

— Нәҗип, мин кемне күрәм!!. Кайдан җил ташлады сине! — дип, аңа табан атлаган гына идем, Мәҗит Гафури, нәрсәсенә шулчаклы ашыккандыр, минем юлымны бүлде дә:

— Мин сине Шәйхзадә Бабич белән таныштырырга булган идем бит әле, — диде. — Менә ул үзе, танышыгыз инде!

Ул миңа теге таныш егетне тәкъдим итте.

Мин нәрсә әйтергә дә һәм нишләргә дә белми аптырап калдым: ышанырга да, ышанмаска да теләгәндәй, бер Мәҗиткә, бер егеткә карап тордым, чөнки мин Бабичны бөтенләй башка бер кыяфәттә күз алдына китерә идем. Бабич, урыныннан торып, әллә ничек оялган да, кыенсынган да рәвештә, миңа кулын сузды һәм:

— Без Зариф агай белән таныша язып калган идек шикелле! — дип елмайды, миннән гафу сорагандай итеп.

Менә шуннан соң гына мин Нәҗип Думави белән шартына китереп күрешә, исәнләшә алдым.

Аннары Закир Кадыйри миңа карап:

— Менә бит, ничектер туры килеп, бүген Уфага биш олы шагыйрь җыелган, — диде. — Шуңа истәлек рәвешендә, без газетабызның бәйрәм санында сезнең берәр шигырегезне бастырып чыгарырга булдык.

— Бик әйбәт!

Ләкин бу утырыш азагында бик үк күңелле булып чыкмады. Башта Сәгыйть Сүнчәләй шигырен беркадәр төзәтмәләр белән кабул иттеләр. Шуннан соң Бабич шигырен тыңладык. Ул «Көтәм» дигән шигырен язып алып килгән иде.

Үткен телле, тирән хисле Бабичның зур бирелү белән укыган бу шигыре безгә шулкадәр ошады һәм тәэсир итте ки, хәтта без укып бетергәннән соң да шактый вакыт сүзсез тордык, чөнки чын күңелдән чыккан, йөрәк каны белән язылган шигырь иде бу!..

Төзәтмәләр кертү турында бер сүз дә әйтмәстән, без барыбыз да:

— Әлбәттә, бастырырга кирәк! — дидек.

Ләкин Закир Кадыйри моны хупламады.

— Шәй, мин бу шигырьне, — диде ул, — сәер якларын алып ташлаганда гына бастыра алам. Шәй, бу көенчә мөмкин түгел!

Без берникадәр вакытка аптырауда калдык. Бабич моны сиздә булса кирәк: ул, шигырен түш кесәсенә салып, урыныннан кузгалды да:

— Минем бу шигырем, халкыбызга ирекле көн килми торып, дөньяга чыга алмаслыгын үзем дә беләм. Ә мин ул көнне чын ышану белән көтәм. Юк, мин генә түгел, аны бөтен халык көтә! — диде дә, кыю-кыю басып, редакциядән чыгып та китте. Закир Кадыйри сөмсерен коеп, аска карады да:

— Шәй, фәукыльгадә[1] кыю сүзләр, шәй, тули әмәл![2] — дип мыгырданды.

Без байтак вакыт тын тордык. Азагында бу тынлыкны Гафури бозды:

— Шулай да Бабич хаклы! — диде ул. Без дә авыр гына бер көрсенеп алдык.

Шуннан соң Гафури икенче бер мәсьәләне кузгатты:

— Бүгенге көтелмәгән бер очрашуны тарихи истәлек итеп калдыру өчен, бергә рәсемгә төшүне тәкъдим итәр идем мин, — диде ул.

Билгеле, моңа һәммәбез дә ризалык белдердек. Ләкин бу мәсьәләдә дә беркадәр сүз көрәштерүләр булып алды. Ул да булса шул, рәсемгә Бабичны да алу турында иде. Аны да Гафури кузгатты. Аның тәкъдимен мин дә хупладым. Нәҗип Думави белән Сәгыйть Рәмиев тә:

— Без дә каршы килмибез! — диделәр. Ләкин Сәгыйть Сүнчәләй кырт кисеп каршы төште:

— Бабич бит ул яңа гына борынлап килә торган бер шагыйрь, — диде ул. — Аның яза башлавына кайчан да, язган нәрсәсе күпме!..

Мәҗит Гафури моңа каршы, йомшак кына иттереп:

— Мәсьәлә бит озын гомерләрдә, күп шигырьләр язуда түгел. Язган нәрсәләренең сыйфатында, кыйммәтендә. Мәсьәләгә шул яктан чыгып карарга кирәк! — диде.

Кинәттән ачуым кабарып китте дә, мин дә чыдап тора алмадым:

— Болай булмады бу, агай-эне, — дидем. — Мәсьәләне шәрә көенчә алга куеп хәл итәргә кирәк!.. Мин соңгы елларда, Бабич имзасы дөньяга чыккан чорда, Агыйдел, Идел буйларында булганым юк. Шунлыктан татар, башкорт халыкларының Бабич шигырьләренә ничек караулары турында бер сүз дә әйтә алмыйм. Ләкин соңгы өч ел эчендә миңа Урта Азиянең байтак кына җирләрендә булырга туры килде. Мин Алатау итәкләрен таптадым, Кәтмән, Чалкуда тауларының култыкларын араладым, Иле суы, Чу елгасы, Ыссык күл ярларын гиздем. Нинди генә халыклар яшәми анда: татар, уйгур, таранчы, кыргыз, казакъ, үзбәк һәм дунганнар! Менә шул җирләрдә, әнә шул халыклар арасында һәрвакыт Бабич шигырьләренең көчле бер дәрт белән яңгыравын ишетергә туры килә иде миңа!.. Ләкин мин бер генә җирдә дә Сәгыйть Сүнчәләй белән Зариф Бәшири шигырьләренең әнә шулай халык йөрәгенә барып кергәнлеген күрмәдем. Менә шуннан чыгып әйтергә телим: әгәр дә Бабич Сәгыйть Сүнчәләй белән миңа, бигрәк тә миңа: «Син минем белән янәшә утырып, рәсемгә төшәргә лаек түгелсең!» — дисә, мин аның алдында тепсез шайтан булып калыр идем!

Минем шушы очынулы сүзләремне, башкалар шикелле үк, тыныч кына, әмма игътибар белән тыңлап утырган Гафури, Сүнчәләйгә карап, бераз гына башын селкеп торды да:

— Менә нәрсә, Сәгыйть әфәнде, — диде. — Әгәр дә мин, сезнеке төсле 80 шигырь язуга караганда, Бабич шигырьләре төсле сигез юллык бер шигырь яза алсам, үземне дә чын шагыйрь итеп санар идем!

Сәгыйть Сүнчәләй телсез калды.

Без, һичшиксез, Бабичны да уртабызга алырга булдык һәм шунлыктан рәсемгә төшүне икенче көнгә калдырдык. Ләкин, кызганычка каршы, Мәҗит белән без ике көнгә якын эзләсәк тә, Бабичны таба алмадык. Шунлыктан рәсемгә Бабичтан башка гына төшәргә туры килде.

Мин Бабичны бәйрәм үткәч кенә күрдем.

— Кая югалдың син! «Ай күрде, кояш алды», дигәндәй, чыгып киткәч тә, җир упкандай булдың!.. Әллә Кадыйрига ачу итеп, бөтенләй Уфадан күп селтәргә уйладыңмы!

---

[1] Фәукыльгадә — гадәттән тыш.

[2] Тули әмәл — буш хыял.

Бабич бәйрәм көннәрендә авылга китеп, шунда бераз саф һава иснәгәннелеген әйтте дә:

— Төкердем мин аңа! — диде. — Аңа гарьләнү түгел, уйлап та караганым юк... Андый «эт баш, сыер аяклар»ның шундый мөгамәләләре белән горурланам гына мин! «Минем шундый шигырьләрем аларның тез буыннарын какшата икән!» — дим.

Аңа рәсемгә төшү вакыйгасын сөйләгәч, ул:

— Менә монысы минем өчен чынлап та үкенерлек, хафаланырлык бер хәл, — диде һәм шуның тәэсирендә «Бәйрәм үткәч» дигән бер шигырь язачагын әйтте. Ул икенче көнне үк шул шигырьне язып, миңа алып килде.

Бабич белән без берничә тапкыр утырыштык. Ул Галимҗан Ибраһимовның Галия мәдрәсәсендә әдәбият укытуына шатлана.

— Ул укыта башлагач та, мин үземдә кискен бер борылыш башланганлыгын сиздем, — ди. — Аңа чаклы миндә дә матур әдәбиятта, бигрәк тә шигырьдә, гарәп-фарсы сүзләрен куллану кирәк, дигән бер караш бар иде. Шул уңай белән бервакытны Галимҗан агай миннән сорый: «Син киләчәкнең яктыга табан баруында кемгә, нәрсәгә таянасың!» — ди. «Билгеле, — мин әйтәм, — халкыма», дим. «Шулай булгач, — ди Галимҗан агай, — синең әдәби телең дә үз халкыңның теле булырга тиеш түгелме!» Шуннан соң мин халык телен актарып, аның җәүһәрләрен эзләргә керештем.

Мин Бабичның гаҗәп дәрәҗәдә сүзгә осталыгына хайран калдым. Ул уен-көлке сөйләгән чагында, үзенең сүзләре белән генә түгел, хәрәкәте белән дә сине көләргә мәҗбүр итә. Ә инде җитдине сөйләгәндә, синең бөтен игътибарыңны яулап ала. Ул моны әнә шул көннәрдә Газиз Әлмөхәммәтев белән уздырылган әдәбият кичәсендә күрсәтте. Башта ул берничә җитди шигырь чыгып сөйләде. Тегеләй дә Газиз Әлмөхәммәтевнең җырлавы астында тирән уйга талган зал Бабич сөйләгән вакытта тагын да тирәнрәк тынлыкка чумды. Ләкин шуның артыннан ук Бабич, сәхнәгә чыгып, кызыклы, көлкеле нәрсәләр сөйли башлагач, зал кинәттән җанланып, терелеп китте. Халык эче катып көлә, котырып кул чаба иде.

Шуннан соң мин Бабичны үз гомеремдә бер тапкыр да күрә алмадым.

## 7

Казанга кайту теләгемә мин 1921 елның башларында гына ирештем.

Шәһит Әхмәдиев тырышлыгы аркасында, командировка алып, Казанга кайттым. Мин кайтып төшкәндә, Казан урамнарында җепшек кар, урыны-урыны белән чылтырап су ага иде. Икенче төрлерәк әйткәндә, ни арба да ни чана!

Ул вакытта Казанда Партия Үзәк Комитеты нәшрият бүлегенең көнчыгыш (шәрык) халыклары өчен әдәбият тарату филиалы эшли, аның башында Фатих Сәйфи утыра иде. Тапшырасы әманәтләр дә булганлыктан, мин иң элек шунда Фатих Сәйфигә юнәлдем. Ул исәнләшү белән:

— Менә нәрсә: син хәзердән үк Галимҗан Ибраһимовка бар, — диде. — Ул каты авырып ята. Еш кына сезне дә искә ала!

Ул мине, арык кына бер җирән ат җигелгән чанага утыртып, үзе озатып калды.

— Хәзергә бигайбә, безгә дигән автомобиль эшләнеп бетмәгән икән! — дип шаярткан да булды.

Галимҗан Ибраһимов Шиһап Мәрҗани улы Борһан хәзрәт өендә тора икән. Болай квартирасы зарланырлык түгел, җыйнак кына өч бүлмәдән гыйбарәт иде.

Мин барганда, Галимҗан кроватьта ята иде. Ул акрын гына кузгалып, торып утырды да:

— Вакыты-вакыты белән сукыр эчәк бик нык ала шул, — диде. — Шунлыктан кроватьтан төшә алмыйм. Шунда минем яныма гына утыр инде.

Мин аны 1913 нче елдан бирле күргәнем юк иде. Төсенә бик җентекләп карадым. Минемчә, ул болай бик нык үзгәрмәгәнгә охшый. Авыруы көчле генә булуга карамастан, аның күңеле шактый күтәренке, элекке шикелле үк, өске иренең уң як канатын калтыратып, сөйкемле рәвештә елмая-елмая сөйли. Урта Азия хәлләрен кызыксынып сораша, дикъкать белән, бирелеп тыңлый.

— Урта Азиягә бер барып чыгарга дәрт бар да бит, дәрман чаграк шул, — ди.

Аннан соң:

— Без сине байтак заманнар югалтып тордык, — диде. — Кайчагында мин шөбһәләнеп уйлап та куям: бу, мин әйтәм, Кытай ягына шылмады микән, — дим. Күптән түгел монда Әүлиятә шәһәреннән Низаметдин исемле бер карт, элекке тимер юл эшчесе, килгән иде. Ул синең турыда матур гына хәбәрләр сөйләде. Аннан элек бер җыелышта энең дә шулай сөйләгән иде. Шуннан соң тынычланып калдым. Нигә алай бәйләнеш тотмадың! Язган нәрсәләреңне миңа җибәреп торыр идең...

Мин, андагы хәлләрне сөйләп, «мөмкинлек булмады шул!» — дигәч, гафу иткән сымак кияк кагып, канәгатьләнгәнлеген белдерде.

Мин Ташкенттан китәр алдыннан, Шәһит Әхмәдиев, Гомәр Әлмөхәммәтевләр политик яңа бер журнал чыгара башлаганнар иде. (Журналның исеме хәтеремдә калмаган.) Шәһит Әхмәдиев бер хат белән шул журналның беренче санын Галимҗанга биреп җибәргән иде. Галимҗан хаттан да элек шул журналны зур җентекләү белән карап чыкты да:

— Бу малайлар анда яхшы гына эшләп яталар, күрәсең, — дип, шатлыгын белдерде. Мин дә шуны җөпләдем.

Тагын да берничә кеше турында Галимҗан исемнәрен атап сорашты.

Минем, мондый гәпләрдән тиз генә арынып, Гафурилар турында сорашырга йөрәк кыткылдап тора иде:

— Анысы да монысы торсын, — дидем мин, — карт язучыларыбыздан хәзер кемнәр ныграк эшчәнлек күрсәтә!..

— Гафуридан башка, берсенең дә имзасы күренми әле. Ул элеккегә караганда да ныграк терелеп, яңарып китте. Бил бәйләп, җиң сызганып кереште ул каләм эшенә!

Шушы сүзләреннән соң Галимҗан, зур кыенлык белән генә кровате янындагы өстәлгә сузылып, аның тартмасыннан бер кульязма тартып чыгарды.

— Менә бит Мәҗит әле яңа гына бер поэма язган. «Эшче» дип атала. Моннан берничә көн генә элек Уфадан Галә Ходаяров алып килде. Шактый уңышлы нәрсә кебек. Барыннан да бигрәк шунысы әйбәт: Мәҗит бу нәрсәсе белән дә революцияне чын ихлас, зур шатлык белән каршы алганлыгын күрсәтә. Әле мин, син килгәндә генә, шул турыда уйлап ята идем: моңардан сәхнә әсәре эшләгәндә дә, әйбәт кенә бернәрсә чыгар иде, дим.

Ул кульязмаларны миңа тоттырды да:

— Син шуны теге бүлмәдә чәй янында игътибар белән укып чык әле, — диде. — Ә мин бераз гына ял итим!

Ул, бераз гына ыңгырашып, чалкан түшеп ятып калды. Миңа әллә ничек кыен иде. Галимҗанны авыру хәлендә борчуыма үкенгәндәй булдым. Шунлыктан мин, чәй янында поэманы укып бетергәч тә, кульязманы аңа тапшырып, тиз генә китәргә уйладым. Ләкин Галимҗан:

— Тукта әле, кайда ашыгасың! — диде. — Давайте деловой доклад!.. Әллә поэма сине кызыксындырмадымы!

— Кызыксындыру гына түгел, дустым Мәҗитнең уңышлы эшенә куандым!..

— Шулай булгач, фикереңне әйт. Җитешсез җирләре юкмы!

— Минемчә, тулаем алганда, поэма карт бер шагыйрьдән шуннан артык, тагын да сорарлык урын калдырмаган шикелле. Ләкин азагында эшчене авылга кайтаруы бераз сәеррәк кебек...

— Аны син дә сизгәнсең икән әле, — диде Галимҗан һәм минем карашыма тулысынча кушылганлыгын белдерде.

— Мәҗитнең бу хатасы, — диде ул, — һәммәбезгә билгеле нәрсә... Әгәр дә без иске татар мәдрәсәсеннән әдәбият мәйданына үрләгән әдипләргә: «Син, әлбәттә, бүгеннән үк һичбер хатасыз марксизм нигезендә яз!» — дигән таләпне куйсак, бик ялгышкан булыр идек. Безнең моңа хакыбыз да юк, шуның белән бергә, мәсьәләне болай кую зарардан башка бернәрсә дә бирмәячәк!.. Монда төп мәсьәлә шунда: нинди генә яктан карап булса да, карт әдип вә шагыйрьләрнең ихлас күңелдән үз итеп Октябрь революциясен каршы алуларында. Төпле юлбашчылык булганда, алар бу хаталарыннан бик тиз арыначаклар!..

Бу хакта Галимҗан байтак сөйләде. Аннары минем әле генә килеп төшкән кунак икәнемне исенә китереп булса кирәк:

— Мин бүгеннән үк Татсовнаркомга һәм Тат. ЦИК рәисе Борһан Мансуровка хәбәр итәрмен, — диде! — Алар сиңа номер да алып бирерләр, яхшы паекка да беркетерләр...

Кылт итеп исемә килеп төште дә:

— «Казакъ кызы»н таба алдыңмы? — дип сорадым.

— Ул яктан шатлыгым зур, — диде Галимҗан: — Аны таптым табуын да, ләкин тагын бер кабат эшләп чыгып, бастыру чарасын күрә алмыйм бит әле. Менә шушы кәефсезлек юл куймый тора!

Ашау-эчү, квартира мәсьәләләре Галимҗан әйткән рәвештә җайлангач, мин ике көннән соң тагын да аңа бардым. Аңа билгеле булмаган байтак кына хәбәрләр сөйләдем. Урта Азия тирәсендә йөргән татар укымышлыларының төрле язмышларыннан гыйбрәтле үрнәкләр китердем.

— Шулай инде ул, — диде Галимҗан шуларны тыңлагач. — Әнә Кәрим Хәкимов, Шәһит Әхмәдиев шикелле кешеләрнең ихлас хезмәтләренә тап төшерергә маташкан бәндәләр анда аз түгелдер әле. Аларны матбугат аркылы фаш итә торырга иде. Шундыйлар аркасында Урта Азия халыклары белән татар, башкортлар арасында салкын караш туарга мөмкин.

— Дөрес, — дидем мин дә, — мондый хәлләргә бармак арасыннан гына карап, авыз ачып тору ярамый, әлбәттә. Ләкин мин шунысына да ышанам: Урта Азия халыклары ак белән караны яхшы гына аералар!

Галимҗан Ибраһимовның, шактый авыру булуына да карамастан, һәман да иҗат һәм җәмгыять эшендә күп кенә нәтиҗәле эшләр башкарганлыгы, һәрбер әһәмиятле мәсьәлә турында баш ватканлыгы күренеп тора иде.

— Мин карт татар шагыйрьләренең җыентыкларын, шулар белән бергә Бабич шигырьләрен дә җыеп бастыру өчен хәрәкәт итәм әле, — диде ул. — Бик яшьләй һәлак булуына карамастан, Бабич безнең әдәбият бакчасында үзенең сулмас-шиңмәс чәчәкләрен үстереп калдыра алды. Әйдә, аларның элек дөньяга чыга алмый яткан иҗатлары бүген якты дөнья күрсеннәр!

— Бабич бит ул синең шәкертең шул! — дидем мин.

— Юк, — диде Галимҗан, — ул минем дә, Гайнетдин, Фәсхетдиннең дә шәкерте түгел, тормыш, тарих шәкерте. Әйе, без барыбыз да шулай тормыш, тарих шәкертләре!

Иң азагында ул үзенең Сибириядә куркыныч бер хәлдә йөрүе турында сөйләп алды да:

— Артык дәрәҗәдә сак йөрүем аркасында гына шымчылар кулына эләкми, исән-сау әйләнеп кайттым, — диде.

Галимҗанның әйтүенә караганда, аның иң нык сакланган кешеләре Вагыйз Наурузов белән Колчак армиясенең корпус мулласы Габдрәуф Шәһидуллин булганнар.

— Беркөнне, — ди Галимҗан, — банк идарәсендә нәүбәттә торам. Әлеге Вагыйз Наурузов, яшь кенә бер мадамны култыклап, килде дә керде. Аның атаклы провокатор икәнлеген яхшы белгәнлегемнән, эчем жу итеп китте. Җитмәсә тагын, минем кырдан үтеп киткәндә, миңа табан карап куйгандай булды. Гәрчә мин олаучы сыйфатында, танылмаслык рәвештә киенгән-ясалган булсам да, саклыкның зарары юк дип, тиз генә чыктым да сыздым. Таныган булса, һичшиксез, тоттырган булыр иде!

Минем Галимҗанны соңгы тапкыр күрүем 1926 елның җәендә Казанга кайткан чагымда булды.

Казан урамыннан китеп бара идем.

— Бәшири, син түгелме соң бу! — дигән таныш бер тавышка әйләнеп карадым. Урам уртасында канатлы тарантаска җигелгән бер ат туктап тора. Аңа Галимҗан утырган иде.

Мин, ашыгып, янына барып исәнләштем.

— Әйдә утыр! — диде Галимҗан тәкәллефсез генә. — Синең белән озак кына итеп сөйләшәсем килеп йөри иде әле.

Бу чагында Галимҗан Татарстан Мәгариф Комиссариаты янындагы Гыйльми һәйәт (Академцентр) эшләрен алып бара иде шикелле. Шунда аның эш бүлмәсенә киттек.

Башта ул С. Җәләл, Б. Шәриф, И. Биккулов шикелле укымышлылар турында зарланып алды:

— Шуларны эшкә тарту хакында нинди генә чараларны күрмәдем мин! Нинди шартларны таләп итсәләр, шуларның барсын да булдырдым. Ләкин бер генә дә күңел биреп, җиренә җиткереп эшләмиләр. Бу Шәриф дигәннәре, бармак башына чорнарлык белеме булмаса да, татар укымышлыларының намусларын пычратырлык итеп дөнья болгатырга оста!

Шуннан соң ул:

— Аның «Безнең байрак» газетасына үзбәкләр турында язган мәкаләсе үзбәкләрдә нинди тәэсир калдырды! — дип сорады. — Үзбәкләр арасында чын ихлас белән, бәйнәлмиләл дуслык нигезендә эшләп килүче татар, башкорт укымышлыларының эшләренә зарар китермәсме!..

Бу мәкаләнең ничаклы начар эчтәлекле булуы турында сөйләп торасы да юк. Шунлыктан Галимҗанның борчылуы да урынлы иде, әлбәттә.

Соңыннан Галимҗан:

— Татарстанда фән-белем, мәдәният эшләре һаман киңәеп бара, моңа чиксез зур мөмкинлекләр бар, — диде. — Шунлыктан саф күңелдән, зур дәрт белән эшләүче укымышлыларга ихтыяҗ көннән-көн арта. Безнең бит Урта Азиядә йөргән өметле, тотнаклы укымышлыларыбыз да күп кенә. Әнә шуларны Татарстанга кайтару чарасын да күрергә кирәк.

Бу турыда байтак кына сөйләшкән һәм киңәшкәннән соң, мин аңа:

— Ә син минем Татарстанга кайтуыма ничек карар идең! — дидем.

— Бик үк хуплап бетермәс һәм кайтырга ашыгу турында киңәш тә бирмәс идем,— диде ул. — Сәбәбе шул: син — Урта Азиядә электән үк эшләп килгән бер кеше. Син аларның тормышларын, әхвале рухиямәрен яхшы беләсең. Минем ишетүемә караганда, син андагы җирле халык белән яхшы гына аңлашып эшләп киләсең икән. Шунлыктан мин шуны телӛр һәм сиңа шуны тәкъдим итәр идем: син, әлегә анда торып, матбугат-әдәбият аркылы күрше халыклар белән дуслык әмәленчә эш итер идең. Синең татар, башкорт матбугатына — Урта Азия халыклары тормышыннан, андагы матбугатка татар, башкортлар хәленнән язып торуың, минемчә, бер әһәмиятле эш булыр иде.

Тагын ул бераз гына уйланып торды да:

— Менә бит минем башыма нинди бер уй килеп төште, — диде. — иртәгә Кави Нәҗми белән сөйләшим әле. Син чуваш, уйгур, үзбәк әдәбияты турында берәр нәрсә язар идең. Әйдә, эшне шуннан башлап җибәрик!

Билгеле, мин дә моны бик хуп күрдем.

Икенче көнне Кави Нәҗми мине өенә чакырды.

Барсам, аларда карт чуваш шагыйре Полоросов (Шелеби) иптәш утыра иде. Кави Нәҗми аның белән мине таныштырды да:

— Менә бит эш нинди җайлы килеп чыкты! — диде. — Күктән көткән нәрсә җир астыннан үзе чыкты бит әле! Бүген генә әле без, Галимҗан Ибраһимов белән, синнән чуваш, уйгур, үзбәк әдәбиятларына карата берәр нәрсә яздыру турында сөйләшкән идек. Шуннан күп тә үтмәде, менә бу Полоросов иптәш килеп керде. Ул татар, чуваш әдәбияты һәм матбугаты арасында элемтә ясау турында сөйләшү, шуңа нигез салу өчен килгән. Менә бит, — диде Кави Нәҗми, тагын да кайтарып, шатланган рәвештә, — нәкъ менә шушы чорда синең дә Казанга килеп чыгуың уйланып эшләнгәндәй булды.

Икенче көнне без Татарстан китап нәшрияты белән чуваш, уйгур, үзбәк әдәбиятлары турында язу өчен договор ясадык. Һәм мин, Казанда бер айга якын торып, иптәш Полоросовның ярдәме белән, «Чуваш әдәбияты» дигән нәрсәне эшләп бетереп киттем. Уйгур, үзбәк әдәбиятлары турында Ташкентка кайткач язып җибәрдем.

*1959 ел, март, Уфа*

**Ш. Абилов, З. Максудова**

# ЛУТФИ ИДЕЛ БУЙЛАРЫНДА

**Урта гасыр үзбәк поэзиясенең зур вәкиле һәм Идел-Урал буе төрки-татар халыкларының уртак шагыйре Мәүляна Лутфиның тууына 600 ел тулды. Ул XIV—XV йөзләрдә яшәгән төрки шагыйрьләрнең иң күренеклеләреннән. Галишер Нәвои аның турында: «Мәүляна Лутфи үз заманының мәликел-каляме (бөек сүз остасы) ирде, фарси вә төркидә нәзыйре (тиңе) юк ирде, әмма төркидә шөһрәте күбрәк ирде» [1], дип язган. Йөзне яшәгән Лутфи күп санлы газәлләр, робагыйлар, туюглар [2] калдырган һәм «Зәфәр-намә» [3], «Гөл вә Навруз» кебек зур күләмле дастаннар иҗат иткән. Лутфиның мәхәббәт һәм гүзәллек, гаделлек һәм кешелеклелек турындагы газәлләре алты гасыр буена дөнья поэзиясенең матур үрнәкләре булып килгәннәр һәм әле бүген дә үзләренең әдәби кыйммәтләрен югалтмаганнар.**

**Шагыйрьнең «Гөл вә Навруз» дастаны да күпчелек төрки халыкларга мәгълүм булган, борынгы поэзиянең гүзәл үрнәкләреннән саналган. Кызганычка каршы, атаклы дастанның кульъязмалары сакланмаган диярлек. Моңа кадәр аның 1511 елда күчерелгән һәм Британия милли музеенда саклана торган кульъязмасы [4] дөньяда бердәнбер нөсхә саналып килде.**

**Лутфиның безнең көннәргә килеп җиткән әсәрләре 1957 елда үзбәк телендә һәм 1961 елда рус телендә аерым китап булып чыкты [5]. Аларның һәр икесенә, Лондон кульъязмасыннан алынган факсимиле нигезендә, «Гөл вә Навруз» дастаны да кертелгән. «Гөл вә Навруз»ның басылып чыгуы шагыйрьнең башка кульъязмаларын ачыкларга да мөмкинлек бирде. Казанда Гөл белән Наврузның мәхәббәт маҗаралары, аларның гаделлек өчен ничек көрәшүләре турында сөйләгән иске бер кульъязма бар иде. Чагыштырып тикшерә торгач, аның Лутфи дастанының яңа бер күчермәсе икәнлеге беленде [6]. Шулай, «Гөл вә Навруз»ның хәзергә кадәр дөньяда билгеле булмаган яңа**

---

[1] Галишер Нәвои. Мәҗалисен-нәфаис. Ташкент. 1961 ел. 72 бит.

[2] Туюг — өч аваздаш (омоним) сүзе рифмадаш килгән дүрт юллы шигырь.

[3] «Зәфәр-намә» безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән.

[4] Чарльз Рьё. Cataloque of the turkish Manuscripts in the British museum. Инглиз телендә. 1888 ел. III том.

[5] Лутфи. Газәлләр. Робагыйлар. Туюклар. «Гөл вә Навруз». Ташкент. 1957 ел. (Нәшриятка әзерләүче С. Эркинов); Лутфи. Лирика и «Гуль и Навруз» (Составление, предисловие и примечания Э. Рустамова). Мәскәү. 1961 ел.

[6] Лондон нөсхәсенең факсимилен алышуда күрсәткән ярдәмнәре өчен, авторлар Үзбәкстан Фәннәр академиясенең Тел һәм әдәбият институты гыйльми хезмәткәрләреннән С. Эркинов һәм К. Воротникова иптәшләргә тирән рәхмәт белдерәләр.

бер күчермәсе — Идел буе, Казан кульъязмасы барлыкка килде. Хәзерге көндә ул шушы юлларны язучылардан З. Максудова кулында саклана.

Әгәр Лотфиның XV йөзнең беренче чирегендә Сарай шәһәрендә торуын, Болгарда булуын, ул җирләрдәге галимнәр, әдип-шагыйрьләр белән аралашуын һәм әдәби мәҗлесләрдә катнашуын искә алсак, «Гөл вә Навруз» күчермәләренең Идел буенда, татарлар арасында табылуы әллә ни гаҗәп тә тоелмас. Сарай һәм Болгар шәһәрләрендә булганда, Лотфи үзенең аерым әсәрләрен, әйтик шул ук «Гөл вә Навруз»ны якын каләмдәшләренә бүләк итмәгәндер, дип кем әйтә ала!!.



## Кульъязманың тасвирламасы

Төбе киндер җеп белән тегелгән бу кульъязма таушалган, бик иске. Алдан һәм ахырдан байтак битләре төшкән. Исән калганы — 29 кәгазь (58 бит). Урта Азиядә эшләнгән калын, ак кәгазь. Китапның форматы 16 см × 19 см зурлыгында, текст урнашкан өлеше 13 см × 15 см зурлыкта. Һәр биткә нәсх хәтта[1] куе көрән кара белән уртача 14 бәет язылган, барысы 1600 шигъри юл. Лондон нөсхәсендә 2400 юл бар икән.

Кульъязманың 1—2 битләрендә аерым сүзләр генә укырлык. Әмма Лондон нөсхәсе нигезендә ул юлларны да элекке хәленә кайтарып була. Кульъязмада бүлек башлары өчен буш урыннар калдырылган, ләкин исемнәре язылмаган диярлек. Нибары 11 урында бүлек исеме куелган. Аларның икесе генә Лондон нөсхәсендәгегә туры килә. Бер үк әсәр кульъязмаларының фасылларга төрлечә бүленүе һәм бүлек исемнәренең аерылуы күчерүчеләр эше булырга тиеш.

Беренче һәм соңгы битләре сакланмаганлыктан, кульъязманың кайда, кайчан һәм кем тарафыннан күчерелгәнлеге билгесез. Ләкин кәгазьнең искелеге һәм язуына карап, ул XV йөз азагында яки XVI йөзләрдә күчерелгән булыр дип чамаларга мөмкин.

Казан кульъязмасы түбәндәге юллар белән башлана:

سنکا نچه یالینب یالبارایم    نه کم کیلسه ایامنی کورایم
جوسونی کوردی کل وقتی پریشان    ایغان بنی یدین بولدی پشیمان

һәм:

کوروشتی لار صفا برلا همولدم    یراشیب تویلادی لار شاد خرّم
تپکلدی ایکی یاندین بارکاهلار    موافق بولدی ایکی پادشاه لار

диган юллар белән өзелеп кала. Бу юллар Лондон нөсхәсенең 29 һәм 114 нче битләренә туры килә. Ике нөсхәнең һәркайсында шул ук юллар һәм бер үк сүзләр. Бу — Лондон һәм Казан кульъязмаларының бер үк әсәрнең күчермәләре булуын раслый.

---

[1] Почерк төре.

# Казан кулъязмасының кайбер үзенчәлекләре

Әсәрдә эзлекле рәвештә билгеле бер язу кагыйдәләре сакланмаган. Күчерүче профессиональ каллеграф булмагандыр, күрәсең. Лондон һәм Казан кулъязмаларында кайбер сүзләр төрлечә язылган, аерым очракларда теге яки бу сүз башка сүз белән алмашкан. Бу очраклы хәл түгел. Мәсәлән, Лондон нөсхәсендә түбәндәге формаларны очратабыз: айткын, бакгын, кылгын, куналга, күште, эште-ашты, атлык, андак-мондак, катык, сивәк, сивүк, мин, син.

Ә Казан кулъязмасында шул ук сүзләр: айткыл, бакгыл, кылгыл, кунарга, күчте, әчте-ачты, атлыг, андаг-мондаг, катыг, сөнгәк, сәвүк, мән, сән рәвешендә язылган.

Мондый үзенчәлекләрне күчерүченең Идел буе болгар-кыпчак язма (иске татар әдәби) теленең стабильләшкән традицион нормаларын сакларга тырышуы белән аңлатырга мөмкин. Шул ук вакытта Лутфи әсәрләрендә Идел буе төрки теленә хас элементларның шактый урын алуын да инкарь итеп булмый[1]. Шагыйрь болгар-кыпчак (татар) телен, әдәбиятын яхшы белгән, һәм бу хәл аның лексикасына тәэсирсез калмагандыр, билгеле. Лутфи теленең татар укучысына бүген дә яхшы аңлаешлы булуы сәбәпләренең берсе шунда булса кирәк.

Лондон кулъязмасында бүлекләр алмашынган, буталган, әсәрдә эзлеклелек бозылган. «Гөл вә Наврүз»ны матбугатка әзерләгәндә, С. Эркинов һәм Э. Рустамов, сюжет юнәлеше һәм эчтәлегеннән чыгып, аны тиешле хәленә китерергә тырышканнар. Казан кулъязмасы Лондон нөсхәсенең аерым урыннарын тулыландырырга да ярдәм итә. Лондон нөсхәсенең 64 битендәге шигъри юлларда кайбер сүзләр язылмый калган:

Нә колкем буйны[2] баглык бер этем сән,
Саңа. . . . . . . . ук берлә кем сән;
Әгәр синдин йәнә бер эш табаен,
. . . . . . . . . . . чабаен.

Дастанның 1957 елгы Ташкент басмасында (139 бит) ул урыннарга куелып язылган сүзләр квадрат җәяләрдә күрсәтелгән.

Нә колкем буйны баглык бер этем сән,
Сәнгә [нә хәд, бу колл] ук берлә кем сән?
Әгәр сәндин йәнә бер эш тапаен,
[Каның акызубан буйның] чапаен.

Ә Казан кулъязмасында (3 а бит) ул строфа түбәндәгечә:

Нә кол кем буйны баглык бер этем сән,
Саңа **тикмәс фозуллык**[3] берлә кем сән?!
Мәгәр сәндин янә бер эш табаен,
**Үз илкем**[4] берлә уртадин чабаен.

---

[1] В. А. Артамошина. Условия формирования и некоторые особенности языка среднеазиатских поэтов — предшественников А. Навои («Тюрко-монгольское языкознание и фольклористика». Мәскәү. 1960 ел. 21—28 битләр).

[2] Буйны — муен.

[3] Фозуллык — әрсезлек.

[4] Илкем — кулым.

Тагын бер мисал китерик. Лондон нөсхәсендә шундый юллар бар (76 бит):

Ятып ятканларыны күргәч ул дәм[1],
Ятыр йирдә тотып багладьı мәхкәм[2].


Лутфи кебек нечкә тойгылы шагыйрь «ятып ятканнарыны» дип әйтмәс. Биредә сүз Гөл һәм Наврузның, озак баргач, туктапып, качып (тынып) ятулары хакында бара. Шул вакыт аларны чик сакчылары тотып бәйлиләр. Казан кулъязмасында (17 а бит) ул болай язылган:

Тынып ятканларыны күргәч ул дәм
Ятыр йирдә тотып баглады мәхкәм.

«Тынып ятканнарыны» дип әйтү төгәлрәк тә, дөреслеккә дә якынрак килә.

Казан кулъязмасы Лондон нөсхәсенә әнә шундый характердагы кайбер ачыклыклар кертә һәм киләчәктә, билгеле бер дәрәҗәдә, «Гөл вә Навруз» дастанының фәнни текстын булдырырга мөмкинлек бирәчәк. Ләкин Казан кулъязмасының әһәмияте моның белән генә чикләнми.

«Гөл вә Навруз» дастанының икенче бер кулъязмасы Идел буенда, Татарстанда, табылуының гаять зур әһәмияте бар. Ул, берьяктан, фәнгә төрки телләрнең үсү эволюциясе һәм аларның аерым өлкәләрдә ничек формалашуы хакында материаллар бирсә, икенче яктан, татар һәм үзбәк халыкларының әдәби-мәдәни бәйләнешләренең ерак тарихлары турында сөйләргә дә мөмкинлекләр ача.



Казан нөсхәсенең бер бите.

## Татар поэзиясендә Лутфи эзләре

Лутфиның «Гөл вә Навруз» дастаны төрки халыклар арасында гаять популяр булган һәм гасырлардан гасырларга сөелеп укылып килгән. Укучының күңелен ләззәтләндергән бу әсәр галимнәр өчен матур үрнәкләр чыганагы, шагыйрьләр өчен илһам чишмәсе булган. Төрки шагыйрьләр, Лутфи мирасындагы поэтик энҗеләрдән файдаланып, үз әсәрләрен бизәгәннәр һәм, Лутфи ирешкән югарылыкка карап, шигърият күгенә үрмәләгәннәр[3]. Лутфи «Абушка» авторына да, 1560 елда «Лөгате Нәваия вәл-Истишһадате Чыгтаия»не төзегән Казвин шәһәренең төрки әдибе Галяи бине Мохибби эш-Шәрифкә дә, Л. Будагов һәм Ф. Корш кебек рус галимнәренә дә, «Кәнзел-лөгат» нясенә дә таныш булган.

Лутфины татар халкы да күптәннән белгән һәм якын иткән. Аның гаҗәеп матур шигърият дингезеннән шагыйрьләребез илһам ала килгән. Казан ханлыгында яшәгән

---

[1] Ул дәм — шул вакыт.
[2] Мәхкәм — нык.
[3] Харәзем шагыйре Мәҗлиси үзенең «Кыйссаи Сәйфел-мөлек» әсәрен «Гөл вә Навруз» үрнәгендә язганлыгын әйтә. (Кыйссаи Сәйфел-мөлек. Казан университеты басмасы. 1849 ел. 6 бит.)

зур талант иясе, шагыйрь Мөхәммәдъяр Лутфи әсәрләрен яхшы белгән, хәтта «Гөл вә Навруз» дастаныннан иҗади файдаланган. Бу бигрәк тә аның «Нуры содур» (1542 ел) поэмасында ачык күренә. Поэманың аерым мисрагълары «Гөл вә Навруз»дагы юлларны хәтерләтә. Әсәрнең хатимәсе — соңындагы 10 бәет «Гөл вә Навруз»дан үзгәрешсез күчерелгән дияргә мөмкин.

Бу — Лутфи «Гөл вә Навруз»ының татар шагыйре иҗатына булган тәэсирен раслый торган ачык дәлил. Димәк, «Гөл вә Навруз»ның идея юнәлеше, әсәрдәге мәхәббәткә турылык, кешене олылау һәм ил белән идарә итүдә гаделлек принциплары Мөхәммәдъярның дөньяга карашларына, философик фикерләренә дә, «Нуры содур» поэмасының рухына да тәэсир иткән.

Соңгы чор татар әдипләре, шагыйрь һәм галимнәре дә Лутфины яхшы белеп, аңа зур ихтирам белән караганнар. Шагыйрьләрдән Бәшир бине Габдулла (XVIII йөз), Габделҗаббар Кандалый (XIX йөзнең беренче яртысы) үзләренең аерым әсәрләрен Лутфига мөрәҗәгать итеп язганнар. Борынгы татар кульязма китапларында да Лутфи шигырьләреннән теркәмәләрне очратып була.

Шулай итеп, Идел буенда яшәгән укымышлы кешеләр арасында Лутфиның диваныннан яки «Гөл вә Навруз» дастаныннан берничә мисрагъ — юл булса да белмәгән кеше аз булгандыр. Шагыйрь халык күңелендә зур хөрмәткә ия булган, югары дәрәҗәдә саналган. Атаклы галим Каюм Насыйри, «Ләһҗәи татар» сүзлегенең керешендә төрки халыкларының нәфис сүз сәнгатен һәм әдәби телләрен үстерүче бөек шагыйрьләрне санап үткәндә, беренче урында Лутфиның исемен атаган, аннан мисаллар да китергән. «Чыгътай теленә хезмәт итүчеләрдән, — дип яза ул,— Лутфи, Нәвои, солтан Бабер... кебек мәшһүр мөсәннәфләрдер[1] ки, чыгътай теле аларның мөсәннәфаты белән мәгъмур булмышдыр»[2].

Лутфи шигырьләренең 1914 елда Казанда «Өмет» матбагасында басылып чыгуы да шагыйрьнең татарлар арасында популяр булуы турында сөйли.

◇◆◇

---

[1] Мөсәннәф — иҗат итүче, язучы.
[2] Каюм Насыйри. Ләһҗәи татар. Казан университеты нәшрияты. 1895. 3 бит.

# «ГӨЛҖАМАЛ»

Бу җырны, танылган вокал осталары белән бергә, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар да яратып башкаралар. «Гөлҗамал» гасырлар буенча халык иҗат иткән озын көйләрнең иң матурлары рәтенә керә ала.

Күп еллардан бирле нәселдән-нәселгә мирас булып килгән көйләрнең кайда, кайчан, кем тарафыннан иҗат ителүен табу, тулысынча исбат итү күп очракта мөмкин дә булмый. «Гөлҗамал» — саф татар җыры. Ләкин аның да башлама тарихы билгесез, хәтта легендасы да юк.

Сүз дә юк, «Гөлҗамал» — бик борынгы җыр. Моны аның көе генә түгел, сүзләре үк күрсәтеп тора. Көе кебек үк, җырның сүзләре дә — үзенә генә хас борынгы сүзләр. Мин «Гөлҗамал» җырының, халык көйләре арасына кереп, җырчылар репертуарында үзенә төпле урын алуы тарихын сөйләп бирергә телим. Бәлки, минем истәлегем бу гаҗәеп көйнең тарихын ачыкларга ярдәм итәр.

1929—1931 елларда мин, үземнең бертуган энем Хәмит Таһиров белән бергә, Үзбәкстанның Хива шәһәрендә укытучы булып эшләдем. Хәмит тә укытучы иде. Шуның өстенә, ул кечкенәдән үк җырга һәм бигрәк тә инструменталь музыкага һәвәс булды. Нинди генә коллективта эшләмәсен, Хәмит иң элек үзешчән сәнгать эшен юлга сала: оркестр, хор төзи, музыкаль драма әсәрләрен уйнауны оештыра иде.

Шулай бер вакыт бик ашыгып кайтып керде дә мине үзе белән якындагы клубка барырга чакырды. Ул артык дулкынланган, дәртләнгән һәм бик кабалана иде. Клубка барып җиткәнче: «Энҗе! Җырлар, көйләр энҗесе! Бәлки, син, апа, әлегрәк берәр җирдә ишеткәнсеңдер! Көен булмаса, сүзен, сүзен булмаса, шундый җырның барлыгын беләсеңдер. «Энҗе лә мәрҗән кызларның кулбавы», ди-ди, ярсып сөйләнә килде. Клубка килгәч, ул мине уртача буйлы, зур мыеклы, кыяфәте белән элекке интеллигентларга охшаган, 45—50 яшьләрдәге чит-ят бер кеше белән таныштырды. Фамилиясе — Вахитов, укытучы икән... Кызганычка каршы, исеме хәтердә калмаган. Хәзер хәтта нинди мәктәптә эшләгәнен дә искә төшерә алмыйм. Әмма шунысы истә, алар хатыны Газизә апа белән күп еллардан бирле Хивада яшәгән кешеләр иде.

Вахитов белән Хәмит моннан бер-ике генә сәгать элек һәм бөтенләй очраклы рәвештә танышканнар икән. Инде үзләрен дуслаштырган җырны миңа да тәкъдим итәләр. Мин караңгы залга кереп урнаштым. Хәмит, түземсезлек белән рояльгә утырып, бу ят көйне уйный да башлады. Вахитов абый сокландыргыч моңлы тавыш белән җырлап җибәрде:

Шәмдекләрдә генә шәмнәр яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр,
Энҗе лә мәрҗән кызларның кулбавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы...

Мин, җыр башкарылып беткәнче үк, туганымның нәкъ шулай дулкынлануын аңлаган идем инде. «Гөлҗамал» — зур музыкаль табыш иде.

Мин җырга, моңга бай Башкортстанда үстем. Күп мәртәбәләр Уфада, Казанда булып, ул заманның танылган җырчылары Абруй ханым Сәйфи, Әминә ханым Бәхтизина, Фәттах ага Латыйпов һәм Газиз ага Әлмөхәммәтов концертларын тыңлаганым бар. «Гөлҗамал»дай җырны ишеткәнем юк иде. Юк, «Гөлҗамал» гади бер көй генә түгел. Ул кышкы озын төннәрдә зур

түземлек, осталык таләп иткән авыр хезмәт процессында хокуксыз татар кызларының ачы язмышларыннан зарлану темасына багышланган тулы эчтәлекле, зур полотнолы сәнгать әсәре. Гүя алар — «шәмдекләрдә генә» янган шәм яктысына җыелган татар кызлары — матурлыгы белән генә түгел, акылы белән дә танылган шәфкатьле Гөлҗамалдан үз язмышларын бәхетле итүен үтенәләр, киңәш сорыйлар, ялваралар...

«Гөлҗамал»ның хәзер җырлана торган сүзләре дә теге вакытта Вахитов башкарганча ук диярлек. Тик «шәмдек», «сәүгәннәрнең» сүзләре генә әдәбиләштерелгән. Аннан соң җырдагы икенче куплетның кушымтасы [припевы] безнең дәвер тыңлаучыларына гаҗәбрәк, көлкерәк тоелыр төсле булгач, без халыкка чыгарыр алдыннан аны кыскартырга булдык. Ул кушымта болай иде:

Яшь егетләр кызларның мулласы,
Насыйп кына итсен лә мәүласе.

Бу строфада «мулласы» дигән сүз кызларның кумиры мәгънәсендә әйтелгән. Мәүласе — алласы дигән сүз.

1934 елда без Казанга кайттык. Хәмит Таһиров, мәктәпкә эшкә урнашкач та, укытучылар йортындагы үзешчән сәнгать коллективларының эшенә катнашып китте. Озак та үтми, ул радиокомитет эшчеләре Әхмәт Сафин, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Халикова, Фиофана Терновская һәм башка иптәшләр белән танышып алды. Иң башлап Хәмит Гөлсем ханым Сөләймановага «Гөлҗамал» җырын өйрәтте. Яңа җыр радиодан тапшырылганда, үзе берничә мәртәбә рояльдә уйнады. Бөек Ватан сугышы башлану белән, Хәмит Кызыл Армиягә алынды. Артиллерия офицеры Таһиров 1943 елда Курск шәһәрен яклаганда һәлак булды.

Гөлсем Сөләймановадан соң «Гөлҗамал» байтак еллар буена яңа башкаручылар тапмады. Ул, ничектер, онытылып ятты. Моның сәбәбе, бәлки, көйнең җырчыдан зур осталык таләп итүендәдер. Хәзер исә бу көй татарларга гына түгел, башка милләт халыкларына да якыннан таныш һәм таныш. И. Шәмсетдинов аны симфоник оркестр өчен эшкәртте. Композиторның бу хезмәте тирән ихтирамга лаек. Көйнең нәфис эшләнүе, драматик яңгырашы сүзсез дә көчле тәэсир калдырырлык.

Г. ТАҺИРОВА.

# ТӨРЕК ХАЛЫК МӘЗӘКЛӘРЕ

## Нәкъ шулай, генерал җәнапләре

Сәлим III патшалык иткән заманда регуляр гаскәр солдатлары хәрби эшкә Европача тәртиптә өйрәнә башлаганнар. Бер ротада Мәхмүт исемле аңгырарак бер солдат булган. Алдагы көндә ротаны генерал килеп тикшерәсе икән. Шуңа күрә рота командиры Мәхмүтне бер читкә чакырып алган да әйткән:

— Әйбәт кенә тыңлап тор. Генералның сиңа сораулар бирүе бар, ничек җавап кайтарырга кирәклеген өйрәнеп, ятлап куй. Иң элек ул: «Армиядә ничәнче ел хезмәт итәсең?» — дип сорар, аннары: «Сиңа ничә яшь?» — дияр. Шуңа күрә беренче соравына: «Бер»,— дип җавап бирерсең, икенчесенә: «Егерме биш», — диярсең. Калган сорауларының барысына да: «Нәкъ шулай, генерал җәнапләре», — дип кенә җавап кайтарырсың, — дигән.

Ул төнне Мәхмүт таң атканчы йокламый, бертуктаусыз җавап сүзләрен ятлый. Иртән ротаны тезеп куялар. Генерал килеп тикшерә башлый. Шунда, үч иткән кебек, ул Мәхмүтнең каршысына ук туктый да:

— Сиңа ничә яшь, улым? — дип сорый.

Мәхмүт күзен дә йоммыйча.

— Бер, — дип җавап кайтара.

Генерал сәерсенеп куя. Икенче сорауны бирә:

— Армиядә ничәнче ел хезмәт итәсең?

— Егерме биш, — ди Мәхмүт.

Генералның ачудан бузарынып:

— Минем белән шаярмакчы буласыңмыни син?! — дип кычкыруына каршы Мәхмүт:

— Нәкъ шулай, генерал җәнапләре!— дип чатнатып җавап кайтара.

## Бер гаебе дә юк микәнни?

Төнлә бер кешенең йортына карак кереп, бөтен әйберләрен урлап чыккан. Иртән торгач, йортның хуҗасы, әйберләре урланганлыгын күреп, полициягә хәбәр иткән. Аның кайгысын уртаклашырга тирә-күршеләре дә җыелган.

— И ходаем, бу кадәр дә сансыз кеше икәнсең, ишегеңне бикләмичә йокларга ярыймы инде, — дигән берсе.

— Коймаң бу кадәр тәбәнәк булмаса, йортыңа гомердә дә карак керә алмас иде, — дигән икенчесе.

— Карак әйберләреңне җыеп алып чыкканда да берни ишетмәдеңмени? Шулхәтле каты йоклый торган кеше буламыни?! — дигән өченчесе.

Эченнән ут йотып торган хуҗа түзмәгән:

— Әй, дусларым, бөтен гаеп үземдә икәнен бик беләм мин. Ә менә йортымны басып чыккан ул каракның бер гаебе дә юк микәнни? — дигән.

## Шуннан гына кабызып булмый идемени?

Каллиграф Есаризадә бервакыт каты давылда Босфор култыгында көймәдә йөзүен танышларына болай дип сөйли икән:

— Әфәнделәр, мин уразада авыз ачарга дип өйгә кайтып килә идем, давыл чыгу сәбәпле соңга калдык, туплар атканны да[1] юлда гына ишеттек. Яныбызда авыз ачарлык ризык юк иде, шул сәбәпле мин трубка тартырга булдым. Бөтен шырпымны сызып бетерсәм дә, каты җилдә трубкамны кабыза алмадым. Валлаһидыр, дулкыннар шулкадәр биек иде, безне уртак өй мәчете манарасындагы ут биеклегенә күтәрә иде.

Аның сөйләвен бик бирелеп тыңлап торучылардан берәү түзмәгән:

— Мөгаллим, сез анда кадәр менеп җиткәч, нигә шул утка гына үрелеп трубкагызны кабызмадыгыз? — дип сораган.

## Ике ялганчы

Бер ялганчы икенчесенә болай дип сөйли икән:

— Кичә бер авылдан узып барганда берәүнең бакчасында бик зур бер кабак күрдем. Каршыга кәрван булып дөяләр килә иде. Бер дөя кабакның кырыен китеп алып, тишек ясады. Шуннан дөя кабакны ашаган саен тишек зурая барып, дөя үзе бөтенләй кабакның эченә үк кереп китте. Аның артыннан башка дөяләр дә кереп киттеләр. Таулар арасына утынга баручы бер утынчы кабакның сабагын чабып алмакчы булып кизәнгән иде, кулыннан балтасы ычкынып китеп, кабак эченә кереп китте. Утынчы балтасын эзләп үзе дә кабак эченә керде. Шунда ул дөяләр йөртүчегә очрады. «Әй, карале, ни эзлисең син монда?» — дип сорады аннан дөяләр йөртүче. «Балтамны югалттым әле, шуны эзлим», — дип җавап бирде утынчы.

— Исең киткән балтага! Мин менә бер кәрван дөяләремне югалттым әле, иртәдән бирле эзләп тә таба алмыйм, ә син кечкенә генә балтаңны тапмакчы буласың, — ди дөяләр йөртүче.

Икенче ялганчы моны тыңлап тора да үз нәүбәтендә болай дип сөйләп китә:

— Кичә бер тимерче алачыгында бер казан күрдем. Ике яктан ике тоткасын ике тимерче эшләп ята. Боларның аралары шулхәтле ерак, бер тимерче икенче тимерченең чүкеч сукканын да ишетерлек түгел.

— Арттырасың да инде, дөньяда шундый зур казан буламыни? — ди шунда беренче ялганчы.

— Ә син ул кабакны нәрсәгә салып пешерерсең соң? — дигән моңа каршы икенче ялганчы.

---

[1] Төркиядә ураза аенда авыз ачар вакыт җиткәнне белгертеп туптан ата торган булганнар.

# Болар да бүрек

Бер саран казый, материя сатып алып, бүрекчегә бүрек тектерергә килә. Ләкин, материалны аның кулына тоттырганчы, күңеленнән нидер уйлап-исәпләп тора да:

— Ничек уйлыйсың, шушы кисәктән ике бүрек тегеп булырмы? — дип сорый.

— Бик була, — ди бүрекче.

Казый тагы да комсызлана, шуннан соң:

— Ә өч бүрек чыгарып булмасмы? — дип сорый.

«Була» дигән сүзне ишеткәч, ул, батыраеп китеп, дүрт бүрек, биш бүрек, алты бүрек тегеп булмасмы? — дип тезеп китә. Бүрекче «була» дип башын гына селкеп тора. Ахырында, унга житкәч, туктыйлар. Казый, бик сөенеп, өенә кайтып китә. Әйтелгән көнне бүрекчегә килә. Бүрекче моның алдына йодрык чаклы гына ун бүрек чыгарып салгач, казый аптырап китә:

— Бу ни бу? — ди.

— Ни булсын, бүрек, казый әфәнде, — ди бүрекче.

— Бүрек икәнен күрәм дә, минем башка сыймый бит болар, — ди казый.

Бүрекче моңа каршы тыныч кына.

— Син бит үземә тектерәм дип әйтмәдең. Фәлән чаклы бүрек тегеп буламы? дип кенә сорадың. Менә мин сиңа шул чаклы бүрек тектем инде... — дигән ди.

# Без дә берәр тапкыр үлеп карыйкчы

Сый яратучы берәү уразада үзенең берничә дустын авыз ачарга кунакка чакырган. Табынга бик күп төрле сый — ризык куелган. Иң азактан җимеш суы китергәннәр. Борыннан килгән гадәт буенча җимеш суын, һәркем кашыгы белән үрелеп алсын дип, табын уртасына куйганнар. Тик бер җайсызлыгы килеп чыккан: кунакларга кечкенә бал кашыклары гына биргәннәр. Болар тамчылап-тамчылап кына эчеп утырганда хуҗа үзе җимеш суын аш булә торган чүмеч чаклы дәү кашык белән чүмерә икән, өстәвенә җимеш суын эчеп җибәргәч: «Ах, үләм инде, үләм», — дип куя икән.

Табында утыручыларның берсе ахырда түзмәгән:

— Әфәндем, шул кашыгыңны безгә дә биреп торчы, без дә берәр тапкыр үлеп карыйкчы, — дигән.

# Истамбулдан кайткан

Бер карт кына хатын Истамбулдан кайткан энекәше белән сөйләшеп утырганда:

— Истамбулда нинди яңалыклар бар соң, сөйлә әле! — дип үтенгән.

Энекәше хәйләкәр һәм шаян бер егет булып, апасына:

— Валлаһи, искитәрлек берни дә юк анда, тик соңгы вакытта бер хикмәт уйлап чыгарганнар: карт хатыннарны яшь егетләргә, ә кызларны минем бабай яшендәге картларга бирәләр икән, — дигән.

Карт хатынның буйга җиткән кызы да шунда икән. Бу сүзләрне ишеткәч, кыз, хәтере калып:

— Тузга язмаганны сөйләмә! — дип әйтеп куйган.

Хатын шунда кызын ачуланып:
— Һи, надан, тик кенә тор, ни беләсең син?! Бу кеше бит Истамбулдан кайткан! — дип әйткән ди.

## Үз улчәве

Көннәрдән бер көнне эчкече Мостафа каты авырып киткәч, моны дәваларга доктор чакырталар. Доктор, авыруны әйбәтләп карый да әйтә:

— Синең бөтен эчке әгъзаң эштән чыккан. Әгәр дә шушылай дәвам итсәң, озакламый аягыңны сузарсың. Сиңа хәзер аракының тамчысы да ярамый, — ди.

Моңа каршы Мостафа, ялварып:

— Әфәнде, җиргә ятып аягыңны үбәм, тик тамагымны чылатыр өчен әз генә эчәргә рөхсәт ит инде, мин аны берьюлы ташлый алмыйм, — ди.

— Яхшы алайса, сиңа көненә ике бармак иллесе генә эчәргә рөхсәт итәм, шуннан артыгы бер тамчы да ярамый, — ди доктор.

Беркадәр вакыттан соң Мостафа тагы авырып китә, тагын доктор чакырталар.

— Син мин әйткәнне тыңламагансың, тагы эчкәнсең, ахры, — ди доктор.

— Валлаһи, сезнең бөтен киңәшегезне төгәл үтәдем, ике бармак иллесеннән артык бер тамчы да эчмәдем,— ди Мостафа.

Шуннан соң доктор: «Кая, үлчәп эчә торган савытыңны күрсәт әле», — дигәч, эчкече Мостафа аның алдына кер юа торган ләгән китереп куйган ди.

## Ике генәме?

Көннәрдән бер көнне таз малай базарга килгән. Караса, бер кибетнең эче буп-буш, анда сатучы белән аның өйрәнчеге генә кара-каршы утырып торалар. Таз малайга бу хәл бик кызык тоелган һәм ул ишекне ачып:

— Биредә ни сатасыз? — дип сораган.

Сатучы шаяртып:

— Ишәк сатабыз! — дип җавап биргән.

Таз малай бераз уйланып торган да:

— Ике генә башмыни, тагы юкмы соң? — дип сораган.

## Чикләвек белән кабак

Бер кеше бакчада чикләвек агачы астында ял итеп ята икән. Шунда аның нечкә генә сабакларда үскән зур-зур кабакларга күзе төшкән. Аннары башын күтәреп, агачтагы вак кына чикләвекләргә караган.

— И алла, бу дөнья ник бу кадәр сәер яратылган? Менә бу дәү кабаклар зур агачка, ә вак чикләвекләр әнә теге нечкә сабакларга күбрәк килешә түгелме? — дигән. Шулай дип уйлауга, бу кешенең башына агачтан бер чикләвек килеп төшкән.

— И мәрхәмәтле алла, дөньяны бик дөрес кылганыңа тагын бер тапкыр ышандым. Әгәр дә бу агачта чикләвек урынында кабак булса, минем бу мескен баш нишләмәс иде икән?— дигән ди бу кеше.

# Карт шаһитләр

Бер кеше суд дәгъвасы белән казыйга мөрәҗәгать итә. Эш дәгъвалы булганлыктан, бу кеше казыйны үз ягына аудару чарасына керешә. Бер поднос баклава [1] сатып алып, шуларның һәр кайсына берәр алтын тәңкә сала да шуны бүләк итеп казыйга җибәрә. Суд ишеге төбендә подносны суд приставына тапшыралар. Пристав, ашамлыкка бик кызыгып, бер баклаваны кабып карый һәм ниндидер бер каты әйбер тоя. Әйбернең алтын тәңкә икәнен күргәч, тиз генә кесәсенә сала. Тагын бер баклаваны кабып карый һәм тагы алтын тәңкә табып, кесәсенә сала. Шулай итеп, пристав дүрт алтын тәңкәне кесәсенә сала да, баклаваларны баштагыча итеп төзәтеп куеп, казыйга кертеп бирә.

Казый дәгъвачы кешедән суд көнендә ниләр әйтәчәксен дип сорагач, дәгъвачы:

— Бу эштә мин хаклы, минем кырык шаһитем бар, — ди.

Казый алдындагы кәгазьгә карый да:

— Юк, углым, биредә утыз алты шаһит кенә теркәлгән, — ди.

Шул чакны почмакта утырган пристав сүзгә кушыла:

— Дөрес, шаһитләр кырык иде. Дүртесе бик карт кеше булганлыктан, баскычтан өскә менә алмаслар дип, мин алардан аста гына сорау алдым, — ди.

# Еласам да барам

Бер авыл кызын кияүгә биргәннәр. Кыз, елый-елый, кияү йортына күрше авылга китәргә җыена. Кызның этисе йомшак күңелле кеше икән. Кызының елаганын күрә дә әйтә:

— Юк, мин бу хәлгә түзә алмыйм: кызым елый икән, ризалыгымнан кире кайтам, кызым өйдә генә торсын, — ди.

— Әти, минем елавыма исең китмәсен. Мин, еласам да, үзем теләп барам, — дип әйткән ди кыз.

# Хафиз әфәндегә кофе китерегез

Төрек телен белми торган бер кеше казыйга килеп, үзенең дәгъвасын саф гарәп телендә сөйли башлаган. Казый аны бүлдермичә бик озак тыңлап торган. Әлеге кеше сүзен бетергәч, казый, моны коръән укыды дип белеп, «амин!» дигән дә суд приставына таба борылып:

— Хафиз әфәндегә бер чынаяк кофе китерегез, — дигән.

# Дәүләт кушканга

Көннәрдән бер көнне Истамбул кешесе бер авылга килеп эләккән. Бу авыл халкы аракының ни икәнен дә белми икән. Авыл агайлары белән исәнләшеп, танышканнан соң, Истамбул кешесе кәрзиннән ашамлыклар чыгарган, алдына бер шешә аракы да алып куйган. Шуннан соң аракыны рюмкага салып, су белән кушкан. Авыл агайлары ап-ак төскә кергән бу эчемлек белән кызыксынып, Истамбул кешесеннән: «Нәрсә бу?» — дип сораганнар.

— Аракы булыр бу! — дигән Истамбул кешесе һәм шундагы бер агайга да салып биргән.

[1] Баклава — чикләвек төше һәм бал белән пешергән сумса.

Авыл агае аракыны кабып караган да шундук кире төкереп:

— Хөрмәтле бәй, сез моны үзегез теләп эчәсезме, әллә дәүләт кушкангамы? — дип сораган ди.

## Фәрман булгач...

Ике кеше талашып киткәннәр. Шунда берсе икенчесен кыйнап ташлаган. Боларның икесен дә тотып казыйга китергәннәр. Кыйналучы казыйга үзенең шикаятен сөйләп биргән. Кыйнаучы кеше исә:

— Минем кулымда фәрман бар, менә ул, — дип, казый алдына кәгазьгә төргән биш алтын тәңкә китереп куйган.

Казый кәгазьнең авырлыгын чамалап караган да кыйналучы кешегә таба борылып:

— Карале, углым, дәгъвалашып юкка вакыт әрәм итмә, бу кәгазь белән ул сине дә, мине дә җиңәчәк, — дигән.

## Башлый да ташлый

Бер көнне бер ир хатынын болай дип шелтәләргә керешкән:

— Хатын җаным, ник бу кадәр көнче син! — дигән. — Музыка белән шөгыльләнә башлаган идең, ташладың; француз телен өйрәнәм дигән идең, ул уеңнан да кире кайттың; тегү эшенә өйрәнергә керешкән идең, ул ниятеңнән дә ваз кичтең; балам булсын дип теләгән идең, ике ай узмады, ул теләгеңнән дә кайттың...

Хатын түзмәгән, иренә ябырылып:

— Туктыйсыңмы, юкмы? Буып үтерәм бит! — дигән.

— Исем дә китми, син бу эшеңнән дә ярты юлда туктап калачаксың, — дигән ди ире тыныч кына.

## Кем өчен сайраган

Ике авыл агае агач күләгәсендә ял итеп яталар икән. Шул вакыт агачтан чут-чут итеп сандугач сайравы ишетелгән.

— Бу кош минем өчен сайрый бит, — дигән берсе.

— Юк, минем өчен сайрый, — дигән икенчесе.

— Минем өчен, минем өчен генә, — дип үз сүзен иткән беренчесе.

— Юк, — минем өчен генә, — дигән икенчесе.

Шулай бәхәсләшә торгач, болар талашып ук киткәннәр. Берәүнең дә сүзен бирәсе килмәгән. Шулай итеп, эш судка барып җиткән.

Бәхәсләшүчеләрнең берсе, каз алып, казыйга барган. Иртәгесе көнне икенчесе казыйга күркә илткән. Шуннан соң болар судка килеп, казыйга үзләренең дәгъваларын сөйләп биргәннәр һәм казыйдан сандугачның кем өчен сайраганын әйтеп бирүен сораганнар.

— Ул сандугач сезнең берегез өчен дә сайрамаган. Чын дөресен беләсегез килсә, әйтим: ул кош минем өчен сайраган, — дигән казый.

## ...дисәләр, ышанма!

Бер кибет хуҗасына таможнядан пыяла әйберләр салган зур гына сандык чыгарып биргәннәр. Кибет хуҗасы сандыкны кибеткә күтәреп илтер өчен кеше чакырткан да:

— Сандыкны кибетемә илткән өчен сиңа ни бирим: бер лира акчамы, әллә яхшы киңәшме? — дигән.

Сандыкны илтүче кеше кызыксынып:

— Ярый, яхшы киңәш булсын, — дигән.

— Беренче киңәшемне хәзер әйтермен, икенчесен юлда, өченчесен кибеткә кайтып җиткәч әйтермен, — дигән сандык хуҗасы.

Ялланган кеше сандыкны аркасына күтәргәч, кибет хуҗасы:

— Тыңла: «Бай булганчы ярлы булу яхшырак», дип әйтсәләр, ышанма! — дигән.

Шуннан соң болар кузгалып киткәннәр. Ярты юлга җиткәч, кибет хуҗасы:

— Тыңла: «Өйләнеп яшәгәнче, өйләнми яшәү яхшырак», дисәләр, ышанма! — дигән.

Кибеткә кайтып җиткәннәр. Өске каттагы складка менгәннәр. Баскыч төбенә җиткәч, сандыкны күтәреп килүче кеше:

— Инде өченче киңәшеңне дә әйт, — дигән.

— Бел: «Җәяү йөрү трамвайга утырып йөрүдән яхшырак», дисәләр, ышанма! — дигән кибет хуҗасы.

Сандыкны китерүче кеше, моның өченче киңәшен ишеткәч, сандыкны җиргә атып бәргән дә әйткән:

— Бел, әгәр дә бу сандыгыңда берәр әйбер исән калган дисәләр, ышанма! — дигән ди.

## Бөтенләй койрыксыз булганмыни?

Бер кешенең ялганчылыгы белән даны чыккан. Ялганлый башласа, ул, кызып китеп, чамасын югалта икән. Аның бу сыйфатыннан кешеләр көлгәнен үзе дә белә икән. Шуңа күрә ул, ялганлый башласам, тамак кырып миңа сиздерерсез дип, ялчысына әйтеп куйган.

Бер көнне мәҗлестә, аштан соң кофе китергәч, ул үзенең кунакларына болай дип сөйләргә керешкән:

— Кичә кием шкафыннан бер күсе килеп чыкты. Алдашмыйм, койрыгы бер ун аршын бар иде, — диюгә, ялчысы тамак кырып куйган.

— Ягъни, биш метр озынлыгы иде,— дигән бай.

Ялчысы тагы тамак кырган.

— Алай ук булмаса да, бер аршын бар иде, — дигән бай, киметә барып.

Ялчысы тагы тамак кырган. Бай түзмәгән, аңа таба борылган да:

— Карале, ахмак! Синеңчә, ул күсе бөтенләй койрыксыз булганмыни? — дигән.

## Күктәге айны җиргә төшерү нигә кирәк?

Рамазан аенда Бикташи[1] ураза тотмаска карар кыла, моның өчен ул күктәге айны күрмәскә тырышып, төннәрен тышка чыкмаска була.

— Ураза тотасыңмы? — дип сорап аптыратучыларга ул:

— Ураза тотар өчен мин юк айны ясый алмыйм ич! — дип кенә җавап кайтара.

Бер көнне Бикташига тышка чыгарга туры килә. Тышка чыккач, ул башын аска иеп, күккә карамаска тырыша. Аяк астында җыелып

[1] Дәрвиш.

торган су туры килеп, атлап чыгам дигәндә генә, суда түп-түгәрәк ай шәүләсе күрә.

— Я раббем, үзеңнең көчсез бер колың белән көч сынашырга уйладыңмы? Фәкыйрь бер бәндәңнән ураза тоттырыр өчен күктәге айны җиргә төшерү нигә кирәк иде инде? — дигән Бикташи шул чакны.

## Дипломатия эшенә җибәр

Көннәрдән бер көнне бер кеше дусты Бикташига мөрәҗәгать итеп:

— Хөрмәтле Бикташи, минем улым ялганга бик оста. Шул гадәтен һич ташлата алмыйм. Ни чара кылырга белмим, берәр киңәш бирче!— дигән.

Бикташи шунда ук җавап кайтарган:

— Син аны дипломатия эшенә җибәр. Ул анда бик зур уңыш казаныр, — дигән.

## Койка́

Бер кайнана яшь кенә килененә:

— Кызым, мин кайтуга койка́ пешереп куй әле, — дип йөрергә чыгып китә.

Килен, мескен, койкага тоз салалармы, юкмы? — дип аптырап кала. «Әгәр койка пешермәсәм, кайнанам кушканны эшләмәгән дип ачуланыр, пешерсәм, берни пешерә белми икән дип уйлар», дип борчуга төшә.

Күршеләрдән сорарга ояла. Бу хәлдән котылыр өчен ул ишек төбенә чыга да урамнан узучыларга карап тора башлый. «Еламаган балага имчәк бирмиләр»,— ди бит мәкаль. Шул вакыт юлдан, сакалын селкеп, чайкала-чайкала, бер карт узып бара икән.

— Бабай, тозсыз койка кебек нигә ул кадәр чайкаласың? — ди моңа әлеге килен.

Бу сүзне ишеткәч, карт:

— И кызым, кызым, койка тозлы буламыни? — дип көлеп җавап бирә.

Яшь килен, картның бу сүзенә бик сөенеп, тиз генә өйгә кереп китә һәм, кайнанасының кайтуына, җиңнәрен сызганып, бик тәмле койка пешерергә керешә.

## Баланы кызганыгыз

Бер бала өчен ике хатын талашып киткәннәр дә казыйга барганнар. Безнең бу дәгъвабызны бик гадел хәл итеп, баланың кайсыбызныкы икәнен аерып бир, дигәннәр. Ә үзләре бала минеке дип бер дәлил дә китерә алмаганнар. Шуннан соң казый палач чакыртып, баланы урталай кисәргә дә ике хатынга аерып бирергә кушкан.

Хатыннарның берсе казыйның хөкемен тыныч кына тыңлап торган, икенчесе ах-вах килеп еларга, ялварырга керешкән.

— Казый әфәнде, кызгана күрегез, баланы харап итмәгез. Мин баламнан ваз кичәм, тик ул исән генә калсын, — дигән.

Шуннан казый хатынны да аңлаган. Баланы чын әнисенә бирдергән, ә теге алдакчы хатынны илле тапкыр таяк белән суктырткан.

**ЯХЪЯ ХАЛИТОВ**
тәрҗемәсе.

Мин Шабай

**САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР**

*Бәясе 65 тиен*

Татарстан китап нәшриятында мәрхүм прозаик Мин Шабайның Сайланма әсәрләрен китап итеп бастырып чыгарды. Әдипнең бу җыентыгына «Уяну» исемле повесте һәм «Мәдрәсә», «Уйналмаган скрипка», «Басу




капкасы төбендә булган хәлләр», «Каз бәбкәләре» һәм башка иң яхшы хикәяләре тупланган. Дөньяга, кешеләргә, табигатькә соклану, тормышны гүзәл, кешеләрне бәхетле итеп күрергә теләү — Мин Шабай әсәрләренә хас төп сыйфатлар менә шул.

Хәйретдин Мөҗәй

**СУГЫШ ЯЗМАЛАРЫ**

Фашистларга каршы яшерен көрәш алып барганы өчен, Дахау концлагеренда Гитлер палачлары тарафыннан атып үтерелгән Совет Армиясе полковнигы, патриот шагыйрь һәм язучы Х. Мөҗәйнең бу җыентыгына аның сугыш язмалары, хикәяләре һәм шигъри әсәрләре тупланган.




Гариф Ахунов

**КАНАТЛАР КАЯ ИЛТӘ?**

Повесть

*Бәясе 58 тиен*

Татарстан бүген Советлар Союзында чыгарыла торган нефтьнең өчтән бер өлешен бирә.

Татарстан мехлары, Татарстан сәгатьләре, Татарстан машиналары дөнья ярминкәләрендә дан тота.




Татар әдәбияты һәм сәнгате Совет илендә генә түгел, чит илләрдә дә меңләгән укучыларын һәм тамашачыларын тапты.

Икмәккә һәм урман-суларга да бай ул безнең Татарстан. Әмма, барыннан да бигрәк, хезмәт сөюче алтын куллы кешеләргә бай.

Язучы Гариф Ахуновның «Канатлар кая илтә?» исемле повесте республикабызның әнә шул бетмәс-төкәнмәс байлыкларын һәм ул байлыкларны булдыручы кешеләрне сурәтләүгә багышланган.

Нәби Дәүли

**РАЗРУШЕННЫЙ БАСТИОН**

Роман

*Бәясе 49 тиен*

Нәби Дәүли рус телендә басылып чыккан бу романында[1] үзенең укучылар арасында инде киң танылган «Тормыш белән үлем




[1] Әсәрнең татарчасы узган ел аерым китап булып чыккан иде.

арасында» исемле повестенда кузгатылган теманы дәвам иткән. Әсәрдә фашистлар яңа корал эшләп чыгаруны күздә тотып салына торган җир асты заводын төзүче совет хәрби әсирләренең гитлерчылар белән кискен һәм батырларча көрәше тасвирланган. Ул көрәштә совет әсирләре зур гына югалтуларга дучар булалар. Әмма, шуңа да карамастан, алар станокларны эштән чыгаралар, завод төзүне тоткарлыйлар һәм, шулай итеп, фашистларның яңа корал булдырырга дигән начар ниятләрен тормышка ашырырга ирек бирмиләр.

Касыйм Фәсәхов

## ТЕКӘ ЯРЛАР

Шигырьләр җыентыгы

*Бәясе 32 тиен*

Касыйм Фәсәховның әле күптән түгел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан бу җыентыгына соңгы елларда язылган кырыклап яңа шигырьләре һәм




«Күңел ярасы» исемле зур күләмле поэмасы урнаштырылган.

Шамил Рәкыйпов

## ЧӘЧӘКЛӘР СӨЙЛИ БЕЛӘ

Повесть

Язучы Шамил Рәкыйповның бу яңа документаль повесте Советлар Союзы Герое Александр Матросовның үлемсез батырлыгын кабатлаган якташыбыз комсомолец Шәвәлиев образын гәүдәләндерүгә багышланган. Автор геройның балалык, яшьлек елларыннан алып, соңгы көннәренә кадәрге тормышын образлы тел, оста художество чара-




лары ярдәмендә җанлы һәм калку итеп сурәтләп биргән.

# *ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VII СЪЕЗДЫ*

## СЪЕЗД КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан язучыларының чираттагы җиденче съезды шушы елның 25 мартында Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында эшли башлады.

Иртәнге сәгать уннар. Театрның тамаша залы халык белән шыгрым тулы: бүгенге әдәбиятыбызның күренекле шагыйрьләре һәм прозаиклары, драматурглары һәм тәнкыйтьчеләре, республиканың төрле почмакларыннан җыелган яшь һәм башлап язучылар, партия-совет оешмаларының вәкилләре, мәдәният әһелләре, матур әдәбият сөючеләр...

Съездда катнашу өчен, киң илебезнең төрле шәһәр һәм өлкәләреннән кунаклар килгән: СССР һәм РСФСР язучылары союзларыннан вәкилләр, тугандаш Башкортстан язучылары, чуваш дусларыбыз, үзәк нәшриятларның, газета һәм журнал редакцияләренең җаваплы хезмәткәрләре...

Җиденче съездны өлкән язучыларыбызның берсе, Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр ага Бәширов ача.

— Минемчә, без үзебезнең җиденче съездыбызны элекке еллар белән чагыштырганда тагын да үсә һәм ныгый төшкән талантлы һәм бердәм иҗат коллективы буларак каршы алабыз,— диде ул үзенең кереш сүзендә.— Бу, минемчә, безнең иң әһәмиятле казанышларыбыздан берсе.

Без съездга 750 еллык озын гомере булган зур һәм бай бер әдәбиятның тулы хокуклы һәм лаеклы варислары булып киләбез. Чыгышларда бу хакта да сүз булыр. Бу бай мирасның безнең өскә зур җаваплылык өстәве дә тирәнрәк аңлашылыр, ул мирастан тулырак файдалану турында да кайгырту сүзләре әйтелер дип ышанасы килә.

Без съездга шулай ук соңгы 50 ел эчендә революцион эчтәлекле яңа әдәбият — төрле яктан камилләшеп җиткән, катлаулы, күп жанрлы татар совет әдәбиятын иҗат итүчеләр булып та киләбез. Шунлыктан, бүгенге уңышларыбыз һәм киләчәгебез турында сөйләгәндә, әдәбиятка якты, гуманистик традицияләр кертеп, тиңе булмаган әдәби образлар тудырып калдыручы әдәби остазларыбызны да онытмабыз, коммунизм идеяләренә тугрылыклы булу, халыкка кайнар мәхәббәт тойгыларын йөрәк каннары белән язып калдыручы каләмдәш иптәшләребезнең үзләрен дә, алар калдырган яхшы традицияләрне дә истә тотарбыз дип ышанасы килә.

Бу съездны ачканда шатланып һәм горурланып әйтерлек кайбер уңышларыбыз да бар. Шуларның берсе һәм, минемчә, иң җитдие — безнең сафларыбызга килеп кушылучы якты карашлы, кыю фикерле яшь талантларның елдан-ел күбәя баруы. Билгеле, бу яшь көчләр, башка язучылар белән кулга-кул тотынып, киләчәктә тагын да алгарак атларлар, күп милләтле совет әдәбияты мәйданында һәм тугандаш халыклар каршында татар совет әдәбиятының абруен, аның дәрәҗәсен тагын да югарырак баскычка күтәрерләр дип ышанабыз.

Безнең бу съездыбыз, минемчә, тагын бер ягы белән истә калачак. Һәркайсыбызга мәгълүм, бу көннәрдә бөтен дөнья җәмәгатьчелеге совет әдәбиятының нигезен салучы, аның зирәк лидерларыннан берсе, бөек гуманист Алексей Максимович Горькийның 100 еллыгын бәйрәм итә. Бу зур вакыйганың безнең съездыбыз вакытына туры килүе үзе үк күңелле хәл. Билгеле, Горький иҗатының безнең әдәбиятыбызга уңай тәэсире съездда рәхмәт сүзләре һәм ихтирам белән телгә алыныр дип уйларга кирәк.

Һәм, чыннан да, күп кенә башка проблемалар белән рәттән, Г. Бәширов кузгаткан бу мәсьәләләр дә съездның игътибар үзәгендә булды. Докладларда чал тарихлы, бай традицияле әдәбиятыбызның бүгенге торышына төпле бәя бирелде, язучылар коллективы башкарган күп төрле эшләр яктыртылды, Татарстан язучылары хәл итәргә тиешле актуаль проблемалар, алда торган бурычлар билгеләнде. Күп кенә чыгышларда да мөһим һәм өлгергән мәсьәләләр кузгатылды.

Татарстан язучылары союзы председателе Мирсәй Әмирнең отчет докладының барыннан да бигрәк үзенең тулылыгы белән аерылып торды[1]. Докладчы аерым жанр-

---

[1] М. Әмир докладын журналыбызның 5 санында басылды.

ларның үсешенә тәфсыйллы күзәтү ясады, бүгенге әдәби процесска хас үзенчәлекләрне һәм кимчелекләрне күрсәтте, кайбер борьяклы тенденцияләрне тәнкыйтьләде.

Ике съезд арасында Татарстан язучылар коллективына тагын 25 кеше өстәлгән. 1968 елның 1 мартына союз членнарының гомуми саны 111 кешегә җиткән. Шулар янына республиканың төрле шәһәр һәм районнарында яшәүче 500 ләп яшь һәм башлап язучыларны да китереп кушсак, әдәбият фронты солдатларының гомуми саны ифрат күбәя.

Татарстан язучылар союзы идарәсе күп санлы шул әдипләрнең иҗатына ниндирәк юнәлеш бирә алган, коллективның эшен никадәр оста итеп оештыра алган соң? Идарәнең җаваплы секретаре Зәки Нури докладында сүз нигездә әнә шул мәсьәләләр тирәсендә барды. Ул кузгаткан барлык мәсьәләләргә дә тукталып тормастан, докладта китерелгән кайбер мәгълүматларга гына күз салыйк:

Алтынчы съезддан соң узган вакыт эчендә нәшрият 500 исемнән артык матур әдәбият китабы басып чыгарган. Ул китапларның гомуми күләме 4326 табакка җитә, тиражы 9 млн. данәдән артыграк. Классикларыбызның һәм күренекле әдипләребезнең күп томлы сайланмаларын чыгару эше дә гамәлгә ашып бара. Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ф. Хөсни һәм М. Әмирләрнең өч томлыклары, Т. Гыйззәт белән Р. Ишморатның ике томлыклары укучылар кулына керде инде. Якын араларда И. Гази һәм Г. Гобәйнең өч томлыклары, Г. Әпсәләмовның алты томлыгы басылып чыгачак. СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында классик язучыбыз Галимҗан Ибраһимовның ун томлыгы әзерләнеп ята.

В. И. Ленинның 100 еллыгына безнең өч томнан торган үз ленинианабыз булачак. Аның татар язучылары әсәрләреннән төзелгән беренче томы инде басылып та чыккан.

Татарстан язучылары даими рәвештә авылларда һәм район үзәкләрендә, клубларда, промышленность предприятиеләрендә булганнар, колхозчылар, мәктәп балалары, студентлар, эшче яшьләр белән очрашканнар. Тугандаш республикалар һәм күрше өлкәләр белән әдәби бәйләнешләр тагын да тирәнәя һәм ныгый төшкән. 1965—67 еллар эчендә республиканың 11 районында әдәбият атналыклары үткәрелгән. Татар язучылары Ленинград, Астрахань, Ульяновск шәһәрләрендә, Төмән һәм Пермь өлкәләренең авылларында булып кайтканнар.

Яшь һәм башлап язучылар иҗатына идарә һәрвакыт җитди игътибар биреп килгән. Яшьләр өчен уздырылган күп санлы семинарлар һәм конференцияләр әнә шул турыда сөйли.

Съездда ревизия комиссиясенең отчет доклады белән язучы Гариф Гобәй чыкты.

— Партиябез һәм хөкүмәтебез язучыларга һәрвакыт җитди, эшлекле ярдәм күрсәтә килделәр,— диде ул.— VI съезддан соң узган берничә ел вакыт эчендә генә дә, язучыларның тормыш шартларын яхшырту юнәлешендә булсын, аларның сәламәтлеген саклау мәсьәләсендә булсын, күп төрле әйбәт эшләр башкарылды. Ике съезд арасында язучылардан 30 кеше яңа квартирага күчте. Йөзләрчә язучылар иҗат йортларында булып кайтты, санаторияләрдә дәваланды, ял йортларына барды...

Язучыларның тормыш шартларын яхшырту юнәлешендә башкарылган эшләрне санап чыкканнан соң, Г. Гобәй бу өлкәдә эшләнергә тиешле эшләргә тукталды, хәл ителмәгән мәсьәләләрне көн тәртибенә куйды.

Әйткәнебезчә, Татарстан язучыларының VII нче съездына республикабызның төрле оешмаларыннан, шулай ук күрше өлкәләрдән һәм тугандаш республикалардан кунаклар килгән иде. Кунаклар язучыларга үзләренең кайнар сәламнәрен тапшырдылар, аларга яңа иҗат уңышлары теләделәр, изге теләкләрен җиткерделәр. Котлап чыгыш ясаучылар арасында РСФСР язучылар союзы секретаре Л. К. Татьяничева, чуваш язучысы А. Калган, күренекле башкорт әдибе, «Агыйдел» журналының җаваплы редакторы Х. Гыйләҗев, комсомолның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. Фәрхиев, СССР язучылар союзы вәкиле В. Ганиев, гарәп язучысы Сәхип Җамал, китапханә эшчесе Хәлифов, укытучы З. Таранова һәм башкалар бар иде.

Докладлар буенча фикер алышуларда ике дистәгә якын кеше катнашты. Алар татар совет әдәбияты ирешкән уңышларга, әдәбиятның бүгенге торышына, аерым тармакларның үсеш дәрәҗәсенә тукталдылар. Язучылар союзы һәм һәрбер язучы алдында торган мөһим бурычлар, актуаль мәсьәләләр турында сөйләделәр. Кыскасы, ике көн буена шактый җитди, кайнар һәм бәхәсле сөйләшү барды.

— Без поэзия жанрының үсеше турында горурланып сөйли алабыз, проза әдәбиятыбыз нормаль үсә дип әйтә алабыз. Ә менә драматургия өлкәсенә күз ташласак, шактый күңелсез күренешләр белән очрашабыз,— диде Г. Ахунов.— «Галиябану», «Ташкыннар», «Җилкәнсезләр», «Хуҗа Насретдин», «Миңлекамал» кебек әсәрләр туган заманнар сагынып сөйләргә генә калды.

Г. Ахунов драматургиянең артта калуына китергән сәбәпләрне аңлатты, алардан котылу, аларны бетерү буенча күп кенә конкрет тәкъдимнәр кертте. Алга таба Г. Ахунов татар халкының революцион каһарманнарына багышланган тарихи әсәрләрнең аз булуы турында борчылып сөйләде һәм Әлмәт бүлекчәсенең эшчәнлегенә тукталды, Әлмәттә яшәүче язучыларның әсәрләренә бәя бирде.

Съездда әдәбиятның аерым жанр һәм тармаклары, шул жанрларга гына хас мәсьәләләр турында да шактый төпле һәм тирән сөйләшү булды. Доклад буенча фикер алышуларда катнашкан язучылардан Ләбибә Ихсанова, мәсәлән, нигездә балалар әдәбиятына багышланган проблемалар хакында сөйләде:

— Без әле бала вакытта ук рус теленнән тәрҗемә ителгән бик мавыктыргыч һәм кызыклы китаплар укый идек. Аларның күбесенең авторлары да онытылып беткән инде, ә геройлары, аерым эпизодлары һаман истә. Нинди китаплар иде соң алар? Кара-Ком сәяхәтчеләре, Тянь-Шань тауларын тикшерүчеләр турында иде ул китаплар. Сугышка кадәр балалар әдәбияты өлкәсендә эшләгән талантлы язучылардан Хәмит Кави дигән авторны телгә алып китәсе килә. Аның «Кузбасска сәяхәт», «Донбасс шахталарында» кебек китаплары әле дә булса онытылмыйлар. Сугыштан соң мондый төр әдәбият бөтенләй диярлек йомылып калды.

Алга таба Л. Ихсанова балалар әдәбиятының үсешен тоткарлый торган сәбәпләрне аңлатты һәм Ә. Маликов, Г. Ахунов, Ш. Рәкыйпов кебек язучыларның соңгы елларда чыккан әсәрләренә анализ ясады.

Казан дәүләт университеты укытучысы Гыйрфанова исә үзенең чыгышын әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә багышлады. Г. Бәшировның «Намус» романы мисалында ул татарчадан русчага тәрҗемә практикасында очрый торган җитди кимчелекләрне ачып салды. Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты редакциясе мөдире Ш. Рәкыйпов мемуар әдәбият алдында торган бурычлар хакында сөйләде, язучыларны әдәбиятның бу өлкәсендә активрак эшләргә чакырды. Ә. Давыдов чыгышы традиция һәм новаторлык, аларны аңлау һәм аңлату мәсьәләләренә багышланган иде.

Октябрь революциясе дөньяны ике лагерьга, ике системага аерды. Бер якта тарих тарафыннан, тормышның объектив кануннары тарафыннан үлемгә, череп таркалуга хөкем ителгән капитализм лагере, икенче якта — социализм лагере. Ике система, ике лагерь арасында дистә еллар буе өзлексез рәвештә рәхимсез көрәш барды. Һәм ул көрәш бүген дә дәвам итә. Аның тышкы чагылышы, формалары үзгәрде. Капитализм дөньясы көрәшнең тагын да астыртын, тагын да кабахәт алымнарын уйлап чыгара тора. Җир шарында кешенең намусы, җаны өчен аяусыз көрәш, кискен идеологик көрәш бара.

Шундый шартларда язучылар нишләргә тиеш? Аларның урыны кайда, алар кем белән? Ике система арасында барган идеологик көрәшкә каләм осталары битараф карый аламы? Үзенең чыгышында А. Расих язучылар игътибарын, барыннан да бигрәк, әнә шул мәсьәләләргә юнәлтте.

— Сезгә ничек тоела торгандыр, минем үземне соңгы вакытта әдәбиятта күбәйгән тар горизонтлы кешеләр — персонажлар борчый башлады.— Язучы Ф. Хөсни сүзен әнә шулай алып китте.— Аларның басып бии торган мәйданчыклары гаять кечкенә, итәкләре стенага тиеп-тиеп китә. Болай аларның буй-сыннары да зифа, килешле генә итеп киенә беләләр, чикләвек кабыгына гына сыеп бетәрлек мәхәббәтләре дә бар... Ләкин аларның горизонтлары бик тар. Алар бүгенге киң дөнья белән яшәмиләр. Кайвакыт күңелгә шик килә: алар газета укыйлармы икән, дөнья хәлләре белән аз булса да кызыксыналармы икән? Нәрсәдән килә бу? Минемчә, барыннан да элек, язучының үзенең горизонты тар булудан килә булса кирәк...

Чыгышының ахырында Ф. Хөсни бүгенге әдәбияттагы кыска хикәя жанрына тукталды, бу жанрның үсеш дәрәҗәсенә күзәтү ясады, кыска хикәя жанрын активлаштыру, җанландыру өчен конкрет тәкъдимнәр кертте.

Галиәсгар Камал исемендәге татар академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗановның кайнар чыгышын да съезд делегатлары кызыксынып һәм игътибар белән тыңладылар. Ул, М. Әмирнең отчет докладында драматурглар һәм театр коллективы адресына әйтелгән тәнкыйть фикерләре белән килешә алмыйм, диде. Докладчының һәм чыгыш ясаган иптәшләрнең аерым положениеләре белән бәхәскә керде.

Фикер алышуларда шулай ук Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Камалиев, балалар язучысы Җ. Тәрҗеманов, тәнкыйтьче Р. Мостафин һәм яшь шагыйрь Р. Харисовлар да катнашты.

Ахырдан КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев зур речь белән чыкты. Шуның белән җиденче съезд үзенең эшен тәмамлады.

◇ ◆ ◇

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## МУЗЫКАЛЬ ФЕСТИВАЛЬ

Юлбашчыбыз В. И. Ленинның туган көненә багышлап үткәрелә торган музыкаль фестиваль соңгы алты ел эчендә традициягә әверелде. Бу фестивальгә ел саен совет сәнгатенең иң оста, иң күренекле вәкилләре катнаша.

Быел апрель аенда 20 көн дәвамында Казан театрларында, культура сарайларында бөтен дөньяга мәшһүр коллективлар — СССР халык артисты, профессор А. В. Свешников җитәкчелегендәге ССР Союзы Академия хоры, СССРның халык артисткасы Н. Надеждина җитәкчелегендәге «Березка» Дәүләт хореография ансамбле, «Җырлый торган гитаралар» ансамбле, СССР халык артисткасы В. Марецкая, Бөтенсоюз һәм халыкара эстрада конкурслары лауреаты И. Кобзон концертлар бирделәр.

Фестиваль Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында башланды. Язгы музыкаль бәйрәмне Татарстан Министрлар Советы председателе урынбасары Р. Ярмөхәммәтова ачты.

Бетховенның беренче тапкыр 1908 елда яңгыраган, азатлыкка, туганлыкка, бердәмлеккә ирешү тантанасын сурәтләгән Бишенче симфониясен Казан тамашачылары зур күтәренкелек белән тыңладылар.

Халыкара пианистлар конкурсы лауреаты А. Каплан С. Рахманиновның Икенче концертын башкарды. Бу кичә П. И. Чайковскийның «Итальян каприччиосы» исемле симфоник әсәре белән тәмамланды. Симфоник оркестр белән Казагыстанның халык артисты, дирижёрларның Бөтенсоюз конкурсы лауреаты, безнең якташыбыз Фуат Мансуров дирижерлык итте.

## АЧЫК ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

**19 апрельдә** Татарстан язучылары союзы каршындагы партия оешмасының ачык җыелышы булды. Татарстан язучыларының VII съезды йомгаклары һәм партия оешмасының бурычлары турындагы докладны партия оешмасы секретаре Л. Ихсанова ясады. Доклад буенча фикер алышуга катнашкан И. Гази, А. Талвир, В. Синев, С. Сабиров, А. Хәсәнова һ. б. лар съездда күтәрелгән мәсьәләләрне тормышка ашыру чаралары, империализмга каршы идеологик көрәштә язучыларның тоткан роле турында сөйләделәр.

Җыелыш кузгатылган мәсьәләләр буенча карар кабул итте.

## ТАНЫЛГАН КИНО АРТИСТЛАРЫ КАЗАНДА

Апрель аенда республикабызның башкаласында кино бәйрәме үткәрелде. Шул уңай белән Казанга утызга якын танылган кино артистлары килде. СССРның халык артисты В. Белокуров, РСФСРның халык артисткасы Л. Смирнова, РСФСРның халык артисты М. Кузнецов, РСФСРның халык артисты Е. Матвеев, РСФСРның атказанган артистлары З. Федорова, К. Лучко, Н. Румянцева, Г. Вицин, артистлардан Н. Мордюкова, К. Сорокин, Е. Моргунов, В. Ивашов, В. Васильев, Бруно Оя, Ю. Белов, В. Беляевский, В. Шалевич, В. Комаров, Г. Яцкина, Г. Юматов, О. Воронцов, Б. Битюгов, Е. Винник, Д. Ашкинази һ. б. лар Спорт сараенда, кинотеатрларда, предприятиеләрдә, культура сарайларында ун меңләгән кино сөючеләр белән очрашып, концертлар бирделәр, үзләренең иҗат үрнәкләре белән таныштырдылар.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Һәр яз саен, апрель аенда, халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай туган көн уңае белән, республикабыз башкаласы Казанда, шәһәр һәм авылларда шигырь бәйрәме үткәрелә.

Быел да шагыйрьләр, әдипләр, әдәбият сөючеләр шигырь бәйрәмен зур итеп үткәрделәр. Бәйрәмгә Ленинградтан, Башкортстаннан, Кара-Калпак АССРдан кунаклар килде.

Шигырь бәйрәме **23 апрельдә** Зеленодольск шәһәрендә башланды. Шәһәрнең Культура сараендагы Зәңгәр залга күп санлы әдәбият сөючеләр җыелды. Анда үткәрелгән шигырь кичәсенә И. Туктар, Н. Арсланов, З. Нури, Ш. Галиев, Ф. Шәфигуллин катнашты. Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре З. Нури Татарстан язучыларының VII съезды йомгаклары турында сөйләде, шагыйрьләр үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

**24 апрельдә** шигырь бәйрәме дәвам итте. Казан дәүләт консерваториясенең Зур залында бу көнне шигырь һәм җыр кичәсе булып үтте. Бу кичәдә татар шагыйрьләре һәм Ленинградтан, Кара-Калпак АССРдан килгән кунаклар үзләренең шигырьләрен укыдылар, композиторлардан: З. Хәбибуллин һәм Р. Яхин, А. Ключарев, З. Гыйбадуллин, Ф. Әхмәдиев, артистлардан: И. Шакиров, Р. Билалова, Г. Рәхимкулов,

А. Арсланов, Х. Гыйниятова, Р. Ибәтуллин, К. Янбулатова һәм Т. Якупов катнашты.

**26 апрельдә** Куйбышев мәйданындагы Г. Тукай һәйкәле янында традицион шигъри митинг үткәрелде. Кичен язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Башкортстаннан килгән яшь шагыйрьләр катнашында шигырь кичәсе булды.

## ГОРЬКИЙ КӨННӘРЕНДӘ

Бөек пролетар язучысы М. Горькийның тууына 100 ел тулу уңае белән Мәскәүдә М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтында «Горький һәм заман» темасына фәнни сессия булды. Анда филология фәннәре докторы, СССР язучылары союзы члены М. Гайнуллин «Горький һәм татар әдәбияты» дигән темага доклад ясады. М. Гайнуллин шундый ук докладны Азия халыклары институтында «Горький һәм көнчыгыш» темасына үткәрелгән фәнни конференциядә һәм «Горький һәм СССР халыклары әдәбияты» дигән темага Ереванда үткәрелгән Бөтенсоюз конференциясендә дә укыды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Проза секциясенең **18 апрельдә** үткәрелгән чираттагы утырышында яшь язучы В. Нуруллинның «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Шинельсез солдатлар» повесте турында фикер алышу үткәрелде.

Фикер алышуга А. Расих, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Бакиров, Н. Фәттах, Я. Халитов, Т. Миннуллин, Х. Сарьян, К. Тимбикова һәм башкалар катнашып, яшь авторның беренче зур әсәрендәге уңышлы һәм кимчелекле якларны күрсәттеләр, киләчәктә иҗат эше өчен файдалы киңәшләр әйттеләр.

**12 апрельдә** үткәрелгән тәнкыйтьчеләр секциясе утырышында яшь тәнкыйтьче Ф. Мусинның соңгы еллардагы проза әсәрләрендә герой мәсьәләсенә карата ясаган докладын тикшерү булды. Докладчы һәм доклад буенча чыгыш ясаган Х. Хәйри, З. Мәҗитов, М. Гайнетдинов, М. Бакиров һ. б. лар, бүгенге проза әсәрләренә киң тукталып, аларда художество сыйфатларының үсә баруын, сурәтләнгән геройларның характерларында совет кешеләренә хас үзенчәлекләрнең өстенлек алып торуын билгеләп үттеләр.

## Ш. МӘРҖӘНИНЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

11 апрельдә СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында Шиһап Мәрҗанинең тууына 150 ел тулу уңае белән Гыйльми совет утырышы булды. Утырышка Казан югары уку йорты укытучылары, дәүләт архивы, китапханә хезмәткәрләре катнашты.

Тарих фәннәре докторы А. Халиков «Ш. Мәрҗани — беренче җирле татар тарихчысы» дигән темага доклад ясады. Филология фәннәре докторы М. Гайнуллин, филология фәннәре кандидатлары Х. Хисмәтуллин, М. Усманов һ. б. лар белдерүләр белән чыктылар.

Утырышка катнашучылар Ш. Мәрҗани әсәрләренең басмасын әзерләү һәм аның юбилее уңае белән фәнни конференция үткәрү мәсьәләсен көн тәртибенә куйдылар.

## ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕНДӘ КУЛЬТУРА ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Моннан өч ел элек Әлмәттә Татарстанның районара симфоник оркестры оештырылган иде. Бу коллектив республикабызның көнчыгыш районнары хезмәт ияләренә уңышлы рәвештә культура хезмәте күрсәтеп килә.

Апрель аеннан башлап районара симфоник оркестр, репертуарын яңартып, нефтьчеләрне һәм колхозчыларны Моцарт һәм Салих Сәйдәшев әсәрләре белән таныштыруга кереште.

Әлмәт музыка училищесының беренче чыгарылышы булды. Училищены тәмамлаган дистәләрчә яшь музыкантлар Алабуга, Азнакай, Бөгелмә, Баулы, Әлмәт, Лениногорск, Чаллы һәм башка шәһәр һәм поселокларда балалар музыка мәктәпләрендә укытачаклар.

## СӘЕТ КАЛЬМЕТОВКА 50 ЯШЬ

Әлмәт шәһәрендә яшәүче драматург Сәет Кальметовка 50 яшь тулды. Юбилей уңае белән Техника йортында тантаналы кичә үткәрелде. Кичәне КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Хәкимова ачты. Драматургның тормышы һәм иҗади эшчәнлеге турындагы докладны Гариф Ахунов ясады. Соңыннан партия-совет оешмалары, нефть учреждениеләре, колхоз һәм совхозлар, мәктәпләр исеменнән юбилярга карата күп санлы тәбрикләү сүзләре әйтелде. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы драматургны Почет грамотасы белән бүләкләде.

Икенче бүлектә кичәгә катнашучылар Әлмәт татар драма театры артистлары һәм музыка училищесы укучылары, укытучылары көче белән үткәрелгән зур концерт карадылар.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Мәскәү шәһәренең атеистлар клубында татар әдәбиятына багышланган әдәби кичә үткәрелде. Кичәне техник фәннәр докторы, профессор Искәндәр Нигъмәтуллин ачты. Ә. Галикәев, Ф. Кутуева, М. Таһирова һ. б. лар «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр турында сөйләделәр. Татар әдәбияты вәкилләре Х. Вахит белән Г. Минский һәм башкорт шагыйре Г. Рамазанов яңа әсәрләрен укыдылар.

Яшь шагыйрьләр Равил Фәйзуллин белән А. Хәлим Әгерже районы авылларында булып кайттылар. Алар Иж-Буби, Исәнбай, Баржы-Умга, Кырынды, Салагыш һәм башка авылларда әдәбият сөючеләр белән очраштылар, татар әдәбиятының бүгенге

торышы турында сөйләделәр, яңа шигырьләрен укыдылар.

**19 апрельдә** Казан химия-технология институты студентлары татар әдәбияты һәм сәнгатьнең яшь көчләре белән очрашу үткәрделәр. Кичәдә җырчы И. Шакиров, композитор Р. Еникеев, шагыйрь Р. Фәйзуллин, прозаик Р. Батуллиннар катнашты. Сәхнәдән җыр, шигырь, музыка яңгырады. 800 кеше катнашкан бу кичә зур күтәренкелек һәм алкышлар белән узды.

## ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБТА

**12 апрельдә** чираттагы әдәби җомгада кыска хикәяләр кичәсе үткәрелде. Анда Ф. Хөсни, Х. Сарьян, Р. Батуллин, Г. Шәрәфетдинов һ. б. лар әдәбият сөючеләрне үзләренең яңа хикәяләре белән таныштырдылар.

## М. ГОРЬКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗДА

Мөслим районының Максим Горький исемендәге артель членнары бөек язучының тууына 100 ел тулу көнен зур итеп билгеләп үттеләр. Шул уңай белән колхоз идарәсе М. Горький исемендәге премия билгеләде. 100 сум күләмендәге бу премия һәр елны язучы туган көнне — 28 мартта иң алдынгы механизаторларга, терлекчелек осталарына биреләчәк. Быел М. Горький исемендәге премияләр комбайнчылардан М. Гыймранов белән В. Латыйповка, тракторчы Г. Әхмәтҗановка тапшырылды.

Киләчәктә Октябрь авылында бөек язучыга һәйкәл салу планлаштырылды.

## ЯҢА ДИССЕРТАЦИЯЛӘР

Казагыстан ССР Фәннәр академиясенең тел, әдәбият һәм сәнгать институтларының берләштерелгән Гыйльми Советы утырышында М. Горький исемендәге Омск педагогия институты доценты Г. Әмиров «Г. Тукай теле (лексика һәм фразеология)» дигән темага докторлык диссертациясе яклады.

Казан дәүләт университетының март — апрель айларында үткәрелгән Гыйльми советы утырышларында журналыбызның актив авторларыннан М. Усманов, Ә. Кәримуллин, С. Алишев, К. Зиннәтуллина фәннәр кандидаты дигән гыйльми исем алу өчен диссертация якладылар.

М. Усмановның «XVII—XVIII йөзләргә караган тарихи кулъязмалар һәм аларның үзенчәлекләре», С. Алишевнең «Татарлар һәм Пугачев хәрәкәте» исемле хезмәтләре — тарих фәннәре кандидаты, Ә. Кәримуллинның «Татарларда китап басу һәм татар филологиясенең яңа чыганаклары. (XVII—XIX йөзләр.)», К. Зиннәтуллинаның «Хәзерге татар әдәби телендә фигыльләр төрләнеше» дигән хезмәтләре — филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаеклы дип табылды.

## «ДАВЫЛГА ТАБАН» ҮЗБӘКСТАН СӘХНӘСЕНДӘ

Танылган татар драматургы Р. Ишморатның «Давылга табан» пьесасын Хәмзә исемендәге Ташкент драма театры Үзбәкстан тамашачыларына күрсәтте. Владимир Ульянов ролендә яшь артист Х. Абдурәсүлов, Мария Александровна Ульянова ролендә СССРның халык артисткасы, Дәүләт һәм Хәмзә премияләре лауреаты С. Ишантураева уйнады. Спектакльне сәхнәгә режиссер Н. Отобаев куйды.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210